Галимнәр том диалекты вәкилләре берничә төркемнән тора дип карыйлар. Мәсәлән, А.П. Дульзонның түбәндәгечә бүлүе билгеле: 1) әүштәләр (Том шәһәре эченә кереп калган), 2) чатлар, 3) Обь татарлары, 4) калмаклар. Шул ук вакытта бу төркемнәрнең бер-берсенә якын торуларын да искәртәләр. Мәсәлән, Г.Ф. Миллер һәм М.А. Габдрахмановлар әүштәләр һәм чатлар

---

[1] *Тумашева Д.Г.* Диалекты сибирских татар. Опыт сравнительного исследования. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1977. 295 с.

бер-берсенә аеруча якыннар дип күрсәткәннәр. Кызылкаш, Умавыл, Абытай, Калтай авыллары вәкилләренең сөйләше чат сөйләшенә караса, Әүштә авылында әүштә сөйләшендә аралашалар. Болардан тыш, чат сөйләше вәкилләре Новосибирск өлкәсенең Колыван районы Акбалык, Оры (Умар) авылларында яшиләр.

Калмак сөйләше вәкилләре Кемерово өлкәсе Юрга районының Тумаел (Константиновка), Кышлау, Искедим авылларында яшиләр.

Том диалекты тубыл-иртеш (Төмән, Омск өлкәләре) һәм бараба (Новосибирск өлкәсе) диалектлары белән шактый уртаклык күрсәтә. Аларның якын бәйләнештә булулары турында фактлар теркәлгән. Мәсәлән, чат сөйләшенә карый торган авылларның берсен татарча Умавыл дип, русча Барабинка дип атыйлар. Сөйләүләренә караганда, бу авыл кешеләре Бараба ягыннан килгән. Аларның сөйләшендә бараба диалектына хас сүзләр яки күренешләр дә очрый. Шул ук вакытта Бараба ягында Омаул (чаг.: Ом) исемле авыл бар.

Калмак сөйләше исә алтай теленә якынлык күрсәтә (бу турыда түбәндә кара).

## Әүштә-чат сөйләше

Әүштә-чат сөйләшенең тубыл-иртеш диалекты һәм татар теленең урта диалекты белән күпмедер дәрәҗәдә уртаклыгы бар. Тубыл-иртеш диалекты белән якынлыкның нигезендә озак еллар дәверендә бер географик территориядә яшәү торса, татар теленең урта диалектына якынлыгын татар әдәби теленең йогынтысы (беренче чиратта, мәктәп һәм матбугат чараларының тәэсире) белән аңлатып була.

### *Сузык авазлар*

Сөйләшкә киң әйтелешле, иренләшү төсмере булмаган *а* авазы характерлы. Ул төрле позицияләрдә күзәтелә: *йақ* – як, *чанақ* – чана, *қарабақцай* – сыерчык һ.б. Кайбер очракларда бу авазның тирән тел арты варианты да күзәтелә. *А'* авазының


Современное расселение сибирских татар
– тобольские татары
– заболотные татары
– тюменские татары
– тевризские татары
– тарские татары
– томские татары
– барабинские татары
Сургут
Ханты-Мансийск
Демьянское
Иртыш
Уват
Тобольск
Лайтамак
Тобол
Вагай
Усть-Ишим
Тара
Тюмень
Ялуторовск
Ишим
Курган
Петропавловск
Омск
Чаны
Куйбышев
оз. Чаны
Барабинск
Колывань
Новосибирск
Юрга
Томск
Кемерево
Обь
Чулым

бу вариантлары тагын керәшен, нократ, пермь, касыйм һ.б. сөйләшләргә дә хас.

*е* – уртача күтәрелешле, иренсезләшү төсмере булмаган аваз, борынгы төрки і авазына якын, күбесенчә беренче иҗектә яисә бер иҗекле сүзләрдә, нигездә, өлкән буын сөйләшендә күзәтелә: *мен* – мин, *кел* – кил, ягъни хәзерге татар телендәге и авазына туры килә.

*ә* – киң әйтелешле, татар телендәге ә авазына тәңгәл килә: *әкә* – абый, әйбәт, *йәш* – яшь, *мәрзән* – мәрҗән, *кәзә* – кәҗә һ.б.

Кайбер сүзләрдә, бигрәк тә сүз тамырында – *ә~е~и* тәңгәллекләре күзәтелә.

Киресенчә, әдәби телдәге *э (е)* авазы урынына *и* әйтелергә дә мөмкин: *ит* – эт, *иш* – эш, *силер* < *слер* < сезләр – әд. сез, *инә* – *ене* – әни – әд. әни.

*ы* – бу авазның әйтелеше, нигездә, әдәби телдәгечә: *чық* – чык, *мышық* – песи, *сары* һ.б.

Әүштә-чат сөйләшендә *ы* авазына *а* сузыгы тәңгәл килү очраклары, башка сөйләшләр белән чагыштырганда, ешрак күзәтелә.

Мәсәлән: соңгы ачык иҗектә: *тура* – әд. туры, *тамча* – тамчы, *суwақ* – суык, *тағайа* – такыя.

Сорау кисәкчәсендә: *барба-йоқба* – бармы-юкмы, *көрдөнбә* – күрдеңме.

Инфинитив кушымчасында: *барғала керәк* – диал. *барғалы кирәк* – барырга кирәк, *сурагалы – сорағалы* – әд. сорарга кирәк.

Фигыль кушымчаларында: *қурқый* – курка, *утрар* – утырыр, *барар* – барыр.

***ы ~ а***: *йаңы* – яңа, *ылақ-салақ* – алак-салак, *қайтқынчы* – кайтканчы һ.б.

*о* – иренләшкән, арткы рәт сузыгы, нигездә, тамыр иҗектә күзәтелә, еш кына у авазы урынына әйтелә, ягъни борынгы төрки сузыклар шкаласын чагылдыра: *йоқ* – йук – әд. юк, *қонақ* – кунак, *отыра* – утыра, *соу бойында* – су буенда һ.б.

*ө* әлеге авазның алгы рәт пары, кулланылыш закончалыклары да шундый ук: *өр* – үр (үрә), *көмір* – күмер, *көрсәт* – күрсәт һ.б.

*о – ө* авазларының кулланылышында бер үзенчәлекне күрсәтеп үтәргә кирәк: тамырдагы иренләшкән *о – ө* сузыклары беренче булмаган иҗекләрдәге яки кушымчалардагы *ы – е* сузыкларына да тәэсир итәргә, иренләштерергә мөмкин: *болодоғон* – була торган, *төлөгөлө – түләгәле* – түләргә һ.б. Бу типта иренләштерү күренеше күрше бараба диалектында актив. Мондый иренләштерү алтай телләренә дә хас.

*у, ү* сузыклары да үзләренең кулланылышында борынгы төрки тел үзенчәлекләре белән уртаклык күрсәтәләр. Беренчедән, алар борынгы төрки телдәгечә, татар әдәби телендәге *о – ө* авазлары урынында әйтеләләр: *ҡут* – кот, *мус* – боз, *ҡул* – кол; *көс* – күз, *өс* – үс, *ҡуңус* – коңгыз һ.б. Икенчедән, тамырдагы *у, ү* авазлары беренче булмаган иҗекләрдә дә әйтелергә мөмкин: *күгүән* – кигәвен, *одук* – итек, *ҡузуҡ – косык* – чикләwек һ.б.

Өченчедән, *у – ү* сузыклары әүштә-чат сөйләшендәге кебек, сыйфатларның азагындагы *ы – е* сузыкларына тәңгәл киләләр: *шаҡмаҡту* – шакмаклы, *йапраҡту* – яфраклы, *йылу* – җылы, *олу* – олы, *күстү* – көчле, *иссү* – эссе, *кецү* – кече.

Күрсәтелгән тәңгәллекләр әүштә-чат сөйләшендә системалыкларын югалтканнар. Нәтиҗәдә, сөйләштә *керек/кәрәк*/кирәк, *итин*/идән, *мишкә/мәшкә* – гөмбә, *себергәлә/сібергәлі* – себерергә, *ит* – эт, *келди* – килде кебек янәшәлекләр, аерымлыклар кулланыла.

Гомумән, әүштә-чат сөйләшендә үзенчәлекле күренешләр, борынгы формалар сакланып килә. Себер татар диалектларының барысы өчен дә уртак булган күренешләр том диалектында да күзәтелә. Билгеле, соңгы еллардагы тикшеренүләр саңгыраулану күренешенең системалылыгы шактый җимерелгән икәнен күрсәттеләр. Ике сузык арасындагы саңгырауларның яңгыраулашуы системалылыгы йомшаган.

Сөйләштәге сузык авазлар өлкәсендә үзенчәлекләр төрле тәңгәллекләргә, комбинатор һәм позицион үзгәрешләргә кайтып кала. Аларны татар әдәби теле белән чагыштырып күрсәтеп үтик.

***а ~ ә, ә ~ а*** тәңгәллекләре алгы рәт һәм арткы рәт сузыкларын алмашып куллануда чагыла: *айт/әит* – әйт, *әкә/ақа/аққа* – абый, *йаш/йәш* – йәш (яшь), *йәжә/йаша* – йәшә (яшә), *чәйә* – чайа (чая), *мынаң/менәң* – белән; *әрзән* – арзан; *йәнекәйем* – җаныкаем, *хийәли* – хыйалый (хыялый), *кәлпәк* – калфак, *пүдер* – пудра, *кәрәлкә* – корольки (ритуаль камыр ашы), *әцкец* – ачкыч, *мерас* – мирас, *бәребер* – барыбер; *сәкәлүк* – скалка.

Кайбер сүзләр сөйләштә ике вариантта кулланыла: *чөрөш/чырыш* – җыерчык, *бөк/бок* – болын, *балтә/бәлтә* – пальто.

***ә ~ е*** бер төркем сүзләрдә (*күгәмай/күгемәй* – күк җиләк), тамырларында *р* булган фигыль формаларында (*өлгөрәр* – өлгерер, *тийәрсес*– дийерсез (диерсез), *йөрәр* – йөрер һ.б.), сорау кисәкчәсендә (*көрдеңбә* – күрдеңме) табыла.

***э (е) ~ ә***: *көйәнте* – көйәнтә (көянтә); хәл фигыль кушымчаларында: *пешкенце*– пешкәнче, *килгенцек*– килгәнче, *көргенце* – күргәнче һ.б.

***и ~ э (е)***: *илеке* – элек, *исү* – эссе, *тигермән* – тегермән.

***э (е) ~ и***: *эгес* – игез, *эшек* – ишек, *керпец* – кирпеч, *мерәс* – мирас, *мейә* – диал. *мийә* – ми.

Аерым сүзләрдә генә күзәтелә торган тәңгәллекләр. ***а ~ у:*** *апсақ* – усак; ***ы ~ у:*** *чардыван* – чардуган; ***ә ~ и:*** *сәксан* – сиксән; ***и ~ ә:*** *кибәч* – диал. кәпәч – түбәтәй; ***и ~ ү:*** *сирәт* – сүрәт – сурәт; ***и ~ у:*** *бийақ* – бу йак (як); ***у ~ а:*** *кину* – диал. кина – кино.

***ō ~ у***. Өлкән буын сөйләшендә борынгы төрки озын сузык *ō* саклана: *ōрақ* – урак, *ōтыс* – утыз, *тōқта* – тукта, *бōйында* – буенда, *бōла* – була, *қōнақ* – кунак, *ōрау* – урау, *сōғыш* – сугыш, *қōй* – куй (сарык) һ.б.

***у ~ о:*** *мус* – боз, *қуңус* – коңгыз, *қузуқ* – диал. *қосық* – чикләвек, *қуш* – кош, *тура* (< тора) – шәһәр һ.б. Бу типтагы тәңгәллек азрак күзәтелә.

Күзәтүләргә караганда, бу үзенчәлек системалылыгын югалткан. Шуңа күрә борынгы төрки *у, о* авазларына сөйләштә еш кына татар әдәби теленә хас *о, у* тәңгәл килә*: бул, қул, ун, утырт, су цума* – су коена, *шулпа, уқыта, туған, қошкайақ* – кошчык һ.б.

***ө̄ ~ ү*** тәңгәллегә дә сөйләштә борынгы төрки *ө̄* озын сузык авазының сакланып килүе белән бәйле: *кө̄мер* – күмер, *ө̄скән* – үскән, *кө̄р* – күр, *кө̄п* – күп, *цө̄прәк* – чүпрәк, *кө̄нбәс* – күнмәс, *тө̄рт* – дүрт, *ө̄лцә* – үлчә һ.б.; шулай ук: *бө̄гө̄н* – бүген, *тө̄гө̄л* – түгел (сирәк).

Әлеге үзенчәлек, нигездә, өлкән буын сөйләм телендә күзәтелә. Туплаган материаллар *ө* һәм *ү* авазын әдәби телдәгечә куллануның шактый актив булуын күрсәтте. Үз заманында Д.Г. Тумашева да мондый фактны ассызыклап үткән иде[1]. Нәтиҗәдә, сөйләштә: *күс* – күз, *үләрдә* – үлгәндә, *сүзеңне, бүләм, күргән, үзенеке, түшәм, күлмәк, күтәргән* дип сөйләү актив күзәтелә.

***о – е ~ у – ү*** тәңгәллекләре бер үк сүзнең ике вариантта кулланылуында да чагылыш таба. Мәсәлән, XX гасыр урталарында ук Д.Г. Тумашева *күс/көс, түк/төк, түлә/төлә, боға/ буға – үгез, торбақ/турбақ – бозау, қозоқ/қузуқ* – чикләвек кебек параллельләрне күрсәтеп үткән[2].

Шулай итеп, әүштә-чат сөйләшендә *о – ө* һәм *у – ү* авазлары тәңгәлләшү күренеше шактый актив күзәтелә. Бу авазларны татар әдәби телендәгечә куллану тенденциясе җиңеп килә.

Әүштә-чат сөйләшендә тагын әдәби телдәге *и* сузыгына, касыйм, темников сөйләшләрендәге кебек, *ү* авазы тәңгәл килү күренеше бар: *күгүwөн* – кигәwен (кигәвен), *үтек/өтүк* – итек, *үкмәк/үкмөк/өкмөк* – икмәк.

И р е н л ә ш ү  г а р м о н и я с е. Тамырдагы борынгы *о̄, ө̄* авазлары башка иҗекләрдәге *ы, е* авазларын да иренләштерү очраклары күзәтелә: *бо̄ло̄доғон* – була торган, *кө̄шөгө* (диал. күшәгә) – пәрдә, *сө̄змөкөр* (диал. сүзмәкәр) – сөйләшүчән, *тө̄лөгөлө* (< түләгәле) – түләргә, *қо̄нтос* – кондыз, *қо̄зоқ* (< косык) – чикләвек һ.б.

*о – ө* авазларыннан соң килгән иҗектәге *а – ә* авазлары тараялар һәм иренләшү гармониясенә дучар булалар:

---

[1] *Тумашева Д.Г.* Язык сибирских татар (часть вторая). Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1968. С. 130–131.

[2] Шунда ук. Б. 132.

*сөйлөшкөле* < сөйләшкәле – сөйләшергә, *болғон* < болған – булган.

Әүштә-чат сөйләшендә палаталь гармония бозылу очраклары да бар: *айнәк* (диал. әйнәк) – күзлек, *әстаған* – кура җиләге, *чачәк* – чәчәк, циған – чегән, *сәксан* – сиксән, *булби* – булмый, *баради* < барады – бара, *ҕанди* – нинди, *шонди* – шундый, *ҕаймәләп* – кайма тотып, *көрдеңба* – күрдеңме, *ҕайнанәсенә* – каенанасына һ.б.

А в а з  ө с т ә л ү: *үсемер* – үсмер; *керет* – керт, *йөрө* – йөр; *мейә* – ми.

А в а з  т ө ш ү: *әшке* – әшәке; *баған* – багана.

**Дифтонглар.** Әдәби телдәге *-ый/-ий* дифтонгына әүштә-чат сөйләшендә дә, бөтен себер диалектлары һәм күп кенә урта диалект сөйләшләрендәге кебек, *-ай/-әй* дифтонгы тәңгәлләшә: *эшләй* – эшли, *мыйлай* – мияулый, *ҕалтырамай* – калтырамый һ.б. Сөйләштә III зат хәзерге заман хикәя фигыльләрнең *-а/-ә* кушымчасы да *-ай/-әй* дип әйтелә: *әйтәй* – әйтә, *ашай* – ашый, *сатай* – сата, *көтәй* – көтә, *парай* – бара һ.б.

Аерым сүзләрдә: *үгәй*.

*-ай/-әй* дифтонгы тарая һәм аңа *-ый/-ий/-ей* дифтонгы тәңгәл килә: *мелей* < бийәләй (бияләй), *пестийләргә* – бездәйләргә: *Бицәл баланыңҕы ҕул да йептий* (җептәй), *айаҕ та йептий* (җептәй).

*-өй* дифтонгы үзе кулланыла: *өй, сөйләй* – сөйли, *сөйәк* – сөяк һ.б.

Шуның белән бергә, *-өй* дифтонгына *ө* авазы тәңгәл килү очраклары бар: *сөләшәсең* – сөйләшәсең.

Ачык иҗек оештыра торган *и* авазына *-ей* дифтонгы тәңгәл килә; *ниндей* – нинди, *кейем* – кийем (кием), *дей* – ди, *күс тейгән* – күз тигән,

Ачык иҗек оештыра торган у, ү авазларына *-ıw/-ew* дифтонгы туры килә: *йıwып* – йуwып (юып), *сıwаҕ* – суwык (суык), *бıwылу* – буwылу (буылу).

**Тартыклар.** Әүштә-чат сөйләшендә тартык авазларның әйтелешләре һәм ясалышлары әдәби телдәгечә. Бары тик *ч* авазының кушык аваз булуын гына истә тотарга кирәк, ләкин

сөйләштә аның кулланышы бик чикле, чөнки аңа *ц* авазы тәңгәл килә. Д.Г. Тумашева хаклы рәвештә әүштә-чат сөйләшендә *ч//ц*, әмма *ц* беренчел булган булырга тиеш, дип яза[1].

Сөйләшкә хас фонетик үзенчәлекләр аваз тәңгәллекләренә һәм башка фонетик күренешләргә кайтып кала.

Сүз башындагы *б* авазы саңгыраулык элементы белән әйтелә: $^{n}$*бара* – бара. Мондый үзенчәлек татар теленең Башкортстанда, Оренбург өлкәсендә таралган сөйләшләрдә дә күзәтелә.[2]

Сузыклар яки саңгырау белән сузык арасындагы *б* авазының шартлаулыгы кимүе (*б*$^{w}$) яки бөтенләй *w* соноры белән тәңгәлләшүе күзәтелә: *цыб*$^{w}$*ы/ цыwы* – чыршы, *цубацақ/цуб*$^{w}$*ацақ/ цуwацақ* – әби, карчык һ.б.

Чагыштырыгыз: саз ягы сөйләшендә *б* > *w*$^{б}$ күренеше системалы рәвештә кулланыла[3].

***п* ~ *б*** сүз башында шактый системалы характерда: *пес* – без, *паради* – бара, *палық* – балык, *пал* – бал.

Татар теленең үз сүзләрендә борынгы *п* саклана: *йапрақ* – йафрак (яфрак), *кәлпәк* – калфак, *керпек* – керфек.

Бер төркем сүзләрдә исә *б* авазы, нигездә, саклана: *боға* – үгез, бала, *байлан/пайлан* – ак чыршы, *бок* – болын һ.б.

***б* ~ *п*** алынма сүзләрдә системалы характерда: *бахыт* – wакыт (вакыт), *бәйшәмбе* – пәнҗешәмбе, *бумала* – пумала, *байук* – паек, *бахта* < пахта – мамык, *бал'тә/бәлтә* – пальто, *былау* < плов – пылау, *бәдер* – диал. *пәтер* – әд. төче күмәч.

***п* ~ *ф*** алынмаларда да күзәтелә: *Сапийа* – Сафия, *Асқапийа* – Аскафия, *партук* < фартук – алъяпкыч, *кәмпит* – конфет, *зәғыйплек* – зәгыйфьлек.

***м* ~ *б***: *цемен* < чебен – озынборын, *моз/мус* – боз, *мелей* – бияләй, *моғол* – диал. *боғол* – чүмәлә, *мынаң/менәң* – белән,

---

[1] *Тумашева Д.Г.* Язык сибирских татар (часть вторая). С. 136.

[2] *Рамазанова Д.Б.* Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. Казань: Таткнигоиздат, 1984. С. 5.

[3] *Барсукова Р.С.* Заболотный говор тоболо-иртышского диалекта татарского языка в сравнительном освещении. Казань, 2004.

*мөрмәле* – бөрмәле, *таман* – табан, *тумық* – тубык. Шулай ук: *сапса/самса* – бөккән.

***з ~ с***: ике сузык уртасында күзәтелә: *күрәзең* – күрәсең, *теләзә* – теләсә, *пазып* – басып, *пулмаза* – булмаса. Мондый күренеш алтай телләренә хас.

Киресенчә күренеш, ягъни ***с ~ з*** да булырга мөмкин: *Қасан* – Казан, *төсәт* – төзәт, *үсем* – үзем, *қысылғат* – диал. *қызылғат* – кызыл карлыган.

*с* авазыннан соң килгән кушымчалар һәрвакыт саңгырау тартыкка башлана: *пескә* – безгә, *отысқалы* < отызгалы – утыртырга, *қосқын* – козгын. Төмән сөйләшендә һәм бараба диалектында да шулай ук.

***д ~ т***: *бәдер* – диал. *пәтер* – төче күмәч, *дурда* – турта һ.б.

***ж ~ ш*** ике сузык арасында: *пажы* – башы, *қыжсын* – кышын, *пежер* – пешер, *кеже* – кеше, *эжек* – ишек һ.б.

***ш ~ ч***: *бышқы* – пычкы.

***ң ~ н*** төрле сүзләрдә сүз азагында: *менәң/мынаң* – белән, чыгыш килеше кушымчасында: *қайтаң* – кайдан, *анаң* – аннан, *қалатаң* – каладан һ.б.; *сунаң* – соңыннан, *әзерләгәненнәң* – әзерләгәненнән, *қатыныннаң* – хатынынннан.

***қ ~ х: бақырқай*** < бахыркай – мескенкәй, *тәсбиқ* – тәсбих, *парқет* – бәрхет, *ақмақ* – ахмак.

Татар теленең үз сүзләрендә *қ* саклана: *йақшы* – йахшы (яхшы), *қәрендәш* < *қарындаш* – кардәш.

***н ~ ң*** аерым сүзләрдә (*ин* – иң: *ин әwәл*), II зат хикәя фигыль кушымчасында (*ашарсын* – ашарсың, *ташырсын* – ташырсың, *төртәсен* – төртәсең), иялек килеш кушымчасында (*минен* < *минең* – минем) күзәтелә.

Аерым сүзләрдә генә очрый торган тәңгәллекләр. ***б ~ м:*** *иске-босқы* – иске-москы; ***м ~ н:*** *тырмақ* – тырнак; ***н ~ л:*** *тешни* – тешли; ***ч ~ с:*** *ситча* – ситсы; ***ч ~ җ***: *чыназа* – җеназа; ***й ~ д:*** *Мөршийә* – Мөршидә; ***й ~ т***: *йомырт* – шомырт; ***ғ ~ қ:*** *тағайа* < такыя – бүрек; ***қ ~ ғ***: *йурқан* – йурган (юрган); ***к ~ г:*** *йекет* – йегет; ***х ~ к:*** *әрәхмән* – әрекмән; ***нд ~ мг:*** *түндәк* – түмгәк; ***ңл ~ ңг:*** *йаңлыш* – йалгыш (ялгыш); ***нт ~ нд:***

*ышантың* – ышандың; *минтәwәц* (менә мондый кечкенә генә) < мондый.

Аваз төшү. Әүштә-чат сөйләшендә икеләтелгән тартыкларның берсе кыскара: *элеке* – элекке, *анан* – аннан, *минән* – миннән, *қырбасыңба* – кырмассыңмы; *әлә* – әллә, *туның* – тунның, *артан* – арттан, *исү* – эссе.

*л* төшү: *йуғатты* – йугалтты; *р: йәшенеп* – яшеренеп, *бөкәйү* – бөкрәйү; *н: асат* – ансат; *асын* – анысын, *икә* – икән; *й: иләшү* – ияләшү; *ла*: *балай* – балалай – балалый; *ң*: *сунаң* – соңыннан; *й: йәтим-өтөм* – йәтим-йөтем (ятим-ятимә).

Аваз өстәлү. *т* өстәлү: *себертке* – себерке; *л: лунты* – унты (аяк киеме); *к: басмақ* – басма, *чанақ* – чана.

Кушымчадагы башлангыч *л* авазы үзеннән алда килгән тартыкларга (*п, қ/к, т, с, ш, ц, ч*) охшашлана. Күплек кушымчалары: *себерәктәр* < сибиряки – себер татарлары, *таныштар* – танышлар, *малайақтар* – малайлар – бала-чага, *сүстәр* – сүзләр, *циттәр* – читләр, *болғондор* – булганнар. *Цәцтәренә ишәди тәңкәне, өцтө, иккене – Чәчләренә ишә тәңкәләр, икене, өчне.*

Сүзъясагыч *-ла/-лә* кушымчасында: *йықта* – йокла, *эшти* – эшли.

Сүзъясагыч *-лык/-лек* кушымчасында: *көстек* – күзлек, *ағицтық* – урман.

Сыйфат ясагыч *-лу/-лү* (тат. әд. *-лы/-ле)* кушымчасында: *йапрақту* – яфраклы, *көцтү* – көчле, *истү май* – ислемай.

Рәвеш ясагыч *–лап/-ләп* кушымчасында: *йөстәп* – йөзләп.

Исемнәрдә: *йестә* – җизнә.

Тартыклардан (*п, с, қ/к, ш, т, ц*) соң килгән юклык (*-ма/-мә*) һәм сорауны (*-ма/-ма*; әд. *-мы/-ме*) белдерә торган кушымчалардагы *м* авазы *п* авазына күчә: *цықпады* – чыкмады, *көппә* – күпме, *пешпәгән* – пешмәгән, *эшетпәде* – ишетмәде.

Сонор (*р, л, ң*) авазлардан соң килгән шушы ук кушымчаларда: ***б ~ м:*** *болбос* – булмас, *болбоспо* – булмасмы, *аңғарбадым* – аңламадым, *албағаннар* – алмаганнар, *көрдеңба* – күрдеңме һ.б.

Уңай ассимиляция. *с, қ/к, р, п, т, ш, ц* тартыкларыннан соң килгән төшем һәм чыгыш килеш кушымчаларында-

гы *н* авазы *т* (сонорлардан соң) яки *д* авазы белән тәңгәлләшә: *халықты* – халыкны, *цәйнекте* – чәйнекне, *пестең* – безнең, *селәртең* – сезнең, *трактордың* – тракторның һ.б.

*Чишү* сүзендә *ш* авазы *ч* авазына охшашлана һәм *ц*-лаштыру нәтиҗәсендә *цицү* дип әйтелә.

Кире ассимиляция: *цөцө* – төче, *мим булдым* – мин булдым, *кәмпит* – конфет һ.б.

Диссимиляция: *қылбағыш* – көнбагыш; *бер ләт* – бер рәт һ.б.

### *Грамматик үзенчәлекләр*

**Исемнәр**. Әүштә-чат сөйләшендә исемнәрнең категорияләре, аларны белдерү ысуллары, нигездә, әдәби телдәгечә. Шуның белән бергә, кайбер аерымлыклар да күзәтелә.

Иркәләү-кечерәйтү формалары *-ақ/-әк, -цақ/-цәк, -ац/-әц, -қацақ/-кәцәк* кушымчалары ярдәмендә ясала: *малайақ* – кечкенә малай, *пер ибәцек* – аз гына, *улақ* – кечкенә балакай, улкаем, *чанақ* – кечкенә чана, чаначык, *орацақ* – кечкенә чокыр, *иркәцәк* – иркәчек, иркә, *берәүцәк* – бердәнбер, *қысцақ* – кызчык, *балацақ* – кечкенә бала, балачык, *улағац* – улчык, кечкенә малай, *қошқацақ* – кошчык, *бақырцағым* < бахыркаем – мескенкәем. *Бәбәй майына* (туена) *сөлгөчәк а* (алып) *кердем*.

Бу формалар барлык себер диалектлары өчен уртак. Болар белән беррәттән, татар әдәби теленә хас *-қай/-кәй* кушымчасын куллану очраклары да бар: *Бақырқай* (мескенкәй), *қайынсеңлем үлде умпиш йәшәр* (яшьлек). *Әтекәләре* (< әтекәй) *йуғ иде*.

Кеше исемнәрен кыскартып, кайбер очракларда аларга *-уқ/-үк, -ш* иркәләү-кечерәйтү кушымчалары кушып сөйләү күренешләре күзәтелә: *Шәхүл* – Шәйхулла, *Хәйрук* – Хәйрулла, *Нәсрук* – Насертдин, *Гайнук* – Гайниҗамал, *Фәйзүк* – Фәйзулла, *Көлчи/Көлчүк* – Гөлчирә, *Көмәй* – Гөлменәвәр, *Ситуш* – Ситдика, *Майнуш* – Маһинур, *Кәтәш* – Хәтирә, *Кәмиләш* – Камиләбану һ.б.

Әүштә-чат сөйләшендә дә *-ау/-әү* эндәшү килеше формасы күзәтелә: *Қайынсеңлем пар иде умпиш йәшәр, йенгәү* (җиңги) *генә тип йөртә иде. Абау* (апа), *мин балыққа барғам. Инәү* (әни), *атау* (әти) *тип цақырадаған* (чакырабыз).

II зат күплектә тартым кушымчасының диалекталь (*-ың-нар/-еңнәр*) һәм әдәби (*-ығыс/-егес*) формалары параллель кулланыла: *килүweңнәр//килүегес* – килүегез, *пақцаңнар//пакцағыс* – бакчагыз, *әйбереңнәр//әйберегес* – әйберегез һ.б. Мисаллар: *Үсеңнәрнең әйберегес барба?* – Үзегезнең әйберегез бармы? *Пабаңа сиксән йәш. Селәрнең бақцаңнарның* (сезнең бакчагызның) *балцығы әйбәт* һ.б.

Тартым кушымчалы исемнәрнең юнәлеш килешендә икеләтелгән кушымча алу очрагы теркәлгән: *Өстөңәргә* (өстеңә) *кийеңнәр, сыwақта йөрөйләр.*

Тартым кушымчалы исемнәр төшем килешендә угыз тибында да, кыпчак тибында да формалашырга мөмкин: *эшеңе/эшеңне, телеме/телемне* һ.б. Мәсәлән: *Түшмәктәреме* (түшмәк – сырып теккән җиңсез өс киеме) *салминча йөредем ийүнгә чақ* (хәтле). *Балаңы қарағынцық, қоромға күзе төшә.*

I һәм II зат тартым кушымчалары алган исемнәрнең төшем килешендә килеш күрсәткечләре кулланылмаска мөмкин: *Мин үс телем* (телемне) *дә белмим. Кәбәцең* (диал. *кәпәчеңне* – түбәтәеңне) *кимәдең пажыңа. Тамца-тамца йаңғыр йаwа, Бөркән шәлең* (шәлеңне), *тамғанцы* (халык җыры).

Килеш кушымчаларының әүштә-чат сөйләшендә ассимиляциягә дучар булуы үзенчәлекле: *палның/палдың, палны/палды* һ.б.

Чыгыш килеш кушымчаларында ***ң ~ н*** тәңгәллеге күзәтелә: *балдан/балдаң, Уралдан/Уралдаң, қалатан/қалатаң* һ.б.

Иялек килеше, әдәби *-ның/-нең* кушымчасы белән беррәттән, *-нықы/-неке* кушымчасы белән дә ясала: *Инамнеңке* (әниемнең) *йеңсес камзуллары бар. Кийәүнеңке туғаннары, быраты килә сауцы* (яучы) *булып. Аныңқы баллары – апалар* – Аның балалары укымышлылар. *Үсемнеңке улымныңқы қатыны тора* – Үземнең улымның хатыны тора.

Киресенчә, *-ның/-нең* иялек килеш кушымчасы хәбәрлек оештырырга һәм шул рәвешле әдәби телдәге *-нықы/-неке* кушымчасына тәңгәл килергә мөмкин. Бу бигрәк тә сөйләүченең яки тыңлаучының кайдан, ничәнче елгы булуы турында

әйткәндә күзәтелә: *Қазанның үзенеңме* (үзенекеме)? *Уникенце йылның* (елгы) *мин* һ.б.

Хәрәкәтне белдерә торган фигыльләр юнәлеш пунктын белдерә торган сүзләрне, юнәлеш килешендә түгел, баш килештә башкару очраклары күзәтелә: *Халық Себер* (Себергә) *кил* (килеп) *тулды, өрц* (өрцеп) *китте. Сату белән қала* (калага) *китеп бара идем*. Мондый күренеш татар теленең Урал төбәге сөйләшләрендә актив күзәтелә.

Компонентлары нисбәтлек мөнәсәбәтендә торган исем-исем сүзтезмәләрне (әнинең шәле, бакча капкасы һ.б.) кушымчасыз куллану: *Қасан қала* – Казан каласы, *пес йаққа* – безнең якка һ.б. *Сес йақта ниндей тормошлар*? *Қысты алып киттеләр, йекет йақта* (егет ягында) *той боло ғой* (була бит).

**Алмашлыклар**. Әүштә-чат сөйләше, аларның төркемнәре һәм грамматик категорияләре, функцияләре буенча, әдәби телдән, нигездә, аерылмый. Шул ук вакытта, себер диалектларына хас үзенчәлекләр дә чагылыш таба.

Зат алмашлыклары: *мин/мэн, бес/пес, сэн/син, селэр, у/ул, алар*. Мәсәлән: *Бик телле у, аны йиңәлмисең дә*.

II зат алмашлыкларының күплек формасы, әдәби телдән һәм татар теленең башка сөйләшләреннән аермалы буларак, күплек кушымчасы ярдәмендә ясала: *селәр/сэлер* – сез (чагышт.: шулай ук бараба диалектында да). Мәсәлән: *Селәр* (сез) *йасып алғалы* (аларга) *та өлгөрепсес* (өлгергәнсез). *Селәрдә ү дийәңнәрме*? – Сездә өй дияләрме?

I һәм II зат алмашлыкларының юнәлеш килеше *мәңа/ мағa/ маңа/миңә, сәңа/сағa/саңа/сиңә* формаларында ясала: *Саңа* (сиңа) *килдек. Сағa* (сиңа) *соқыр майған* (үрдәк) *керек. Маңа пирәй. Миңә өйләнде. Ул Мөнәwәрә миңа килендәш*.

Икеләтелгән кушымчалы форма да теркәлгән: *Дәптәреңнәр йетбәс иде, сийәргә* (сиңа) *сөйләгәле*. Чагыштырыгыз: бөре, златоуст һәм, өлешчә, минзәлә белән стәрлетамак сөйләшләрендә дә шулай ук.

Иялек килешендә кушымчаларның ассимиляцияләнүе күзәтелә: *Пестең* (безнең) *инәйлар элеккецә килгәннәр. Селәрде-*

*ке* (сезнең) *пабаңнар* (бабайларыгыз – әд. ирләрегез) *парба* (бармы)?

I зат *мин* алмашлыгы иялек килешендә *минең/минем/минен* формаларында ясала: *Минең* (минем) *өц малай, қыслар та шулай уқ. Минең* (минем) *әле оло пицем дэ пар урамта. Аның малайы әкәм* (абыем) *инте минен* (минем).

Иялек килеше кушымчасы төшәргә дә мөмкин: *Үзебес* (үзебезнең) *туғаннар Йәwештәдә* (ав. ис.). *Пес* (безнең) *йақта мөрмәле көйнәкләр кигәннәр.*

К ү р с ә т ү  а л м а ш л ы к л а р ы: *бу, у/ул, теге, анди* (андый), *мынди* (мондый), *шул, шонди* (шундый), *алый/алий* (алай), *анау, монау, әнәкә* (әнә), *менәкә* – менә, *анча* – андый. Мисаллар: *Ацқа тороп эшләдек, менәкә тормош! Менәкә қапқазы да. Әпләп* (алай-болай гына) *салғаннар да йешерелеп төшкән анча йаңғырларда. Менә у* (менә ул) *бақырцақ йөзгә йақын* (яшьтә). *Мона уңдый* (менә мондый) қайыш. *У* (ул) *кешегә йағым* (ягымлы), *матур күренер.*

*Үз* алмашлыгы II зат күплектә *-еңнәр* кушымчасы белән формалаша: *Периданны үзеңнәр беләсеңнәр* (үзегез беләсез).

Шулай ук: *береңнәр* – берегез. Мәсәлән: *Сес береңнәр* (берегез) *дә қайтпайсыс.*

Чыгыш килеш формасында сүз азагындагы *н* авазына *ң* тәңгәл килә: *монаң* – моннан һ.б.

III зат тартым кушымчасы алган алмашлыклар аергыч функциясендә кулланылырга мөмкин: *Йетәр инде ансы йыр* (ул җыр).

*Шул* алмашлыгы мөнәсәбәтле сүз буларак кулланылмый: *Инәм бик йарлы қалған, аңа күрә* (шуңа күрә) *пес уқый алмадық.*

С о р а у  а л м а ш л ы к л а р ы: *кем, ни* – нәрсә, *қандый/қанди/қани* – ничек, нинди, *қайтаң* – кайдан, *қайсы*, *қанца* – ничә, *ниндей* – нинди. Мәсәлән: *Әлә қанди* (нинди) *исем!? Қандий сөләшәсең? Айу қанди* (ничек) *йата? Қанца* (ничә) *палаң полты?*

*Қайсы* сорау алмашлыгы икеләтелгән тартым кушымчасы ала: *Қайсысының* (кайсының) *өйе боғорақ* (пычрак, җыештырмаган), *дийә.*

**Саннар**. Бу сүз төркеменең төп категорияләре ясалышы һәм кулланылышы белән дә әүштә-чат сөйләше әдәби телдән, нигездә, аерылмый. Бары тик кайбер саннарның фонетик яктан берникадәр үзенчәлекләре булуын гына күрсәтеп үтәргә кирәк: *пер/бер, өч/өц, төр(т)/түрт, йете/йеде, отыс* – утыз, *сиксан/сәксан* – сиксән һ.б.

Җыю саннарын микъдар саны функциясендә куллану очраклары теркәлгән: *перәүсе* – берсе һ.б.

**Сыйфатлар**. Әүштә-чат сөйләшендә сыйфатка хас грамматик категорияләр, сыйфатларның ясалу үзенчәлекләре, нигездә, әдәби телдәгечә. Шуның белән бергә, *-лы/-ле* кушымчалы сыйфатларның ясалышында үзенчәлекле күренешләр күзәтелә.

*-лы/-ле* кушымчасы үзеннән алда торган тартыкларга охшашлана. Шул ук вакытта *-ы/-е* сузыкларына *-у/-ү* сузыклары тәңгәлләшә: *атту кеже* – атлы кеше, *күшту аш* (*күшт* – ит) – итле аш, *пашту уқучы* – башлы укучы, *йапрақту себерке* – яфраклы себерке, *цуқты/цуқту* – чуклы, *ташту* (беләзек) – ташлы – әд. кашлы, *тәңкәлү күкрәкцә* – тәңкәле.

Сыйфатлар азагындагы *-ы/-е* сузыклары да *-у/-ү* белән тәңгәлләшә: *кецү* – кече, *иң олу* – иң олы, *қату* – каты, *үлү* – үле, *исү* – эссе.

**Рәвешләр**. Ел фасылларын һәм тәүлек вакытларын белдерә торган сүзләрдән вакыт рәвешләре төрле чаралар ярдәмендә ясала.

Әдәби телгә хас формалар: *Йәй көне қайта торған. Өйөм дә бар, эспүшкәм* (кечкенә өй, алачык) *дә бар, кәзә тыра анта қыш, йәй пес торайпыс. Қышын цана, шыңғырақтар* (кыңгыраулар) *мынан алып китәләр қысны. Мин иртәсе мән киләмен. Қышы-йәйе пима* (киез итек) *кийә. Қышқысын сауцы килгән бер-ике йома алғарақ. Көннөң озон анда булдым. Йәй wахытларда да суйалар. Хәзер йасый алмыйсың аны, йаз мәлләрендә кирәк.*

Сөйләштә *-дый/-дий (-дай/-дәй)* кушымчасы белән рәвешләр ясау актив: *Ратной баладий* (үз баласы кебек) *қарый баланы. Кежедий* (кешедәй) *ыцқанып* (тын алып) *йата инде ул.*

**Фигыльләр**. Затланышлы фигыль формалары. Хикәя фигыль. Әүштә-чат сөйләшендә хәзерге заманның берничә формасы бар.

*-а/-ә/-ый/-и* кушымчалы хәзерге заман, нигездә, әдәби телдәгечә: *барам/ барамын, киләм/киләмен; барасың, киләсең; бара, килә; барабыс, киләбес; барасыс//барасыңнар; бара(лар).* Мисаллар: *Суаҡ су менәң* (белән) *эцеп ҡуйам. Пес ҡалада эшлибес. Паганага йүкәлеп торазың* (сөялеп торасың). *Клупта йырлыйсыңнар бит. Анди ғошлар килә оцоп пес йаҡҡа. Тәңкәли кукрәкцәне күрсәтәсеңнәрбә* (күрсәтәсезме)? *Йеп менән өлчи белбимен* (үлчи белмим).

Көнчыгыш диалектларга хас *-ты/-те* кушымчалы хәзерге заман хикәя фигыль күбесенчә *-ди* формасында кулланыла: *аладим*, юклыкта – *албайдим*; *алайдиң – албайдиң*; *алади/алаты/алат*, күплектә *аладиләр/аладылар/алаттар.*

Шунысы характерлы, бу очракта III заттагы нигез форма (*ала*, *курка, бара*) *-ай* кушымчасы белән дә ясалырга мөмкин (*алай* – ала, *ҡурҡай* – курка, *парай* – бара һ.б.) һәм аңа *-ди* күрсәткече ялгана. Берлектә – *алайди*, күплектә – *алайдиләр*. Юклык формасы: *пелбәй* – белми, *пөтөрбәй* – бетерми, *албай* – алмый һәм шуларга *-ди* күрсәткече ялгана: *пелбәйди, пөтөрбәйди, албайди*. Мисаллар: *белбәйдем* (белмим). *Торага парайдиләр* – Шәһәргә баралар. *Алар ҡалада эштидиләр* (эшлиләр). *Палыҡ эләгәйдиме* (эләгәме)? *Өц йәше тулай. Мос ағай* – Боз ага. *Бестең* (безнең) *тел аңлашылай. Килен, балам, ғына дийәде* (ди) *ҡайнам паҡыр* (бахыр – мескен).

Чат урынчылыгында II зат күплектә *-сыңнар* кушымчасына *-ңнар/-ңдар* кушымчасы тәңгәл килергә мөмкин: *Селәрдә ү дийәңнәрме?* – Сездә өй диясезме? *Ни әйт+утыраңдар?* – Ни сөйләп утырасыз? *Пахриныҡы ҡызы цыҡты, ҡайтыб утыраңнарба, дийәди* (кайтып киләсезме, ди).

*-ай* формасы әүштә урынчылыгында активрак, ә чат урынчылыгы өчен күбесенчә *-т (алат)* кушымчасын куллану характерлы.

Бу формаларның мәгънә аерымлыкларын сиземләве авыр, һәм алар, еш кына, бер үк вакытта бер үк кеше тарафыннан бер

үк мәгънәдә кулланылалар, нәтиҗәдә аларның контаминацияләре дә барлыкка килгән.

Шушы мизгелдә, сөйләү барышында башкарыла торган эшне белдерә торган хәзерге заман *-п + утыр/отыр* ярдәмче фигыле белән ясала. Әүштә-чат сөйләшендә исә ярдәмче фигыль *утыр* вариантында гына кулланыла һәм аның төрләнеш парадигмасы да үзенчәлекле: *утырым/утырмын, утырсың/утырзың, утыр/утыры* (соңгысы сирәк); *утырбыс, утырзыңнар, утыр/утырылар*. Мәсәлән: – *Әй, қайтаң қайтып утырзыңнар* (кайтып киләсез)? – *Мен охотадан* (аудан) *қайтып утырмын* (кайтып киләм). *Нишләп утырсың* (нишлисең)? *Килеп утырылар* (киләләр).

Шушы ук хәзерге заманның катлаулы формаларын да куллану очраклары бар. Алар *йади/йаты, йадыр/йадар* < *ят-, тор-* ярдәмче фигыльләре белән ясалалар: *Оқып йадарзыңнар*? – Укыйсызмы? *Ул кил йаты* – Ул килә. *Йоғысы кел тор* – Йокысы килә. *Тис-тис базып йестәм килеп йата* – Тиз-тиз басып җизнәм килә. *Йатып йатам* – Ятып торам. *Тор-* ярдәмче фигылен куллануны Д.Г. Тумашева калмак сөйләше йогынтысы дип саный[1].

Б и л г е л е  ү т к ә н  з а м а н, әдәби телдәгечә, *-ды/-де, -ты/-те* кушымчасы белән ясала. Төрләнеше буенча да бары II зат күплектә генә аермасы бар: *алдыңнар/алдығыс* (формасы) / *алдыңыс* (ягъни иске татар әдәби телендәгечә). Мисаллар: *Анда булдыңысма? Бескә қунаққа килдеңнәрба* (килдегезме)? *Барабинкада кемдә булдығыс? Киҷә қалаға бардық.*

Б и л г е с е з  (н ә т и җ ә л е)  ү т к ә н  з а м а н, әдәби телдәге кебек, *-ған/-гән* кушымчасы белән ясала, тик төрләнеш парадигмасында аерымлыклар күзәтелә: *алған/алғам; алғансың, алған; алған/алғабыс/алғанбыс; алған/алғансыңнар/алғансыс, алған/алғаннар*. Мисаллар: *Түккәм* (түккәнмен) *дә а* (алып) *кереп қуйғам* (куйганмын) *чиләкне. Қысыңны ашатпағансың. Бигрәк*

---

[1] *Тумашева Д.Г.* Язык сибирских татар (часть вторая). Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1968. С. 141.

*йақшы әдәмнәр икәнсеңнәр. Бесneңке қалықны чат қалық дип атағаннар. Отыс тоғыс йәшемтә қалғам бабайдан. Туғабыс, үскәбес.*

II зат берлек һәм күплек санда икеләнүне, фараз итүне белдерә торган *-дыр/-дер* кисәкчәсе зат кушымчасыннан алда ялгана: *Син дә килгәндерсең* (килгәнсеңдер) *әле*.

Нәтиҗәле үткән заманның *-ып/-еп* формасы да әүштә-чат сөйләшендә актив кулланыла: *Онытыпмын* (онытканмын икән) *қуштанлы* (балитәкле) *күлмәкләр дә төймәле була иде. Сабырланған хәзер, өйгә доғалық қуйып* (куйган).

Күптән үткән заманның ике формасы күзәтелә. Беренчесе, әдәби телдәге кебек, *-ған/-гән/-қан/-кән + иде* формасында ясала. Аның төрләнеше дә әдәби телдәгедән аерылмый: *алған идем, алған идек, алған идең, алған идегес, алған иде, алған(нар) иде*. Мәсәлән: *Пескә батинкылар, шақмақ күлмәктәр апқайтқан иде*.

*-даған* сыйфат фигыль һәм *ите* ярдәмче фигыле белән ясала, эш яки хәлләрнең гадәти булуын, кабатланып торуын белдерә, әдәби телдәге *-а торган иде* формасына туры килә: *Бабай пастушит қыладаған ите* (көтү көтә торган иде). *Өйгә қайтқанда икедә қайтадағаннар ите* (кайта торганнар иде).

Галимнәр әүштә-чат сөйләшендә тагын гадәти үткән заман формасын күрсәтәләр. Ул *-адаған/-отоғон* (*-а торган*) формалы хәзерге заман сыйфат фигыльгә нигезләнеп ясала.

| М.А. Абдрахманов: | Д.Г. Тумашева: |
|---|---|
| берлектә | |
| *баратағам* | *баратағам/мин баратаған* |
| *баратағазың* | *баратағанзың* |
| *баратаған* | *баратаған* |
| күплектә | |
| *баратағабыс* | *баратағанбыс, бес баратаған* |
| *баратағанзынғар* | *баратағанзыңнар/ баратағансыс* |
| *баратағаннар* | *баратағаннар* |

Бу форма үткән заманда даими булып торган, гадәти булган эшне белдерә. Мисаллар: *Пес анда барадаған. Боронғо заманны мин қайдан беләдоғон. Барбыйдағансыңдыр? Син бескә кердәдгәнсең, ник йуғал* (югалып) *киттең? Мамайлар* (карчыклар) *бөреге булатаған киң қонтослы* (камалы). *Әүүәл сауцыға баратағаннар, килешеп қайтадағаннар. Әйкүлдә* (хәситә) *көмеш тәңкәләр, ташлар* (кашлар) *була торған. Сару аwыруға тәблитке йасыйдығаннар. Йортцом* (каенем) *көн дә су қойадаған* (сибә). *Инәм сөлидегән, қуллары талып беткән. Ыштанны пес кийә тығамбыс балақту, оцонда куштан, ыцңыр дийәләр, озон бау, төбө киң. Пашниктар бар иде, қолагы озын, башқа кийә тоғаннар. Наза-наза уйныйдағамбыс. Қашығыс қара цийә, дип йырлап қуйадагамбыс. Йорцо дийәдгәгәм. Татар уйыннары әйбәт буладоғон, кыруг уйный идек.*

Тәмамланмаган үткән заман, әдәби телдәге кебек, *-а/-ә + иде* (сөйләштә: *ите*) формасында ясала: тик ярдәмче фигыль саңгыраулашкан вариантта да була. Мисаллар: *Атам балық көтөнә ите. Кецкенә цақта уғомадым, сумканы қарға қөм* (күмеп) *қуйа итем, әйдә уйнарға. Элек була ите қуштанны күлмәктәр, матур ите, мин кидем аны. Цәц толымын линтылаб ишә итек.*

Билгесез киләчәк (хәзерге-киләчәк) заман, әдәби телдәгечә, *-ыр/-ер* кушымчалы сыйфат фигыльгә нигезләнеп ясала, юклыгы: *-мас/-мәс*. Төрләнешендә I зат берлек сан тулы (*алырмын*) һәм кыска (*алырым*) вариантларда күзәтелә; II зат күплек сандагы формасы да аерыла: *алырсыңнар* (юклыкта – *алмассыңнар*). Мисаллар: *Сөйли дә белбәс. Әй, күкәм* (сеңел), *син қайан қайтырзың*? *Пабам эшләп бөтөрбәгән эшне мин эшләп бөтөрмәм. Қурам* (кичен) *барарым. Анда барсаңнар, йазарсыңнар әле. Мин селәргә сөйләрмен. Әйтерсеңнэр, Цәләй пабай йебәрте тийәрсес. Өлгөрмәссес йасып алғалы та* (алырга да). *Уйладым, гел йәш кенә йөрәрменме. Утыртарсың белбәсә. Йулда ашарсыннар* (ашарсыз), *исән булсаң.*

Сөйләштә *-ғалаң/-гәләк* формасын куллану очраклары күзәтелә: *Әле хәзер барғалақ мин* – Әле хәзер барырмын мин. *Бөгөн кицкесен күргәләк* (күрермен).

Ф и г ы л ь  д ә р ә ж ә л ә р е. Әүштә-чат сөйләшендә эшнең кабатлануы әдәби чаралар (*-ғыла/-гелә,-штыр/-штер*) һәм кайбер очракларда *-ықла/-еклә* кушымчасы белән белдерелә: *Ой, анийым, дийә, йөгерекли. Мән имнәштергәм* һ.б.

Ю н ә л е ш л ә р. Төп юнәлешкә кайтым юнәлеше тәңгәл килү очраклары бар: *Палық тотонам* – Балык тотам. *Атам балық көтөнә иде* – Әтием балык тоту белән шөгыльләнә иде. *Базарда сатынып* (сату итеп) *қайтам*.

Бер юнәлеш урынына икенче юнәлеш формасын куллану: *Қалаға китешеп* (китеп) *қалайлар* (калалар) *пөтөнесе. Әйбер көп килсә, ул көнне сатышпас* (сатмас). *Хәйерне бала-чағаға өли* (өләшә) *дә чыға. Суwыды* – Суынды. *Суwымаған* (суынмаган) *әле саңзасы* (камыр ашы, пәрәмәч), *қайнар*.

Йөкләтү юнәлешендә *-с* авазына беткән тамырларга *-қыр/-кер* кушымчасы ялгану: *Инәсе үскерде* (үстерде), *атазы үлте дә*. Чагыштыр.: *үскерде, сизгерде* һ.б. татар теленең урта диалекты пермь сөйләшендә дә.

*Мендерү: Сунаң* (соңыннан) *өй башына мендереп қуйалар икә қурчақтарын, қурчақ көтәр булганнар*.

Б о е р ы к  ф и г ы л ь. II зат берлек сан *-ғыл/-гел* кушымчасы ярдәмендә ясала, ул әдәби вариант белән параллель кулланыла: *Қулың белән биргел мәңа. Уқыдық, дигел, хатыңны*.

II зат күплек сан *-ыңнар* кушымчасы белән ясала: *Алар йаңына парып килеңнәр* (килегез). *Арбыйча эштәңнәр* (армыйча эшләгез). *Қайтсаңнар* (кайтсагыз) *сәләм әйтеңнәр* (әйтегез). *Әйдәңнәр, кереңнәр* (әйдәгез, керегез).

*-ың/-ең* кушымчасы, хөрмәтләп мөрәҗәгать иткәндә, II зат берлек санда да кулланылырга мөмкин: *Айшәгә әйткән идем, ницек булса да килең, дип*.

Т е л ә к  ф и г ы л ь. Әүштә-чат сөйләшендә әдәби телгә хас теләк формалары кулланыла.

I зат, әдәби телдәге кебек, *-ыйм/-им,* күплектә *-ыйқ/-ик* һәм тагын *-ыйқлар/-икләр* кушымчалары белән ясала: *Мин бар* (барып) *қайтыйм. Чәй эчеп алыйқлар. Тынанып* (ял итеп) *алыйқ*.

Сөйләштә каргау формасы да, әдәби телдәгечә, *-қыры/-гере* кушымчасы белән ясала: *Ай, муйының цыққыры.*

Эчке теләк *-ғы/-ге + кил-* формасы белән белдерелә: *Ашағым* (ашыйсым) *килә. Сөйләшкесе* (сөйләшәсе) *килми. Сөйләгебес* (сөйлиәсебез) *килми. Қысны байға биргесе кели* (бирәсе килә). *Синең үлгең килми* (үләсең килми). *Уха ашағым килеп* (ашыйсым килеп) *йөргән идем.*

*-асы/-әсе + килә*: *Үләсе килми дә инде, тағы бераз йәшәсәм иде.*

Әүштә-чат сөйләшендә ният *-ғалы/-гәле + итә* (яки *йады*) формасы белән белдерелә: *Йасқалы итә* (язмакчы була). *Эцемә сикергәле йады* (эчемә сикермәкче була). *Мәчет салғалы ителәр* (салмакчы булдылар).

Затланышсыз фигыль формалары. Инфинитив. Әүштә-чат сөйләшенә инфинитивның, барлык себер диалектларындагыча, *-ғалы/-гәле* формасы хас: *Кер йуғалы* (юарга) *кирәк, ийне ақтағалы* (акларга) *кәрәк. Қул себергәле* (сөртергә) *цөпрәк барба* (бармы)? *Пер йыл дигәнце суға цумғалы* (чумарга – су коенырга) *йарамый. Нишләгәле кирәк*? – *Торғалы кирәк. Сару аwыруға соло сыwы эцергәлү кэрэк* (эчерергә кирәк).

*-ғалы/-гәле* формасы әүштә-чат сөйләшендә әдәби телгә хас *-ырға/ -ергә* кушымчасы белән параллель кулланыла. Мәсәлән: *Тынанырға кирәк.*

Сөйләштә инфинитивның *-уға/-үгә* формасы да бар: *Селәр йөрүгә* (йөрергә) *цыққан.*

*-мақ/-мәк: Йар бирмәк – йан бирмәк.*

Исем фигыль әүштә-чат сөйләшендә дә әдәби телдәге кебек үк *-у/-ү* кушымчасы белән ясала: *Килүwеңнәргә* (килүегезгә) *ничә көн*? *Айылдан айылға йөрү икән. Сеңел йуқ дип әйтү йуқ.*

Сыйфат фигыль. Әүштә-чат сөйләшендә сыйфат фигыльнең түбәндәге формалары кулланыла. *-ған/-гән* (үткән заман сыйфат фигыль): *Сықтамаған палаға пирбэйделәр* (бирмиләр).

*-ыр/-ер*: *Малайлар да анта*, *қыстар да анта, бармақ төртөр урын қалбой. Қайтыр бахыт йетте. Йупкысының йамар йере дә йуқ.*

Бу форманың исемләшүе күзәтелә: *Андый атай булайбы* (буламы) *дип, үләрдә* (үлгәндә) *балаларына әйткән.*

Күргәнебезчә, мондый очракларда *-ыр/-ер* формасы *-ған/-гән* формасына туры килә.

*-адаған/-атаған/-атқын* – әд. *-а торган*: *Аж пыжыратаған чугун* – Аш пешерә торган чуен. *Пецән цабадаған қарттар* – Печән чаба торган картлар. *Қату аwырды, сөйлидәгәнем бик күп. Өйләре сап-сары йыwып қуйатығын. Бу доғалык цәцкә тағадығын.*

Х ә л   ф и г ы л ь . Әүштә-чат сөйләшендә дә хәл фигыль формалары, нигездә, әдәби телдәгечә. Аларның формалашуында исә кайбер аерымлыклар да күзәтелә.

Тезмә фигыльләрдә *-ып/-еп* кушымчалы хәл фигыльләрнең грамматик күрсәткече төшә: *Ни әйт утыраңдар*? – Ни әйтеп (сөйләп) утырасыз? *Қалықтың эштәп йатқаны көрүн тора* (күренеп тора). *Син бескә керәдәгәнсең, ник йуғал киттең* (югалып киттең)? *Аwыр китте* – Авырып китте. *Аал кил* – Алып кил. *Пүгрәпкә майлар төшөр қуйдым* – Базга май төшереп куйдым. *Пыйыл ашлықтарны иртә цәц қуйдық* (чәчеп куйдык). *Циткә парып қар торам* (карап торам). *Мәйсә мама* (әби) *өйдәбә, йуқпа, белмим, хәзер а килерләр* (алып килерләр). *Кер* (кереп) *китәмен дә көләмен. Аны да а* (алып) *кердек. Йөгер* (йөгереп) *йөргәндә күргән. Саwытқа тутыр* (тутырып) *қуйасың.*

*-ганчы/-гәнче* формалы хәл фигыль сөйләштә *-ғынцы/-генце, -ғынцық/-генцек* вариантларында кулланыла: *Аш пешкенце* (пешкәнче) *тынаныып алың* (ял итеп алыгыз). *Қонақтан қайтқынцық малайы аwырған. Маңғайына күмер сөртә, балаңы қарағынцық, қоромға күзе төшә.*

Мондый диалекталь вариантлар бигрәк тә татар теленең мишәр диалектына хас.

Бу формаларның юклыгы *-мый/-ми/-бый/-би, -мыйца/-мицә; -быйца/-бицә, -мыйцы/-мице, -быйцы/-бице* кушымчалары белән формалаша: *Анча йырың булып йаздырбай утырасың. Басалбыйцы утыра биг озақ. Эшләмиче тормыш пулбай. Пимасын салминча йөрөте.*

*-ғач/-гәч* кушымчалы хәл фигыльнең төрле фонетик һәм аналитик вариантлары күзәтелә: *Алтын бырошкалар була иде, суғыш башталғац ыздайт иттек. Цабынған соң (чабынганнан соң) аwырасың ахырысы. Атам мынан инәм биреп қуйғац, ыризамын, дигән. Қурыққансең* (курыккач) *ул цәцрәп төшкән иде.*

**Ярдәмлек сүз төркемнәре. Бәйлекләр.** Әүштә-чат сөйләшендә әдәби телдә кулланыла торган бәйлекләрнең барысы да табыла. Тик аларның фонетик яктан аерымлыклары күзәтелә. Мәсәлән, *мынаң/менәң/ ман/бән/пән/белән* – белән, *чақ/цақ* – чаклы, *табатан* – таба, *хәтлек* – хәтле, *сайы/сайын* – саен һ.б. Монда тагын татар сөйләшләрендә еш очрый торган *була* бәйлеге дә теркәлгән.

Кайбер мисаллар: *Қасанға табатан (таба) пер қалата тора иде, шунда үл қалты* (үлеп калды). *Йәйгә чақ* (чаклы, хәтле) *аwырды. Иртә бән* (белән) *үлеп тә қуйды. Тын* (беренче) *цәчен алалар қырығына хәтлек. Күз йәше менән үлде, атазы қырық пиштә генә үлде. Кеше сайын өләп* (өләшеп) *йөри. Былафкыны энә йагы ман асқа қуй. Қайнанәсенә килә бақчаларына була* (бакчасы хакына).

**Кисәкчәләр**. Сорау кисәкчәсе *ба/бә/ма/мә/бы/бе/мы/ме* вариантларында күзәтелә: *Кәлбәйсеңбә?* – Килмисеңме? *Көрдөңнәрбе?* – Күрдегезме? *Йаулық қызылба, йәшелбә*? – Яулык кызылмы, яшелме? *Йәтим үскән баласыма* (баласымы) *бу? Қалпақтар болодоғон, селәр күргәнмә*? – Калфаклар була торган булган, сез күрдегезме?

Әүштә-чат сөйләшендә дә *ғой/ғуй/қой/қуй* раслау кисәкчәсе кулланыла: *Тегенцеләр теккәннәр ғой толоп тоннорны* – Толыпларны тегүчеләр теккәннәр бит. *Элек була иде қуй* (бит) *қуштанны* (бала итәкле) *күлмәктәр, мин кидем аны*.

### *Лексик үзенчәлекләр*

Әүштә-чат сөйләшенең үзенчәлекле лексик-семантик системасы формалашкан. Биредә диалекталь лексиканың кайбер тематик төркемнәрен кыскача гына күрсәтеп үтик.

Рухи мәдәният һәм йолалар беләнбәйле сүзләр: *сауцы* – яучы, *бау тоду* – килен төшергәндә ат юлына аркылы бау сузу һәм бүләк алу, *чақыртуға йөрү* (чагышт.: стрл., минз. – *чакыруга бару* – кыз ягына туй көнен билгеләргә бару) – коръән ашына йөрү, *қырықлау* – үлгән кешенең 40 ын уздыру, *қыз йыйылышы* – аулак өй, *қыз бикләү* – кыз куенына керү, *теләүле аш өсте* – ант итү сүзе, *бәбәй майы* – бала тугач уздырыла торган мәҗлес, *сип* – туйда кода-кодагыйлар тарафыннан каршы бирелә торган бүләк, *йыйылыш* – мәҗлес, *қурчақ тиргәү* – курчакка табыну (*алар қурчақ тиргәп ғомер иткәннәр*), *үбә* – өрәк һ.б.

Туганлык-кардәшлекне белдерә торган сүзләрдән түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин: *аба* – апа, *малайақ* – яшь бала, *мама* – үзеннән олырак булган кыз туган яки чит хатынкыз, *тәтә* – эти, *күкә* – 1) эне яки сеңел, 2) үзеннән кече теләсә нинди кешегә эндәшү сүзе, 3) иренең сеңлесе; *абалы-күкәле* – апалы-сеңелле, *йорцо* – иренең яки хатынының энесе, *балдыс* – иренең яки хатынының сеңлесе, *йестә* – җизни һ.б.

Кешене сыйфатлый торган сүзләр: *йегет* – уңган, булдыклы (*қатын йегет иде, бөтөрәсен эшләй*), *гырижа кыцқыру* – бүсер өянәге, бүсернең авыртуы, *сүзмәкәр* – сөйләшүчән, *пицәл* – рахит, *нәкәс* – гамьсез (бала турында), *йүткерек* – туберкулез; *кип* – кыяфәт (*үлгәч тә кибе позылмады*), *тынану* – ял итү, *тезә* – тез, *йабыз* – тәбәнәк, *цығанақ* – буын, *тартылу* – тотлыгу, *терсәк* – арпа (күздә), *танғай* – аңкау, *тилә* – үкчә, үкчә асты, *тумық* – тез капкачы; тубык сөяге; *ныжы* – кәчеркә, *цымца бармақ* – чәнчә бармак, *табац* – уч төбе, *төндөр* – чукрак һ.б.

Хуҗалык эшләре: *йороқ* – кәтүк, *тап* – йомычка, *қап* – капчык, *моғол* – чүмәлә, *нәҗүм* – тирес, *герәдә* – 1) яшелчә бакчасы, 2) түтәл; *гөрсемән* – ишкәк, *цадырық* – чардуган һ.б.

Йорт-җир, каралты-кура: *аран* – абзар, *шыңғырақ* – кыңгырау, *типше* – җәенкерәк күәс, *төйөз* – туз савыт, *көпкә* – (җылы) абзар, *сәке* – киштә (полка) (*сәке йасап йуғары қуйасың әйбер-қараны*), *күшәгә* – чаршау, *сәкәлүк* – уклау, *аш тақтасы* – куна тактасы, *чара* – җилпуч, *кәзүңке* – чолан, *көликә* – кисәү

агачы, *табатан* – таба, *күмер қайғысы* – кыскыч, *синәк* – веранда, *аграт* – ишегалды (чагышт.: урта диалектның пермь сөйләшендә дә шулай ук) һ.б.

А ш - с у белән бәйле сүзләр: *былау* – плов, *лүпсә* – кипкән шомыртны иттарткычтан чыгарып, шикәр кушып ясалган ашамлык, *шөпшәрә* – пилмән, *цамца//саңза* – торпоча*, аш* – токмач, *орбақ* – көрпә, *пирәженик* – ярты таба зурлыгындагы пирог, *хәлвә* – камырын токмач рәвешендә кисеп ясалган чәкчәк, *чемелдек* – сызык *(хәзер туйымнық, чемелдекне ашамыйлар), бәдер* – төче күмәч, черек бәрәңге күмәче, *пыштак* – эремчек, *туражжа* – чүпрә, *чуwәлә* – пирог, бөккән һ.б. ясау өчен, кунага куеп чыккан камыр кисәге һ.б.

К и е м - с а л ы м н ы белдерә торган сүзләр: *кибәц* – түбәтәй, *тағайа* – бүрек, *күгезмәк* – жилет, *байбақ* – оек, *арты йырмачлы* – арты ерык (юбка), *лунтай галуш* – тукыманы сырып эшләнгән һәм галош белән киелә торган аяк киеме, *чәрки* – күн аяк киеме, *уйықлы пима* – чуар итек, *әйкәл* – хәситә, *эцқор* – билбау, *миләй* – бияләй, *куштанлы көйнәк* – балитәкле күлмәк һ.б.

Т е р е к һ ә м т е р е к б у л м а г а н т а б и г а т ь белән бәйле сүзләр: *бок/бөк* – кыр, басу, *қаған* – вак агачлы алан, *утырац* – әрәмәлек *(тойоқ йәй йөрдөләр сыйырлар утырацта), қойо* – бәке; *апсақ* – усак, *этпорон* – гөлҗимеш, *йоморт* – шомырт, *күгемә* – кара җиләк, *мәшкә/куй* – сарык, *йола* – кикрик, *мыжық* – песи, *боға* – үгез, *торбоқ* – тана бозау, *чалғай* – кычыткан, *қаштақ* – пешмәгән (җиләк, карлыган һ.б. турында), *қызық* – кедр (агачы һәм чикләвеге), *пыйас* – суган һ.б.

### *Сөйләү үрнәкләре*

**Тормыш-көнкүреш.** Бездийләр қайа мал тотабыс. Ат сойсалар қазы йасағаннар, кем тутыра күшне (ит) тостыйсың, арт эцәгенә тығасың, сарымсақ саласың, қазылығын бергә тығасың, күппә кәрәк йасыйсың та өй башына эләсең. Итмәктеңке азытқызын алып қаласың, ағац куwашна, ләгән тә тибес, апсақтан (усак) йасаған. Олу пичне йағасың, бумала ман, себертке мән себерәсең ике қат, элеке пиц суқма (балчыктан сугылган) булған,

төрт қалац, төрт кәрәлкә (кош рәвешле кабартма) тығасың. Қалацны аунатып табада күптерәсең. Қызартқа қойасың (куясың, калдырасың), көмереңне тартып, итмәк бешби.

Сөтне әйләндерәм, тыварук йасыйм, әчеки (корт, кызарганчы кайнаткан эремчек) қайнатам.

Чиған итәктү (киң, озын итәкле) көйнәк кигәнем йуқ, қуштанну (бала итәкле) көйнәкләрне күргән. Палларым берсе қорсақта қалды, йер чоқоп ашатып үскердем, йестәм (җизни) тә боулышты. Қәсер йақшы. Һәрберсеннән аwыз итеңнәр, қайсысын йаратсағыс ашағыс. Инәмнеңке элек целтерли-целтерли (тәңкәле) йеңсес камзуллары бар иде, целтерәктү. Уйықлы-уйықлы (каюлы) иңече (инеч) әле дә тора, атуны (мәсех читеге) мамамнар кейә, мәсиқ үтеге (итек) була ату, тамaны (табан) йоқа ғына ицектеңке (читекнең).

Әлқой (хәситә) болодоғон қыйық, монта аста доғалығы, инәмнеңке дә бар иде, мамамнынқы (әбием) да, қыйыққа тора ул көйнәк өсөндә. Қыйық (косынка) та була, қыйықты бәйләп йийа да цац көргәзбәскә, анан йаулықты бәйли, қыйық тибес, өц мөйөштү (почмаклы). Қалпақ пәрқеттән, төрлүцә энзеләр теккән. Пестийләргә ләкмәде, соуғыш цығып, аwырцылыққа ләккән без. Қара йебәк шәл була торған. Партук, түшле партук бәйләгән, камзул кигән. Қышын тун кийә дә қара қор (билбау) бәйләп қуйалар иде қара таwардан. Ирәннәр тағайа (бүрек), сырма цалбар. Мамай, бақыр, өстөңәргә кийеңнәр дийә иде, сыwақта (суык) йөрөйләр. Қалаға барса – толоп тон, аны тегенцеләр теккәннәр. Минең бабайның атасы қайнатам кийә иде толоп тоннардан. Поцқақ тун була тийен қойырығыннан, төлке айақларыннан қорап теккән. Йақасы утырма йақа түгел, қайырма. Қайырма йақалар да булған. Қыйыш йақа кийәләр иде бит элек, ирләрнеңке көйнәктә, цигеп қаптырып қуйалар иде. Шәлләр төмән төрле, цуқлы шәл, йебәк шәл, мамық шәл, күптермәләрдә (ефәк шәлнең бер төре, бәйләгән, бизәкләре кабарып-кабарып тора) байларда була торған,зур шәлне қышын қайа булса барса, йабынып цанаға оутырып. Аwылда бөтен кешедә дә йуқ ол. Бишмәтне бахта (мамык) ман сырғаннар, Рәwефтеңке бишмәтен

күрсәтәйен қәзер. Наски, бийәли, пирцәткә сес йақта да бар булыр. Байбақны бер инә менәе бәйләсәң йылы була, ишшу пима да кейәсең, өстеннән чуни кидек эшкә барғанда. Быйылғы эш изәнгә (иртәгә, киләчәккә) қалмый, эшләгәле кирәк.

*Сөйләүче: Аванеева Нурия*
*Шәрәфи кызы (1928 елгы),*
*Умавыл*

Йәй бахыт цебен оторған қолағына, цықпай дей, аwыста теш йоқ, йырла сиңә. Сабийа абай (апай) йырлап пирәрсең әле таwышың булбаса да. Қурқыйм, алты балаң белә күз йәшендә торарсың, айағы имгәнде атқа атланып, төшкәндә. Нәнәү, үләм тей, чалбарын кисеб алдық, гүш (ит) цыққан айақныңқы. Машинә килде, кеем барай тағын? Тезәсе, балтыры, күше (ите) айырылып тора. Қәсер йөрей инте. Мин қазанныкца (казаннарча) йырлыйм. Морат бит хәрендәшең йақын. Син кемгә йақын монда? Сәкинә тужы қазаннық.

Қартлар уқый қор'ән. Туғацлар (кечкенә кабартма) бежерәләр, самза (чәкчәк), урама (торпыча). Аш ашыйлар, ипи қуйалар. Қуй иттән дә, сыйыр иттән дә бежерәләр, аш (токмач) кисәләр, озон аш та (токмач) кисәләр, шақмаг аш (салма) та кисәләр. Хәйерне бала-чағаға өли (өләшү) дә чыға.

Аулақ өйләр болған. Қыз йортында атайнәләр китеп қалса, малайлар да анта, қыслар да анта, бармақ төртер оурын қалбый, пәличләрне араннан кереб алалар малайлар.

Эрәғәтем (рәхәтем) килеп торай үзегезгә, йаратам мин кешене. Инәм, бақырым (мескенем), әйтә иде: И балам, кем генә ишегең ацып керсә, итмәк-тозоң, йөзөн йақты болсын, цәйең қайнап торсон, дийә иде мәрқүм. Күз йәжем менән үлде, атазы қырық биштә генә үлде.

Инәм сили дегән. Тон (беренче) цәцен алалар қырығына хәтлек. Инәм унбер йыл күзе йуқ (сукыр) утырды. Абзыйым бар иде, бер суткәнең эцендә йан бирде, йеңәмнеңке дә қәле аwыр, зур әкәмне цақыртыб алдым қайтар (үләр) wахыт. Асат аwыру, асат үлем бир, бер Аллам, дийә иде. Шундый сүсләр сөйли иде,

бақырцағым. Йөрәкәм, хәзер әйтәм. Избушканы (ишек алдында кечкенә өй) эшләргә итәләр, ой, анийем дийә, йөгерекли. Кендегәц әби дә килеп йетте. Иң беренче қызымның малайын қырықладық (бәби туе ясау, ул, гадәттә, балага 40 көн булгач уздырыла торган булган), беренче вынугымны қырықладық. Арты-арты ике бала булып қуйды.

Бозомны қарауцылар (дәвалаучы) бар. Мәйетнең сабынын урлыйлар икә, суғышқан ирне йуwындырсаң суғышмый икән.

Төш күреп қалдым, ди, азау тешем төште ди, әтисе үлгән икән.

Боларны да қунақ итәсе килә, бик аларға иләшкән. Алта әзерләп-әзерләп қуйған мин барысына да, байбағын (носки), йаулығын. Алдан этен, алдан этенмәсәң цыға күтеңнән төтен.

Элеке баш аwыртса тиң йасағаннар (баш ауса, аны үлчәү). Мин анан-монан ғына беләм. Йығылғанда тиң була, башы аwышып китә, йеп менән бәйләйләр дә буйайлар ике йақ цигәдән, маңғлайда борын турыннан, йеңсә (җилкә) цықырыннан. Йепне алалар да өлчәйләр, қайсы йақ озынрақ, шул йаққа ауған була баш. Мин йеп менән өлчи белбимен, баш тайғанын күппәте беләләр. Анан озын цөпрәк мән бәйләп, оцларын борып-порып суғалар.

Кешенеңке үбәсе (өрәк) була бит. Мин ул мамайның (карчык) үбәсен күргән идем. Эштән қайтқанда үлгән, аның үбәсен тужы күргәннәр. Ул шул кеше кебек, ул сөйләшмәс, тиз-тиз бара ғына. Қату аwырды. Сөйлидәгәнем (сөйләр сүзем) бик күп.

Қәсер инде пескә көлгө кәрәк, көлә-көлә йығылып қуйғанны сиспи. Көлгән кеше қартайбый. Өй урыныбыс киң булған, йеде эшег иде эцендә. Өйләре қырма булған, сап-сары қырып йыwып қуйа тығын. Саулыққа булсын бу көлүләр.

Қуйны күс тидебе, ни дип сойдық. Күс тейсә ыстаканға көл саласың, име шундый: эт ацы, әдәм ацы, сыйыр ацы, Айшә Патима қулы. Алты рәт итәсең, палаң йоқлый.

Пала туwа, тороп қалсын тип түбәсендә цәц қалдыралар ницәдер йәшенә қәдәр. Фәйзүг әкә нәзер бала (нәзер әйтеп, алладан сорап тапқан бала) булған, түбәсентә цәц қалдырғаннар. Тормышы аwыр була нәзер баланыңқы.

Йыруны башладым да тотылдым (карлыгу) йырлап петпи. Күңелемә тийә, қаймақты да ашабыйм, йөрәк болғанай. Инәм йаратайы лүпсә (кипкән шомыртны иттарткычтан тартып әзерләнгән он), қаймақ салып, писүк салып. Тәптәреңнәр йетмәс йазарға.

Айағыма сыwығ үтә,
Сары сандал кисәм дә;
Қошлар сайрап сағындыра,
Сабыр итим дисәм дә.

Қулйаулығым төшеп қалды
Кылуп айырмасында,
Йақын күргән дусларымдин
Килми айрыласым да.

*Сөйләүче һәм җырлаучы:*
*Мамышева Маһирә (1912 елгы),*
*Умавыл*

Анықы баллары – апалар (укыган кеше, укытучы), қалада торайлар, уқытайлар. Мәчет салғалы иттеләр, урны да бар. Мулинәбес (абыстай) тә бар. Быратым ылы қалада торай, йегермә дүртенче йылнықы. Үсемнеңке улымныңқы хатыны да қалада торай. Қызымныңқы малайы Қазанға баргылай, ул анда уғыған. Минеңке сыродный систырамныңқы малайы Омскийда укыған, инжәнир булып эшләй Сивырныйда. Нишләгәле кәрәк? Торғалы кәрәк, вритный заwат булса да эшләй, Әсма абаға (апа) йөс мәртәбә әйттем, аwылға қайтығыз тип. Китешеп қалайлар бөтенесе. Хаҗиәхмәт әкә (абый) үлде, Әскап мамай (әби, ләлкин карчык) йаңқыс қалды, Әскап мамайныңқысын (эшләрен) эшлим. Безнеңке әбийем булған Хәйат мамай. Хәйат мамам минең әтийемнеңке әнисе ул, бабайым иртә үлде. Сез йақта ниндей тормышлар, йәнекәйем? Инәм Абытайның (ав. ис.), бер абасы бар иде, мамай булып, йөз дә дүрттә үлде. Инәмнеңке инәсе иртә белән йығылды, төшкә хәтле йан да бирде. Инәмнеңке бер әкәсе, ике быраты бар иде. Себерәк пес, эне йуқ пестә. Кецү быратым булса, кецү систырам булса, күкәм дийәсең, алар безгә абам диләр. Әтинең

систырасы абам да туқсанда үлде, аныңқы малайы әкәм инде минен. Иремнеңке өч быраты бар иде, Шәйхул әкәм иремнең олы быраты, кецерәкләргә исеме белән әйтәсең, Қәйрүк, алар мине йеңг дийәләр. Қәйнә, қайыным пар ите. Қайын эне, қайын сеңел була ирeңнеңке кечү быратлары, систыралары булса, балдыз ир кешегә синең кечү систыраң була, синең абаң аңа қайнегәц, әкәң – қайнаға. Пес йақта қайын әби дә болодоғон, қайнананың олу туғаннары, ире қайын бабам болотоғон. Қайынсеңлем пар иде унпиш йәшәр, йенгәү генә тип йөртә иде бақырқай.

Қайнәсе таза иде күрше киленцәкнеңке, сур көйнәк кийә иде. Қәсер киленгә бик йақшы инде қайнаналар. Ул киленцәкнеңке әтекәләре йуғ иде өскәнтә.

Элгәре йәрәшәләр, малайны күрмисең дә. Шәхүл әкәне шулай өйләндергәннәр. Энесе миңә өйләнде. Килендәшләр бар, миңә Мөнәwәрә килендәш, без өц килендәшбес. Қацып киттем мин. Соуғыштан суң, аwырцылық wахыт. Икең сөйләшәсең дә кицен, ат йегә дә күрше аwылға алып китә. Икенце көнне атларны гөлләп (бизәп), күцендереп апқайталар монда, аннан туй йасайлар. Қайнанам бик ғайәр, уңған хатын иде. Йырақ түгел тора идек, ирем йәшлий үлде, алты бала қалды. Қысларны кийәүгә бирдем, малайларым да әйбәт. Қайнанамныңқы да абасы, әкәсе бар иде. Үсемнеңке бабам йитмеш дүрттә, мамам йөз дә икедә үлде. Алар қазаннық (казанлы), пес сиберәк инте. Эгесәк паллар да тыудым: Зөрийә, Хөрийә. Эгеснең персе исән. Үгәй ата, үгәй инә була, сурас бала була, ирсес тыуса. Көп пулсалар иң олу, уртанцы, кецү бала дип әйтәсең. Минең өц малай, қыслар да шулай уқ өцәү. Яңа туған бала, айаққа басты, айақтан китте, үсеп йитәләр.

*Сөйләүче: Шаһивәлиева Диләфрүз (1929 елгы), Кызылкаш авылы*

**Авырулар.** Мин тужы томауладым кицен утырып қапқа алдында. Төнө буйы аwырдым. Илеке (элек) герип йуғ иде, томау аwырywы дийә торғамбыс. Пискәк элеке булған ул, қара им белән имнәп күрәсең (карау). Терсәк (арпа) цыға күскә, унда

булса сул қулға, сунда булса уң қулға бармаққа цалыштырып, йеп пелән бәйләп қуйасың, ырым полған инте. Қултығ астыта ниндей шеш поло доғон, эт имцәге цыққан тийәнне эшеткәнем бар.

Паллар қысамық цығаралар иде, эгеснеңке персе қысамықтан үлте. Сыразы суқырайды, йуwаш (тыныч) пала иде, икенцесе усал, гар'ачийне усал диләр бестә.

Элеке пицәл (рахит) булған, айағыннан пасалмағынцы оутыра биг осақ, атлап китсә айағы қыйыш пола, пицәл бола.

Ныжылу (кәчеркәле) бала была иде, ныжысы бола арқасында, йоқлай алмай. Аны (әнә) минең қайсыдыр балада бар иде, нәрсә белән цығардым суң? Уwыб-уwыб цығардым аны. Үсем цығартым ныжыларын.

Рахит пала ул айақсыс утыра, қорсағы зур булып. Баланы төрлө-төмән (төрле-төрле) ашатмаса рахит пولодоғон.

Үлгән кешенең исемен қушқалы қуймыйлар иде бестә.

Очан аwырууwы болған. Очан тип паланыңқы тиләсен арт нийенә қуйып йылатып имнәгәннәр тип эшеткәнем генә бар.

Минеңке бер қолағым тона төште.

Минеңке тыным қыса, йәш йекет wахытлар петте.

Син тә күргәндерсен әле очанны, йазып торбасыннар дип оныттым тейсеңдер әле. Ысбайланып оутырған кешене йаратпаймын.

*Кызылкаш авылы.*
*1996 елгы экспедиция язмасы*

**Кием-салым.** Көйнәкне итәкләрен пөрөп-пөрөп теккәннәр, ыштанны озон балақлы итеп. Йаулықны йәйгән көйгә бәйлиләр иде, кәшәмир йаулық, ситча йаулықлар болған. Пухоwой шәлләр була тоғон, осон цукту шәлләр. Муйынға қаталар кәрәбәләр эреләрне, уwақларны энче диләр. Қалпақларым пар ите, энчесенә була сүтеп петерделәр. Кәпәц (түбәтәй) кебек түгәрәген кәлпәк тийәләр иде. Кәпәцне беләмесес? Ирләр гел кейеп йөрәйләр. Қатыннар кәлпәкне генә кийә дә шәл йабына. Ирәнләр (ирләр) паштарына тақайа (бүрек) кейгән, түгәрәге генә

була торған, ците тотылған, теләсә нинтей мих менән тотылған. Қолақчын пүрек тә булған. Қатын қыстар шәл эценнән түгәрәк пүрек кейә торғаннар. Күкрәкчә – изү (бизәнү әйбере) өстән кейә тоған, төрле тәңкәләр саплы (тегеп яки тагып куяр өчен махсус сабы булган), муйынқа артқа элеп қуйа торған.

Элеке соғып йасаған көйнәктәр, партыктар (алъяпкыч), л′онны (җитен) эрләгәннәр йеб итеп. Шақмақту көйнәктәр кейдек өскәнтә. Көйнәкне төрлүцә тегәләр иде, мөрмәле, күттән мөрмәле, икешәр қуштан (бала итәк) булайде. Күттән мөрмәле көйнәк тип аерым сөйләделәр. Қатламаны (катлы-катлы бала итәк) көйнәкнеңке өстөгә бөрөп-пөрөп үз матирйасыннан, мәрзәнне муйынға тезеп элгәннәр. Сләртә қалбағанба? Күрсәтәсеңнәрбә? Апақта ату (читек), ирләрнеңке қара, қатыннарныңқы уйықту (каюлы), батинкы үзләре салған (күн эшләү) күннән қатынқысларға, пашмақ тушы күннән, артсыс. Сары туннар, қара тун, толып болған. Пишинә менән пәйләп кийә идек ойықларны.

Қара матирйа, пелүш камсул қыйбатту (кыйбатлы), мих менән тегелеңгән. Бишмәтнеңке итәкләре биллү булып тора торған. Питкә алсу иннекләр, пүдерләр сөрткәннәр, қашына қара тартқан ди тоғоннар ите. Көмөшләр төмән төрлү: алқа, қашлу йөсөк, балдақ, көмөш беләзеге, тезеп қуйылған ташлары, пеләзек қойдортыб алдым тип сөйләшәләр ите. Сипүшкә боло тоғон пайларта ғына, осон сәленеп төшкән, көмештән, қашлар оцларынта, муйында қаптырмасы бар.

*Сөйләүчеләр: Нәҗметдинова Әскап,*
*Акумбатова Зөбәйдә.*
*Кызылкаш авылы.*
*1996 елгы экспедиция язмасы*

Менәкә аларныңқы қапқазы да. Ай чубачағым (бәбекәем), цай қуймағам. Қыслары Нурзийә, Мәрзийә, икесе йоғаш (охшаш, рифмалы) икән. Әнийем йәшләй үлгән. Қода, қодағый рәттән торалар. Бестеңке бабайлар Иван Гырозный цағынта қадзып килгәннәр. Мансур бабай, Пономарь тиб алыштырғаннар. Анда оутырбағаннар икән, монта оутырғаннар.

**Йолалар.** Ауравғаннар элеке тә, қәсер тә, қарттар да, паллар та. Диф йөрөгән, үпкә аwыруwы да булған, сару (сары, авыру исеме). Лихаратқы (бизгәк) менән эүсем тә аwырғаным бар. Тәблиткысын йасыйдығыннар. Көцөк (эт) майын эцергәннәр. Сары аwыруға солы сыwы эцергәлү гирәк. Мәтрүшкә қайнатып, шоморт цәцәге эцереп имни торған. Йаман-йоман аwырулар болодағон. Қоурықса әнәү (әнә) инде қурғашин қойодоғон. Өц қатар (мәртәбә, тапкыр) кирәк. Қоурыққан сең (соң) ул цәцрәп төшкән иде. Инәсе табибцы иде, ул имнәде.

Күс тейгән элгәре, уртаңғы малайға күс тейгән иде. Маңғайына күмер сөртәсең, балаңы қарағынцық қоромға күзе төшә ғой (бит).

Нийәтлек суйайлар, қайсыбер бала сөйләшпәй бит, тартылып (тотлыгып) сөйлөй дип, нийәтлек суйып, қор'ән цығартып…

Қайсысыныңқы айақтан баспый. Йә анадан сәғыйп тыwа. Озақ база алмый, базып китсә хайер бирәләр. Минеңкеләр түжемнән цықты да (имидән аерылу) йәслегә бардылар.

Мыжылы (кәчеркә) була қайсы бала. Итмәкнеңке нисе, йомшағы мынан уwып-уwып цығаралар.

Оцан (эч авыруы) булған ул, аны мамайлар күтәрәләр дә эце китә.

Бичәл (рахит) бала йөри әлми, утыра да утыра. Қарый алмағанныңқы бицәл була. Кул да йептий, айақ та йептий, қорсағы көптий.

Қаршыланып торды, йома көннө йарамый эшләгәле. Ағым сулар туқтап торор игән йома көнне.

**Туй турында.** Син баштусын (син башлы), син сөйлә. Элгәре қацырып китәләр иде. Суратыб алғанда әти-әнидән кил+сурый (килеп). Көйөүнеңке тоуғаннары, быраты килә сауцы (яучы) булып. Зур йомыш ман (белән) килдек ти. Әңкәйләр ыриза булбай, ыризамасес, йуқма, анаң (аннан) бирәләр. Бестә көйөүләп йөргәннәр. Қайсысы қызын байға биргесе кели. Әле туй булды, цын элеке шикелле булды. Кәлбәне дә бежерәләр, паwырсақ та самса қамыры шикелле қамырдан. Сауцылар керәйләр, ылақсалақ (этәк-сәтәк) сөйләйбес. Ыштан балағын цығарып қуй-

ған бабай. Сулар кицеп цықтық, селәрнеңке Мәймүнә дигән қызығыс пар икән. Сөйләшә-сөйләшә тойларны да салышып (килешү) китәләр. Периданны өзеңнәр беләсеңнәр. Сип падарык ансы, перидан төгөл. Мал да бирәбез, йә булса бер тай. Нүгәрләр (кияү егетләре) киләләр, эжек шиленнән (ярык) йегетне күрә қыс. Әтийем буйлы, бийек булған, инәй инде, атам мынан инәм биреп қуйғац, ыризамын, дигән. Қайынинәсе йақшы қатын булған. Қысны күцереб алып қайтайлар. Қызрақ ашы булған, йә боға (үгез), йә тана сойғаннар. Цәй ашлары болғон тойда, шөпшәрә (пилмән) болғон, шондый-шондый. Қысты алып киттеләр, йекет йақта той боло ғой. Телем дә килби қазанныкца (казаннарча) сөйләшкәле. Қышын цана, шаңғырақтар (кыңгыраулар) мынан алып китәләр қысны күцереп. Қодацалар ашатай, апкерәйләр. Озон ақ көйнәк, озон чачақтуларны (чуклы) шәлләр, бәлтә өстә. Йекетләрдә пизун (хром) үтек, қыста – ату (читек), Мәрсийә абада (апа). Қәсер күкәсе – (иренең яки хатынының эне-сеңелләре) кем менән тора? Қызыныңқы қызы мынан торама, бақырым? Ике туған ғына қалдықлар. Әкәү (абый) айақсыс, зур абыйым қайтты (үлде), икенце йедесен (җидесен) оуғыталар бөгөн. Ирнеке туғаннарыннан балтыс (иренең сеңлесе) қына қалды. Әле әнинеке туғаннаң туғаннары бар, ике туған баласы. Қарттар энте. Менә бу бақырцақ (мескенкәй) йөзгә йақын, мескенкәйем, қөр'әнгә қайсылый а+килерләр. Өйдәбә, йуқпа, белмим, Мәйсә мама (әби; карчык) миңә қодағый ул. Йәтим үскән мин, мин анамнан өч кенә йәштән қалған. Минең қайынсеңлем Қазанда, ул бақчасында көн дә су қойадаған, күкәм ул минең. Қайнанамның қы әнисе мамам күзе йуғалып (сукыраю) үлде.

*Сөйләүче: Шәйдуллина Сәкинә (1929 елгы).*
*Умавыл.*
*1996 елгы экспедиция язмасы*

**Тормыш-көнкүреш.** Тискәре кеше қандий (гел, һаман) үзенекен қыла. Йамғыр да үземнекен қылыйм ди, йаwа. Тырнаwыцлар йетешми қала, йамқыр килә башласа, моғоллап

(зур булмаған чүмәлә ясау), моғоллар йасап китәләр тиз-тиз. Ат беләтарттырасың, кибән салырға. Озон-озон синәкләр була кәбән ырғыта торған. Йынақ (җыйнак) қына кәбәннәрем, бер сыйыр саwам, йитә. Тезәләнеп (тезләнү) саусам да үземнеңке инәгем (сыер), өч бутилкы апкерәмен дә инәйгә, бер йомаға (атна) йетә. Сан-сирәк (сирәк-мирәк) тирә-күрше дә керала (кереп ала). Қырлар көп бестә, Утырац, Мулла қағаны, Чаршауник, элек урыслар картопка утысқаннар Чаршауникта. Қырларны қайсысын урта бөк дигәннәр, бөк тужы кыр интәе, басу. Тағын Нәстеркүле, Бүтән төбө бар. Қаған тип зур түгел генә бүләкне әйтәләр, ачық йер, wақ ағацлы. Қаған ул зуррақ, қазаннар болын тиләр. Утырацта тойоқ (тоташ вакыт) йәй йөрдөләр қаслар, соу буйында була ул, әрәмәлек инте. Соуға төшәләр, унар йул төшә идек соуға көйәнтә беләә. Қышқысын пешнә белә қойо (бәке) йасыйлар тишеп.

*Сөйләүче: Корбанбаев Әбүбәкер (Әүбә бабай).*
*Әүштә авылы.*
*1996 елгы экспедиция язмасы*

Билләрем аwырта, бөкәйә алмыйм. Элек боғарақ (җыймаган, пычрак) өйнө йаратмый ийем. Күшәгәләрем (чаршаулар, пәрдәләр) дә керле, идәннәрем дә керле. Эчем бошып йерим. Қартинәм үлде, үз инәм үлде, абам үлде, йермәсегезнең (1928 елгы) ийе. Йирдән бөкәйеб алсам, йөрәкне қыса. Тиз-тиз басып йезнәм килеп йата. Пилүрә күкәмә (эне яки сеңел) алырғайттем эүләрен, Зиннур күкәмә завищайт иткән, шулай итеп бик қауғалаштым. Қәзер исәттерә (уйландыра), йәш wахытта уйламыйсың, бирештем. Үз инәм озағ аурады, моннан ара уттый йана диде, қалған (соңгы) сүзе шул булды. Қара сару белән үлде, цирроз диләр. Үләсе килми дә инде, тағы бераз йәшәсәм иде. Мөршидә мамай (әби, карчык) сиксәннән артық. У кешегә йағым, матур күренер. Бик телле у, аны йеңәлмисең дә. Өч йыл сыйыры йуқ (сыерсыз) тордым, пима тектем, табанный идек пиманы, итекләр тектем, сийыр тиресен илиләр иде, бозау тиресе қунычқа әйбәт. Быратымнықы челлә (җәй, җәйнең жылы,

эссе вакыты) wахытларда малайы йатты, килене йатты, печәне қалды. Сийыр тотпасаң тормыш па? Челлә диләр бездә, челлә керсә су чумарға йарый, челлә кермичә җәй булмас. Моңну итеп кәwекләр (кәккүк) қыцқыра, бөктә (болын) эштиләр ницә ай, гөллү-гөллү йасалған аш тигәце (савыт) була иде, итмәк кәритәсе (җилпуч, күәс) итпәк баса торған, гөбө май йаза торған, қәзер қалақ белән генә болғайбыз, иртәгә күргәләк (күрерсез) сез аны, китмәсәгез. Арғы кибеттә абалы-күкәле (апалы-сеңелле) сатышалар, балларын мин дә қарыйм. Кечүсенә арқасына биреп-биреп алдым, аwырықцан төгөлләр алай. Пицәл дә була қайсы бала. Бестең Пилүрә пицәл иде, ана қандий йүгерә. Бицәл булса қорсағы зур була, айақлар нәзек була, рахит инде ул. Қыз баласының теле йеңелрәк цыға, Рамил лапағ иде, озақ басып китте, үзе таза, үзе әкрен.

Биш бала мынан қалдым. Атта да менеп йөрдем, төмән төрлө (төрле-төрле, мең төрле) эштә эштәдем. Бер қызым зур түгел генә йорт салды Абытайда. Килбәсәләр, әйтәм: исән цақта бер-береңне күрәргә кәрәк. Онотам, цай эцәсем килгән цақта түккәм дә акер (алып кереп) қуйған өйдә цәйнүкне. Биш балаға кем бер тәғам ыризық бирде. Эштәйбес, таң атқанцы төнибес (төн куну). Аурамадылар. Йүткереккә (үпкә чире, туберкулез) им-том йуқ. Саwық тисә қулымның йөзе (аркасы) белән баланы йыwындырам. Күз тисә ишекнеңбә, қапқаныңқы цығанағынама (күгән) қойам суны, йыwындырам. Йел тигәмбә, ни тигән, зәхмәт қағылып қайткамба. Йел белән бушатқан кеше бар. Бәләкәй цағында эт талады да сөйләшә алмады, тартылайды (тотлыгу). Күз тийү генә түгел, тел тийү дә бар. Тел тигәннән дә аwырыйлар баллар ғына төгөл, сийырлар да. Балам тағын тартыла башлады, тел тийә аларға. Ацуландым да аңа, тезәләнде дә «әнекәү, парасти мине» дийә, телцән үзе, эт таласа, эт йонон кисеп, төтәстәп башын әйләндереп, тешләгән йеренә йабасың.

*Сөйләүче: Корбанбаева Сания (1926 елгы).*
*Әүштә авылы.*
*1996 елгы экспедиция язмасы*

Қорсақлы идем, сәғәт биштә тумалы да киттем. Әбилекләр бар иде, икене әбилек белән тудым, Фәрзаман мамай (әби, карчык) бар иде. Тулғақ тота, ачы (кара әле), көчәңке дә килә башлады. Башта үлү бала туған идем. Қызымны тудым, соңғылықны күмәләр бездә чиста йергә.

Бес күргәнне йасып парсаң иде. Айақта лунтай галуш, чәрки ийе әле. Лунтайны сукналардан сырып-сырып аласың да, қунцысы да була, аның эстенә галуш кийәсең. Қәсергедий йалтырақ галушлар түгел иде, шақтур галуш тийәләр, йәмсесләр була торған. Чәркине күннән тегәсең, итектән қысқарақ қунцысы. Эрзиңке итекләр йуғ иде. Ойоқно қалын итеп бәйләсәң тула йоктий (оектай) була инде, йон ойоқ, йон наски, түрт энә белә. Пер энә белен миләй (бияләй) бәйлиләр қалын булсын, йылы булсын өцөн. Чәркиләр қуныцлы да була. Йуқ қәсер, силәргә күрсәтәр ийем. Әйтәдегән, әй берас қына тыныц йәшәсәм иде. Әтийем урынына қалған абыйым, килбәсеңнәрбә (килмәссезме) ти, үлсәм тенәргә керәрсең, күршем кергән дийәрмен ти Мөршийә мамаға. Укул сайап (кадау) киткәннәр систыралар. Пы балаға әйтәм, йатпа йанында анықы, дийәдәгәм (ди торган идем). Минеңке улақтар (балалар) этиләрен үбеп-үбеп қаладаған эшкә киткәндә. Мин Барнаулда туғам, димнәп керетеп кийәүгә бирделәр, палтыс (иренең яки хатынының сеңлесе) та, йорцо (иренең яки хатынының энесе) да бар ите, қәсер үлеп беттеләр инте. Инәләрен, қәйнәмне пер йыл буйы күрдем (карау). Паш паламны тыуғац бәбәй майына (ашына) сөлгөчәкләр, ақцалар акергән ийе, йыруwы да исемтә калган:

Ишектән кердем, түр (сәке) күрдем,
Түргә мендем, гөл күрдем;
Сезнең нурлы йөзөгесне
Бөгөн төшөмтә күртем.

Йазына торған хәләм кебек
Күз өстөңдә қашларың;
Кырукларда йөргән цақта
Әйләнбибе башларың.

Монсы наза йыруwы, наза-наза, наза бақыр (мескен) қыс пала, тип йырлайдыған уйыннарда.

Элгәре эш нық булган. Инәсе сыразу аш (токмач) йасарға қушқан килененә, қоймақпа, қабартмаба пешерткән, сынаған. Бестә айырыла қуй: аш тақтасы (куна), илгәк (иләк) пелә илиләр, орбағы (көрпә) қала, чара (табак) булған тик-түгәрәк (түп-түгәрәк), типте (тагарак) әйтәдегән кер йыwа дыганны. Қааба (кая булса да) барсам сурашам, пелгесе килә циттәге телләрне дә.

**Кием-салым.** Көйләккә йелкә (инеч) тегелә иде тиргә тиз тузмас өцөн, уйым пелән бергә уйылып, пергә тегеләдеген. Йақа да, ирәнләр йақасы буладығын, утызма йақа ирләрдә буладыған, қәсер цықты ул ацылмалы йақа. Ыштанны ыцқырлар белә, балақлар белә тегәдегәннәр, ыцқырын баудан йасыйлар, балақлары киң булыр ыйы. Қалаға барырға булса сырма чалбарын әзерләп қуйа иде. Чабата бес йақта кимәделәр. Чикмән кигәннәр, бик қалын сукнолардан, бөрмәләп, ирәнләрнеке салдат шиниле кебек. Пилбау да, қор да дийәдеген, эц қор. Инәмнеңке әнисенеңке эце төлкө, тышы пелүш тун булған. Сипкә (туйда кода-кодагыйлар тарафыннан кара-каршы бирелә торган бүләк. Гадәттә, кием-салым, тукыма һ.б.) китергәннәр, қодағый миңа сип китерә минең йақын-йақын туғаннарыма. Пес тә шулай апбарабыс йақын тыуғаннарына, қодағый белән эле йыйылышта (мәҗлестә) бергә булған ийек. Инәм бик йарлы қалған, аңа күрә бес уқый алмадық. Көфөр бәндәләр арқылы бездийләргә күрсәтпәсен. Қәсер тә сиб әкилде, йекет кумәце дип итмәг апарабыс, тос. Элег инде пастил әйбере була торған, йурқаны булар. Элек тотон-қабын (савыт-саба) алып килә торған. Йәштә йырлыйдағым, қәсер онтоп петкәм. Йитәрбә, күппә (күпме) йыр йырлап қуйдым. Туғабыс, үскәбес, инте қартайдық.

Әле ул қортқайақтың тештәре тезелеп тора. Питләрендә бер дә чөрөш (җыерчык) йуг иде. Энә күсти (саплый) күстексес.

*Сөйләүче: Шәрипова Зөләйха.*
*Әүштә авылы.*
*1996 елгы экспедиция язмасы*

Нимәләр кийептеләр? Ирәнләр тағайа, кәбәч кийгәннәр. Бес айаққа чолоқ, қазаннар пазар ойоқ тиләр, пима кийәбес, майбақ (йон оек), озон ойоқ ул. Ул элек утырарбыс, бәйләнәбес, мендәр аwызын бәйләп, пирастина итәкләрен пәйләйбес. Пиманықы қуныцы белән йамағаннар пима тишелсә. Сукунный бурки қатын-қысларнынқы, бурки ирләрнең ақ, оссон қуныцлы. Бестә чарық йуқ, батинка йоқа боронзиттан (брезент) була, галушлы. Бийек үкчәле туфләләр байларда ғына була. Сырғалар, беләзекләр, кәпәч булған қатын-қыс пашында, күгелтерем энзеләр теккән, ақ йебәк шәл, осон цацақлы йабынғаннар. Билле бишмәт кигәннәр. Қыйық тиләр ийе, аны башларына йабып қунаққа бара торған ийек, қыйық өстән кәбәц шигеллене кийәләр, түбәсе ачық. Матур чигелгәннәре дә була иде, хәситә ул сестәге йанчық кебек, доғалық үсенә ул. Әйбәт торған қызларға жиңсес камзул, ату (каюлы читек) бик йомшақ, асты табансыс, үкчәле булғанын читек диләр иде, байбақны (к. майбақ) кулаша былан кийәләр, тула килгән кешеләрдә булган ул.

*Сөйләүче: Фәйзуллина Мәүлия Габдрахман*
*кызы (77 яшьтә). Абытай авылы.*
*2004 елгы экспедиция язмасы*

Озон килгәннәр қыстар да, бестең инәйләр элеккецә кейгәннәр. Камзул йеңсез, пелүштән (к. майбақ), инәмнәр үскәндә килде микән. Моннан қаймәләп тегелгән итәге. Озон йеңле күлмәк, түш йабық, йақалары қаптырылған, түшең ацык булбасын. Өйрәңгәле тырышапыс, пестән тә әбиләр бик йәмсес пулған.

Йебәк шәл. Озон цуқту (чуклы), күптермә-күптермә иде. Минең күгелчемрәг иде, күптермәле (кабарып тора торган). Қалфақны энҗесенә була сүтеп бетерделәр. Кәпәц кебек түгәрәген кәлпәк тийәләр иде. Кәлпәкне генә кийә дә шәл йабына.

Элек була иде қуштанны (бала итәк) күлмәктәр, матур иде, мин килдем аны, қайсы өц була торған. Онытыпмын, төймәле була иде, қаптырмалы. Алтын бырошкалар була иде, соғыш башталғац ыздайт иттек, йуқ хаққа бирдек, ташы йанып тора иде йөзөкнең, ирләрнеке балдақ. Беләзекне мамайлар (әби, кар-

чык кеше) кигән, көмөш булған, таштулары (ташлылары) да була иде, тезелеп-тезелеп киткән ташту була торған. Цәц толымын линтылаб ишә идек, тәңкәләр wақ қысцақларда (кыз балалар, яшь кызлар) була иде. Зур түгәрәк алқалар иде мамайларда, дутый (өрдерелгән юка пыяладан эшләнгән мәрҗән). Қалфақ парқет (бәрхет), төрлүцә энзеләр теккән.

Күкрәкцә (борынгы бизәнү әйбере: тукымага тәңкәләр, асылташлар тегеп эшләнә, муенга тагып күкрәк турысына киелә) өстән кийә торған, төрле тәңкәләр сапту (саплы), муйынға артқа элеп қуйа торған. Әйкүл (әлкой – хәситә; тәңкәләр, асылташлар тезеп ясалган, бер иңбашыннан икенче култык астына киелә торган бизәнү әйбере) булған, уқа белән, киң генә, аңа тужы матур көмөш тәңкәләр, ақцалар, ташлар тезә торған, урта халық кийә торған қайа булса барғанда. Әлқой, монта доғалығы инәмнеңке дә бар иде, маныңқы да, қайыш пула. Доғалықлар тығып қуйа торған, қушып тегелецгән, төрлөцә итеп цигелеңгән, өстө матур. Көн дә кийә торған, астан йөри торған күкрәкцә дә була торған.

Цәцкә үрәләр иде тәңкәләр сабақту, бер-берсенә йалғанып, кем өцне, кем дүртне. Цулпысы бар иде әбийемнең, цулпы wақ қына тәңкәле, уртада ағыйық (ахак).

*Сөйләүче: Шаһивәлиева Диләфрүз (1929 елгы),*
*Кызылкаш авылы*

**Курчакка табыну турында.** Иң әwәл өц быраt булған, Қурбанбаевлар қалған шулардан. Алар қурчақ тиргәп бәйрәм иткәннәр, қурчаққа табынғаннар себерәкләр.

Қурчақларны тегеп, кийендереп, қайа кәритәгәме утыртқаннар. Сунаң (соңыннан) өй башына мендереп қуйалар икә. Бәйрәм йетсә аптешеп кийендергәннәр, тегеннәр теккәннәр. Себерәк халықы қурцақ қалықы тийәләр. Қурцақның бөтөн йерен тегәләр иде, цәцне тунның йөнөн кисеб алалар, қурцақның башына тегәләр. Қурцақны қайа бала-цаға уйный, шунда сақлыйдығын, түр (сәке) озон, өй эце буйына, анда қурцақ түрдә тора.

*Сөйләүче: Фәсхетдинова Нәсимә (1924 елгы).*
*Әүштә авылы. 1996 елгы экспедиция язмасы*

**Туйлар.** Песнеӊ саманта қацырып китәләр иде. Соратып алғанда эти-әнидән килеп сорый. Кийәүнеӊ туғаннары, быраты килә сауцы булып. Зур йомыш ман (белән) килдек, ти. Әӊкәйләр ыриза булбай, ыризабасын, йуқпа – бирәләр, байға (иргә) биргесе кели. Цын элеке шикелле булды, кәлбәне дә пешерәләр. Мин үзем тә бардым сауцы булып. Икәү киттек. Син баштусын, син сөйлә, тимен. Керәйләр, ылақ-салақ сөйлибез, теге ыштан цығарып қуйған. Серләрнеӊке (сезнеӊ) Мәймүнә дигән қызығыз бар икән. Тойларны да салышып китәләр. Сип – подарок ансы, сип – бар нәрсәне бергә сип тиләр. Периданны үзеӊнәр беләсеӊнәр. Салымға йә булса бер тай бирәрбез, тиләр. Нүгәрләр (кияү егетләре) киләләр, қыз ишек шиленнән (ярык) генә йегетне күрә. Атам мынан инәм биреп қуйғац ыризамын дигән.

Қызны күцереб алып қайталар. Қызрақ ашы булган, йә бога (үгез), йә таны суйғаннар, цәй ашлары пешерә торған.

Қысты алып киттеләр. Йегет йақта той боло ғой (бит). Телем дә килби қазанныкца сөйләшкәле. Қышын цана, шыӊғырақтар (кыӊгыраулар) мыннан алып китә. Қодацалар әпкерәләр. Озон көйнәк, озон цацақтуларны шәлләр бәйләп, бәлтә, айақта ату (читек), кейәүдә пизун (хром) үтек...

*Сөйләүче: Әбдрәшитова Зәйнәп (1917 елгы),*
*Кызылкаш авылы.*
*1996 елгы экспедиция язмасы*

## Калмак сөйләше

### *Фонетик үзенчәлекләр*

**Сузыклар,** *а* авазы, мишәр һәм күпчелек себер сөйләшләрендәге, урта диалектның дөбъяз, нократ, пермь, керәшен сөйләшләрендәге кебек, иренләшү төсмере булмаган, ачык аваз булып әйтелә: *ат, агач* – урман, *баш бала* – гаиләдә беренче бала һ.б.

Сузыклар өлкәсендәге башка үзенчәлекләр аваз тәӊгәллекләренә, төрле комбинатор үзгәрешләргә кайтып кала.

Бер төркем сүзләрдә һәм фигыль формаларында әдәби телдәге *ы* авазына *а* сузыгы туры килә: *суwақ – суwык* (суык), *бар-*

*ба* – бармы, *қырғыссыңба* – кыргызсыңмы, *утыртарға* – утыртырга, *барарсыз* – барырсыз, *алар идем* – алыр идем, *күрәр* – күрер – әд. карар һ.б.

***ы ~ а*** түбәндәге очракларда теркәлгән: *йаңы* – йаңа (яңа), *қызылчы* – диал. *қызылча* – чөгендер; *барғынчы* – барганчы, *чыққынчы* – чыкканчы, *қызарғынчы* – кызарганчы һ.б.

Тамырларында *у, о* иренләшмә сузыклары булган сүзләрдә аннан соң килгән иҗектә о~а: *туқсон* – туксан, *тусқон* – тузган, *ойнойдо – уйнайды* – уйный.

***ы ~ у***: *бы* – бу һ.б.

Сөйләш өчен характерлы үзенчәлекләренең берсе – сузыкларның гомумтөрки системасы, нигездә, сакланып килү. Бу исә түбәндәге тәңгәллекләрдә чагыла.

Әдәби телдәге киң әйтелешле *ә* авазы урынына сөйләштә аның таррак әйтелешле, әдәби *ә* һәм *и* авазлары арасында торган варианты кулланыла (биредә без аны шартлы рәвештә *э* хәрефе белән күрсәтәбез). Бу вариант әйтелеш ягыннан бераз дифтонгоид характерда булуы һәм озынрак яңгыравы белән дә үзенчәлекле: *инэм* – инәм, *эртэрэк* – иртәрәк, *йэлэклэр* – җиләкләр, *бэлгэ* – билге, *нэ менэ кэлдеңэр* – нәрсә белән килдегез, *белгэнемде* – белгәнемне һ.б.

Шунысы характерлы, *ә* авазы тамырдагы *и* сузыгына да тәңгәл килә, шуның белән бергә, еш кына әдәби вариант үзе дә әйтелә: *мэн/ мин* – мин, *эр/ир* – ир, *кэленчэк* – киленчәк, *йэңдү* – җиңле һ.б.; *бәйләгән* – бәйләгән, *мэлэй* < *мәләй* – бияләй, *үткэзип – үткәзеп* – үткәреп;

***э (е)~и***: *керпеч* – кирпеч, *кебит/кэбит* – кибет һ.б.;

***и ~ э (е)***: *тигермән* – тегермән, *әйбир* – әйбер һ.б.;

***и ~ ә***: *эйбит* – әйбәт, *бәйлиген* – бәйләгән, *иртигэ* – иртәгә, *бетергин* – бетергән, *бәйримнир* – бәйрәмнәр, *әйбирлирне* – әйберләрне, *кердиңэрмү* – *кердеңнәрме* – кердегезме һ.б. (татар теле урта диалекты касыйм сөйләшендә дә шулай ук);

***э (е) ~ ә***: *күгеwен* – кигәвен, *күкрәкче* – күкрәкчә, *менен* – белән һ.б.;

***ә ~ э (е)***: *күпмә* – күпме, *әйләндерәгә* – әйләндерергә һ.б.;

***ә ~ и*** кайбер сүзләрдә, фигыль формаларында күзәтелә: *йөрәсез* – йөрисез, *мән* – мин һ.б.

Калмак сөйләшендә хәзерге татар әдәби телендәге *у, ү* авазларына – $^{у}$*о*, $^{ү}$*о*, ә *о, ө* авазларына *у, ү* сузыклары тәңгәл килә. Бу күренеш шактый системалы характерда:

$^{у}$***о/о ~ у***: *к*$^{у}$*ой* – куй – сарык, *қ*$^{у}$*ол* – кул, *зор* – зур, *боға* – буга – үгез, *алабода* – алабута, *йоқа* – йука (юка), $^{у}$*орлау* – урлау, *ойнойдо* – уйный һ.б.;

$^{ү}$***ө/ө ~ ү***: *к*$^{у}$*өп* – күп, *бөгөн* – бүген, *т*$^{ү}$*өштек* – түшлек, *чөбрөк* – чүпрәк;

***у ~ о***: *сурату* – сорату, *куңғыз* – коңгыз;

***у ~ ау***: *шулау* – шаулау һ.б.;

***ү ~ э(е):*** *чәйнүк* – чәйнек һ.б.;

***ү ~ ө***: *йүткерү* – йөткерү һ.б.;

***ү ~ ә***: *чебрүк* – чүпрәк, *йәйү* – йәйәү (җәяү), *үлүн* – үлән һ.б.

Сөйләш өчен характерлы үзенчәлекләрнең берсе – 2 һәм 3 нче иҗекләрдәге *ә – а* сузыклары урынына *ә – о* ирен сузыклары әйтелү (чагышт.: ***о ~ а*** тәңгәллеге): *көрәк* – көрәк, *йөрәк* – йөрәк, *үкчө* – үкчә, *сөйлөп* – сөйләп, *көбрөк* – күбрәк, *кийөнтө* – көйәнтә (көянтә), *албомнор* – альбомнар, *кугүзмөк* – күгезмәк – әд. камзул, *күркө* – күркә.

***ө ~ ә, о ~ а*** күренешләре беренче иҗектә иренләшмә авазлар килмәгәндә, соңгы иҗектә генә дә булырга мөмкин: *бездекенчө* – безнекенчә, *кирөк* – кирәк, *сийлөжөм* – сөйләшәм, *кийнок* – күлмәк, *сийлөр* – сөйләр һ.б.

Мисаллардан күренгәнчә, аларның күпчелегенең чыганак формасы тамырында ирен-ирен сузыклары булган.

Сыйфатлар азагындагы һәм *-лы/-ле* кушымчасындагы *ы – е* сузыкларына *у – ү* авазлары тәңгәлләшә: *олу* – олы, *кечү* – кече, *кату* – каты, *ачу* – ачы, *сазу* – сасы, *изү* – эссе, *табанну* – табанлы – үкчәле һ.б.

Иренләшү гармониясе. Бу күренеш, беренче чиратта, 2 нче, 3 нче һ.б. иҗекләрдәге сузыкларның иренләшүе һәм тамырдагы иренләшмә авазларга охшашлануында чагыла:

*көпрөк* – күбрәк, *чөгөн* (чагышт.: пермь. *чөгин)* – чуен, *соқмо* – сукма – әд. килесап, *өлчөйткөн* – үлчи торган (булган), *сөйлөр* – сөйләр, *көкөм* – күкәм (үзеннән кечерәкләргә, эне яки сеңелгә эндәшү сүзе), *болғондор* – булгандыр, *қоноқтор* – кунаклар, *болғон* – булган, *торо* < тура – әд. туры, *молло* – мулла, *тоқозно бөтергән көрөсөң* – тугызны бетергән күрәсең, *қоштонно* – кушланлы – киң бала итәкле, *туқтодомо* – туктадымы, *ойнойдо* – уйнайды – әд. уйный һ.б.

Билгеле бер төркем сүзләрдә *ы–е* авазлары иренләшә (кире ассимиляция булса кирәк): *қошқо көн* – кышкы көн.

Аңкау гармониясе. Алгы рәт сузыклары урынына арткы рәт сузыкларын куллану: *быжырадық* – пешерәбез, *қуқай* – күкәй, *тадау* – диал. *тәтәү* – әти, *тыт* – диал. тет – карагай, *қычу чанақ* – кечкенә чана, *йунату* – йүнәтү (юнәтү), *чынча* – чәнчә (бармак) һ.б.

Түбәндәге сүзләрдә киресенчә күренеш, ягъни арткы рәт сузыклары урынына алгы рәт сузыклары кулланыла: *чөгөн* – чуйын, *мәркүп* < морковь – кишер, *әрзән* – арзан, *сүкрәнү* – сукрану һ.б.

Рәт гармониясенең бозылу очраклары табыла: *эшл'эды* – эшләде, *кийнок* – күлмәк, *иноу* – инәү – әни һ.б.

**Авазлар төшү**. ***ы – е*** авазлары төшә: *тороснан* – турысыннан, *эжегнән* – ишегеннән һ.б.; *аузын* – аwызын (авызын);

***а**: баллар* – балалар һ.б.

**Сузыклар өстәлү**. ***ә***: *тезә* – тез,

***е**: керетмичә* – кертмичә.

**Дифтонглар**. *-өй* дифтонгы, татар әдәби телендәге кебек үк, үзе әйтелә: *көйәнтә* – көянтә, *төйәп* – төяп, *өй, сөйәк* – сөяк, *сөйләжәм* – сөйләшәм *төймә* һ.б. Шул ук вакытта: *өрәтү* – өйрәтү.

Фигыльләрдә әдәби *-ый/-и(й)* дифтонгының борынгырак *-ай/-әй* варианты кулланыла: *белмәйем* – белмим, *йасайдык* – йасыйбыз (ясыйбыз), *ашайсын* – ашыйсың, *болмайчы* – булмыйча һ.б.

Әдәби телдәге *у – ү* авазларына калмак сөйләшендә *-оу, -өү* дифтонглары тәңгәл килә; бу очракта киләсе иҗекләрдәге *ы – е* сузыклары иренләшү гармониясенә бирелми: *оуқытты* – укытты, *өүтек* – үтүк, *оурус* – урыс һ.б.

Ачык иҗек оештыра торган *и* авазына *-эй* дифтонгы тәңгәл килү очраклары күзәтелә: *әней* – әни, *дейдең* – диден, *әтей* – әти һ.б.

**Тартыклар.** Күпчелек себер сөйләшләреннән аермалы буларак, калмак сөйләше *ч*-лаштыручы сөйләш булып тора, *ч* авазы шартлау элементы булган кушык аваз булып әйтелә: *$^{т}$чилэк* – чиләк, *$^{т}$чә$^{т}$чә* – чәчә, *барға$^{т}$ч* – баргач, *$^{т}$чанақ* – чана, *$^{т}$чардық* – чардуган, *пэле$^{т}$ч* – бәлеш, *пе$^{т}$чэн* – печән, *қуны$^{т}$ч* – куныч, *қызыл$^{т}$чы* – чөгендер, *тадар$^{т}$ча* – татарча һ.б.

*ч* авазының яңгырау пары *җ* авазында да шартлау элементы күзәтелә, тик бу күренеш, ассызыклап үтәргә кирәк, нигездә, сүз башында, аерым сүзләрдә генә урын ала һәм бик сирәк очрый.

Башка үзенчәлекләр тартыклар арасындагы тәңгәллекләргә, төрле комбинатор күренешләргә һ.б.га кайтып кала.

Билгеле бер төркем сүзләрдә һәм формаларда ***б ~ м***: *иске-босқы* – иске-москы; *салбаған* – салмаган, *қалбады* – калмады, *бирбэйте* – бирми, *бэрбэделэр* – бирмәделәр, *кибэдек* – кимәдек һ.б. (саңгыраулардан соң юклык кушымчасы *-па/-пә* вариантында кулланыла: *чэчпәделәр* – чәчмәделәр, *чықпас* – чыкмас һ.б.); *барба?* – бармы? Шулай ук: *итпәк* – икмәк.

Түбәндәге сүзләрдә ***м~б***: *муз* – боз, *мэлэй* – бияләй, *мелен/менен* – белән.

Бер төркем төрки-татар сүзләрендә *п* авазы борынгы әйтелешне чагылдыра: *керпек* – керфек, *йапрақ* – йафрак (яфрак) һ.б.

Алынма сүзләрдә исә ***п ~ ф***: *зэғыйп* – зәгыйфь, *мәркуп* < мәркүф < морковь – кишер, *партук* < фартук – алъяпкыч, *сапер* – сәфәр, *Чәпар* – Жәгъфәр (Ягъфәр).

Алынмалардагы һәм *пешеру* сүзендәге *п* авазының яңгыраулашу очраклары бар: *Wапа* – Вафа, *Бәрқийа* – Фәрхия *(ф > п > б), быжырадық* – пешерәбез һ.б.

***н ~ ң*** (II зат хикәя фигыльләрдә кушымчадагы этимологик *н* саклана): *йәшсен* – яшьсең, *ашайсын* – ашыйсың, *тығасын* – тыгасың, *аузын тотасын* – авызын тотасың һ.б.; иялек килеше кушымчасында: *анын* – аның, *песнен* – безнең, *абаудын* – апамның һ.б.

Алмашлыкларның чыгыш килешендә сүз азагында ***ң~н***: *анаң* – аннан, *минәң* – миннән, *тегенәң* – тегеннән һ.б. Шулай ук: *суwынаң* – соңыннан.

***ч*** авазы сүз башында *й* (> *җ)* авазына тәңгәлләшә: *Чәқпәр* < Җәғфәр (Ягъфәр), *чан* – җан һ.б.; *Гөлчан* – Гөлҗиһан, *арчақ* < арҗак – арйак (аръяк) һ.б. Мондый күренеш сирәк.

Калмак сөйләшенә дә *й*-лаштыру хас: *йаулық* – яулык, *йәйәү* – җәйәү (җәяү), *йәйен* – җәйен (җәен), *йөрү, йийыштырды* – җыйыштырды (җыештырды) һ.б.

Татар теленең үз сүзләрендә *қ* авазы үзе саклана: *қан* – хан, *қатын* – хатын, *йақшы* – яхшы һ.б. Гарәп-фарсы алынмаларында еш кына ***қ~х***, ә сүз азагында *х* бөтенләй төшә: *қәбәр* – хәбәр, *ника* – никах һ.б. ***қ~х*** чагыштырмача сирәк очрый.

Шуның белән бергә, калмак сөйләшенә дә, башка күпчелек сөйләшләрдәге кебек үк, *қ/к* авазларын спирантлаштыру хас: *Орхийә* – Оркыя, *тырах* < тырак – тракт, *тахйа* – такыя – бүрек һ.б.

Татар теле һәм аның сөйләшләре өчен дә ят фарингаль *h* авазы төшә: *аман* – һаман, *аwа* – һава, *Әдийә* – Һәдия, *уш* – һуш, *Зөрә* – Зөһрә, *тәрәт* – тәһарәт, *Гөлчан* – Гөлҗиһан, *Майсипә* – Маһизифа һ.б.

Аерым сүзләрдә генә күзәтелә торган тәңгәллекләр: ***б~ч:*** *бирқану* – чиркану; ***м~н:*** *тырмақ* – тырнак; ***мд~мн:*** *имдәргә* – имнәргә, *белгәнемде* – белгәнемне һ.б.; ***н~л:*** *тешнәү* – тешләү; ***з~д:*** *изән* – идән; ***й~ң:*** *мийә* – миңа, *сийә* – сиңа; ***ч~ш:*** *пәлеч* – бәлеш; ***й~ш:*** *йоморт* – шомырт; ***ш~с:*** *Шәмши* – Шәмси (Шәмсетдин) һ.б.; ***ш~к:*** *қыйыш* – кыйык (кыек); ***қ~у:*** *чолғақ* – чолгау; ***к~б:*** *көдрә* – бөдрә.

Калмак сөйләшендә яңгырау тартыкларның кулланылышы, башка себер диалектларыннан аермалы буларак, нигездә, әдәби телдәгечә: *Зөрә* – Зөһрә, *зәғыйп* – зәгыйфь, *бәйрим* – бәйрәм, *белгәнемде* – белгәнемне һ.б.

Шулай да, сүз уртасында бик сирәк кенә, яңгырауларның саңгыраулашу очраклары теркәлде: *токоз* – тугыз, *пестеңке* – безнең, *йурқан* – йурган (юрган), *Көлчийан* – Гөлҗиһан, *анта* – анда, *кәбәч/кәпәч* – түбәтәй, *Майсипә* – Маһизифа һ.б.

Ике сузык уртасындагы *с, ш, т* саңгырау тартыкларын яңгыраулаштыру актив:

*с: сазу* – сасы, *изү* < исеү – эссе, *ҷозоҷ* – диал. *косок* – эрбет чикләвеге, *ҷайзы* – кайсы, *йазау* – йасау (ясау) һ.б.;

*ш: шежә* – шешә, *пежерү/быжыру* – пешерү, *ҷыжын* – кышын, *йомжаҷ* – йомшак, *тырыжадыҷ* < тырышадык – тырышабыз, *сөйләжәм* – сөйләшәм, *йәжел* – йәшел (яшел) һ.б.;

*т: тадарча* – татарча, *ҷадын* – хатын, *бырады* – браты – энесе, *тадау* – диал. *тәтәү* – әти, *йарадам* – йаратам (яратам), *алабода* – алабута, *аду* – диал. *ату* – читек һ.б.;

*к/ҷ: күгерт – күкерт* – күк күкрәү, *йоғы* – йокы һ.б.

Ике сузык уртасындагы *ғ/г* авазлары редукцияләнә яисә аларга *w* соноры тәңгәлләшә: *уwыз* – угыз, *тәwермән* – тегермән, *тее/теге* – теге һ.б.

Авазларның охшашлануы (ассимиляция). Тел очы *н* тартыгы үзенең алдындагы авазларга өлешчә охшашлана: *безденке* – безнеке, *көштөнкө – көштнеке* – итнеке һ.б.

Саңгырау *(w, к)* тартыклардан соң килгән күплек һәм башка кушымчалардагы *л* соноры үзеннән алдагы саңгырау авазларга охшашлана; сонорлардан соң – яңгырау *д* авазына күчә: *кийнөктөр* – күлмәкләр, *йәштәр* – яшьләр, *чәчкәндәр* – чәчкәннәр, *йалдыйлар* – яллыйлар, *сыстай* – сызлый, *эштәдек* – эшләдек, *ҷорсаҷту* – корсаклы, *йәңдү* – җиңле, *ништәй* – нишли, *туҷту* < диал. *туклы* – туклыклы һ.б.

Кире һәм тулы ассимиляция очраклары түбәндәге сүзләрдә теркәлгән: *менен* – белән, *чөчө* – төче, шулай ук: *бессең* – безнең, *колосса* < колодец (кое) һ.б.

Авазларның охшашсызлануы (диссимиляция): *бер ләт* – бер рәт, *ҷылбағыш* – көнбагыш, *чөмөш/чүмеш* – чүмеч, *чычҷан* – тычкан, *орыччы* – русча һ.б.

Тартыкларның төшүе. *л, н: исәгән* – исләгән – абайлаган, хәтердә тоткан, *муча* – мунча, *күптә йуҷ* – күптән юк – күптән түгел, *йуғату* – йугалту (югалту) һ.б.; *т: асында* – астында; *тырах* < тракт, *сирбан* – сервант; *ғ: йома*– җомга; *w: күгөөн* – кигәwен (кигәвен); *й: чинаҷ* – чынайак (чынаяк).

Икеләтелгән авазлар кыскара: *минән* – миннән, *араснан* – арасыннан, *анан* – аннан, *аwзынан* – авызыннан, *килгәнәр* – килгәннәр, *әлә* – әллә, *изү* < исү – эссе һ.б.

Тартыклар өстәлү. *с: сәwәләп* – әwәләп (әвәләп), *г: илгәк* – иләк. *т: йелткә* – җилкә, *к: экке* – ике. *қ/к: хәтлек* – хәтле, *чанақ* – чана. *йеткенчек* – җиткәнче, *қайтқынчық* – кайтканчы.

Этимологик *л* саклану: *толтырба* – тутырма, *өлтөргөн* – үтергән.

Авазларның урыны алмашыну (метатеза) очраклары бар: *чолоқ* < чолка – оек, *курч'ук* < кр'учок – рус. крючок, *чөпчәрә* – диал. *чөчпәрә* – пилмән, *бала-барқа* – бала-чага һ.б.

### *Морфологик үзенчәлекләр*

**Исемнәр.** Исем сүз төркеменең грамматик категорияләре, аларны белдерә торган чаралар, нигездә, әдәби телдәгечә. Шулай да, калмак сөйләшендә бу өлкәдә дә характерлы үзенчәлекләр табыла.

Иркәләү-кечерәйтү сөйләштә татар әдәби теленә хас *-қай/-кәй, -чық/-чек* кушымчалары белән белдерелә: *Мәрхүмкәй, инәм сүли иде.*

Бу кушымча ярдәмендә диалектизмнар да ясалган: *әчегәй/иҗекәй* – корт (кызарганчы кайнаткан эремчек), *сарғай* – сарана, *эшләкәй* – тел кереше, *чалқай* – кычыткан һ.б.

Кеше исемнәренең кыскаруы һәм аларга *-й, -уқ/-үк, -қай/-кәй, -ч, -ш* иркәләү-кечерәйтү кушымчалары ялгану күренеше бар: *Сибай* – Сибгатулла, *Баркай* – Барый, *Wәсүк* – Вәсимә, *Мәтүк* – Мәдинә, *Файзуш* – Файзулла һ.б.

Мөрәҗәгать итү, эндәшү формасы, тау ягы керәшеннәре һәм себер сөйләшләрендәге кебек, *-ау/-әү* кушымчасы белән ясала: *бабау* – бабай, *мамау* – әби, *абау* – апай, *тәтәү/тадау* – эти, *инәү/инау* – әни һ.б. *Ғәйшә мамау дийәдек без* – Без Гайшә әби дибез.

Нисбәтлелек белән бәйле үзенчәлекләр. Калмак сөйләшендә гомуми нисбәтлелекне белдерә торган *-нықы/-неке* кушымчасы, әдәби һәм тарихи тулы вариантта да кулланыла. Әдәби

телдән аермалы буларак, ул хәбәрлек составында түгел, бәлки аергыч булып килә. Мәсәлән: *Қандықныңқы төбен ашайлар* – Кандыкның (Себер ягында үсә торган үлән) тамырын ашыйлар. *Чын қалмақтардыңқы сөзләрен өжөтөп* – Чын калмакларның сүзләрен ишеткән.

*-ныңқы/-неңке/-нықы/-неке* кушымчалы аергычлар еш кына инверсияләнәләр: *Уйықлы-чийықлы қунычы атунықы* – Читекнең кунычы каюлы-каюлы.

Сан категориясе. Калмак сөйләшендә бу категориянең ясалышында үзенчәлекле күренешләр бар. Әдәби телдәге кебек, ул *-лар/-ләр,* борын авазларына беткән сүзләрдән соң *-нар/-нәр* кушымчасы белән ясала. Шунысы характерлы, күплек кушымчалары иренләшү гармониясенә буйсыналар һәм, еш кына, иренләшкән вариантта *(-тор/-төр/ -нор/-нөр* һ.б.) да кулланылалар. Традицион сөйләштә аның ассимиляцияләшкән вариантлары да күзәтелә. Мәсәлән, саңгырау авазларга беткән сүзләргә күплек кушымчасының *-тар/-тәр/-тор/-төр* вариантлары ялгана: *ал'бомнор* – альбомнар, *қоноқтор* – кунаклар, *йэлэктөр* – җиләкләр, *йәштәр* – йәшләр (яшьләр), *аттар* – атлар һ.б.

Сонор яки яңгырау авазларга беткән сүзләргә әлеге вариантның яңгырау төре ялгана: *өлөндөр* – үләннәр, *балдар* – баллар (бал – мёд).

Икенче иҗектәге киң әйтелешле авазлар тарая, мондый очракларда бу сүзләргә ялганган күплек кушымчалары да тар вариантта әйтелә: *бәйримнир* – бәйрәмнәр, *әйбирлир* – әйберләр, *балылыр/баллыр* – балалар һ.б.

Килеш категориясе. Иялек һәм төшем килешләре, әдәби *-ның/-нең, -ны/-не* кушымчасы белән беррәттән, *-тың/-тең, -ты/-те* (саңгырау авазлардан соң), *-дың/-дең* (сонор яки яңгырау авазлардан соң) вариантлары ярдәмендә ясалырга мөмкин, тик бу күренеш, нигездә, өлкән буын вәкилләре сөйләшендә күзәтелә: *Әле пичте бозадық* – Әле мичне сүтәбез.

Юнәлеш килештә саңгырау авазга беткән исемнәргә яңгырау варианттагы кушымча ялганырга мөмкин: *Абасы* (апасы) *көйөүгә урысға* (руска) *чықты.*

I һәм II зат берлек сандагы тартымлы исемнәр төшем килешендә кыпчак тибында да *(ны/-не),* угыз тибында да *(-ы/-е)* формалашырга мөмкин, тик мондый күренеш сирәк очрый: *йоломо/йоломны* – йулымны (юлымны). *Күземе қан йәйде* – Күземне кан басты.

**Алмашлыклар.** Аларның составы, төркемчәләренең ясалышы-төрләнеше калмак сөйләшендә дә, нигездә, әдәби телдәгечә. Шул ук вакытта кайбер аерымлыклар да бар.

Нисбәтлелек кушымчасы алмашлыкларда да *-ныңқы/-неңке/-нықы/-неке/-дыңқы/-деңке/-тыңқы/-теңке* вариантларында күзәтелә, бу кушымчаны алган алмашлыклар, әдәби телдәгечә хәбәрлек составында түгел, ә бәлки аергыч ролендә киләләр. Мисаллар: *Анықы* (аның) *қызы Алабуғада тора. Мэнеңке адаминэм оуқығаннар* – Минем ата-анам – укыган кешеләр. *Сәнеңке инәң қалмақма?* – Синең әниең калмакмы? *Безденке ал'бомнор бар* – Безнең альбомнар бар.

Зат алмашлыклары: *мэн /мән /мин* – мин, *сэн/сән/син* – син, *ал/ул* – ул, *пес/бес/бесләр/без* – без, *сез/сезләр/сләр* – сез, *улар/алар* – алар. Мәсәлән: *Мән ләчинкәле туғач йарадам* – Мин эчле кабартма яратам. *Сезләр* (сез) *килү алнында ғына туқтады йамғыр. Уларға барганда мамауға да кердем* – Аларга барганда әбигә дә кердем. *Сләр қоноқтор болодоларма?* – Сез кунаклар буласызмы? *Мән сурадым анан* – Мин аннан сорадым.

Алмашлыкларның төрләнеше. *Мин, син* алмашлыкларының иялек килешендә тамырдагы *-н-* төшә һәм түбәндәге вариантлар барлыкка килә: *мийең/мийң/минең* – минем; *сийең/сийң/синең* – синең, *аның/ааң/аң* – аның. Мәсәлән: *Мийең әтийем аwылдыңқы* (авылныкы). *Минең инәм дә эштәде* (эшләде). *Сэнең дә баллар алтаума* (алтымы)*? Мийң* (минем) *бер малайым* да *киткәне йуқ. Минең тәтәм анда эштеды, күрөзен* – Минем әтием анда эшләде, күрәсең. *Мийң кийнок қоштонно* – Минем күлмәк балитәкле. *Аң* (аның) *йанына қалық йөрөткән* (йөри торган) *иде.*

Иялек килешендә сөйләшкә хас охшашлану күренеше чагыла: *Сездеңкеләр алар* – Сезнекеләр алар. *Бессең мамау ника оуқытты* – Безнең әби никах укытты.

*Мин, син* зат алмашлыклары юнәлеш килешендә *мәңә/миңә/ мийә, сәңә/сиңә/сийә* формаларында кулланыла: *Эреңә* (иреңә) *мамау* (әби) *булғач, мийә дә мамау* (миңа да әби) *була. Сәңә дә кәрөкпө әпәй?* – Сиңа да кирәкме ипи? *Иртән көн болбасба сиңә* (булмасмы сиңа).

*Ул* зат һәм күрсәтү алмашлыгы юнәлеш килешендә *аныңа* формасында да ясала (чагышт.: пермь сөйләшендә мондый форма барлык зат һәм күрсәтү алмашлыкларында күзәтелә): *Аныңа* (аңа) *бардым, айақлары шешкән.*

Күрсәтү алмашлыклары. Калмак сөйләшендә аларның составы, нигездә, әдәби телдәгечә, аерымлыклар исә аларның фонетик яңгырашларында чагыла: *бу/бы/би* – бу, *ол/ул/у* – ул, *менәкә/менә* – менә, *теге/тее/ти* – теге, *мондый; андый* – андый, шундый; *монча* – моның хәтле һ.б. Мисаллар: *Аурыб алдым менәкә қату* – Менә каты авырып алдым. *Бы сыу чумған* – Бу су коенган. *Бу құрқай* (курка) *икән, бармаған. Әле тее wақ* (черки) *чықты, мөшкә. Үремнәре монча иде* – Толымнары моның хәтле иде. *Бусаға аша әйбер алырға да йарамый, бийағына* (бу ягына) *чығыб аласың. Ол тау башқа кәттек, соу чәчештек.* – Шул тау башына киттек, су сибештек. *Анауны айырды икегә* – Әнә аны икегә бүлде. *Теге дөнйада* (коймаклар) *пежерәлмәссең* (пешерә алмассың). *Майға салған соң, ул қабара. Ти + йағын* (теге ягын) *әйләндерәгә түгел аның. Бу йәш әле минән* (миннән).

Традицион сөйләшкә *шул* һәм аның нигезендә ясалган *шундый, шулай* һ.б. алмашлыклар хас түгел. Мәсәлән: *Песнеңке тәтәү ол йақтан* – Безнең эти шул яктан. *Кәбиттә безнеке андый, йомжақ* – Безнең кибеттә шундый (икмәк), йомшак. *Марда* (балык тоту җиһазы) *йасағаннар талдан өреп, эженнәр булған, көлтә* (көлтә) *қоротқаннар, элек андый* (шундый) *булған.*

Алмашлыкларның төрләнеше әдәби телдәгечә. Шулай да кайбер аерымлыкларны күрсәтеп үтәргә кирәк.

*Белән, кебек* бәйлекләре алдында килгән иялек килештәге алмашлыкларның азагында *ң* авазы кыскара: *Мырмашовка диләр, аны* (аның) *белән балық тоталар. Мине* (минем) *белән*

*бер йәшле қызлары үлде. Безне кебекләр* (безнең кебекләр) *барысы да китте соуғышқа.*

Чыгыш килешендә ике *н (-нн-)* авазының берсе кыскара, азакта ***ң ~ н:*** *Минәң бәләкәйе* – Миннән кечкенәсе. *Анаң кәтте* – Аннан китте. *Өч бала қалған анаң* (аннан). *Анаң сун* (аннан соң) *инде өй салдылар. Минәң олу әwәм* (апам) *Минусинискида. Қапқасы тегенәң* (тегеннән).

Сорау алмашлыклары: *кем, нә/ни//нәрә/нәстә* – нәрсә, *қанча* – ничә, күпме, *қандий* – нинди, ничек; *қаа/қайа* – 1) кая; 2) кайда; *қайчан* һ.б. Мәсәлән: *Қанча йәштә?* – Ничә яшьтә? *Бозау қандый була, тай да андый* – Бозау нинди була, тай да шундый (ягъни, тай колын дигән сүз). *Қайа аптырады икән* – Кая ашыкты икән. *Шәлем қаадыр* (кайдадыр). *Қызны бирмәгәннәр, буш қандый* (ничек) *қайтырға кирәк. Нәстә теләдем, аны ашадым. Қанди әле?* – Ничек әле? *Әллә қандийрәк бо пичә* – Әллә ничегрәк бу хатын.

*Қайчан* сорау алмашлыгы «кайвакыт» мәгънәсендә дә кулланыла: *Күкрәге белән бергә озон партык* (алъяпкыч) *кигәннәр, қайчан* (кайвакыт) *йақасы да булған.*

Билгеләү алмашлыклары: *бөтенесе/бөтөрәсе* – бөтенесе, *әр* – һәр, *әммә йуғы* – барысы, бөтенесе; *өйсө/өсө/үзе* – үзе. Мәсәлән: *Әммә йуғымны орлап ташладылар* – Барысын урладылар. *Ашны* (токмачны) *үзе йасай ул. Нәрсә тели, бөтөрәсен* (бөтенесен) *йасайлар туйға. Без сәгез қыз, барыбыз да теребез.*

Юклык алмашлыклары, әдәби телдәге кебек, сорау алмашлыклары алдына *бер* яки *һич* сүзләре ялганып ясала: *бернәстә* – бернәрсә, *беркем/ичкем* – һичкем, *ичқаа/ берқаа* – беркая, *берқайда* һ.б. Мәсәлән: *Қайтып төштек, бернәстәбез йуқ. Ичкем белбәгән, ичкем көрбәгән* – Һичкем белмәгән, һичкем күрмәгән.

Калмак сөйләшендә билгесезлек алмашлыклары да әдәби телдәгечә ясала: *Нәдәр болғон, сөйләшбәй* – Нәрсәдер булган, сөйләшми. *Қаадыр аныңы ағачы булады* – Кайдадыр аның агачы була.

**Сыйфатларның** грамматик категорияләре, семантикасы һәм синтаксик функцияләре әдәби телдәгечә. Бары тик *-лы/-ле*

кушымчасының *-лу/-лү, -ту/-тү* вариантларында әйтелүе генә калмак сөйләшенә үзенчәлекле төсмер өсти: *Қорсақту болғон* – Корсаклы булган. *Малды-қожту кэлде килен* – Килен маллы-кошлы (мал-туарлы) килде.

**Рәвешләр.** Әдәби телдәге *-дай/-дәй* кушымчасы калмак сөйләшендә тар вариантта кулланыла: *Чәчләре қамыштий. Самза* (чәкчәк) *чәчәктий матур була.*

*-лай/-ләй* рәвеш ясагыч кушымча сөйләштә шулай ук актив: *Ақчалай* (акчалата) *да бирделәр, ипи дә бирделәр. Әтийем йәшләй үлде.*

Ел фасылларын һәм тәүлек вакытларын белдерә торган сүзләрдән вакыт рәвешләре әдәби формалар белән дә (*қышын, йәйен* – җәен һ.б.), башка чаралар ярдәмендә дә ясала.

*-ын/-ен: Йәйен чачадылар, печән чабадылар* – Җәен чәчәләр, печән чабалар. *Йәйен арба, қышын чанақ қулдан төшмәде. Иртән қайтасыз.*

*-ғылық/-гелек, -қылық/-келек: Қышқылық иликтр йанмады. Қышқылыққа оутын кертәм. Йәйгелек өчен эспүшкә* (кечкенә өй) *салдылар.*

*-қыда/-кедә: Қар төрлечә була қышқыда* (кышын).

*-қы/-ке/-қо + көндә: Қошқо көндә йаулықтан, мамық шәлем дә йуқ.*

Бәйлек сүзләр белән: *Қыш wахытны* (кышын) *қычу чанақ* (кечкенә чана) *белә китеп қала иде. Көм буйына* (көн буена) *йағып тора идек пичте. Қайтты иртәсе белә* (иртә белән). *Қар белән йаңғыр йаз-көз wахытта.*

**Фигыльләр.** Бу сүз төркеменә хас категорияләр (зат, сан, вакыт һ.б.) әдәби телдәгечә. Сөйләштә аларның формалашуы белән бәйле кайбер аерымлыклар да бар.

Юклык категориясе калмак сөйләшендә *-ба/-бә/-па/-пә (-ма/-мә)* кушымчасы белән ясала: *оуқытпады* – укытмады, *белбәйем* – белмим, *болбасба* – булмасмы, *топтаған* – тотмаган, *эш пөтпәй* – эш бетми һ.б. Мәсәлән: *Песнеңқеләр чәчпәделәр микән. Кэлбэсен* (килмәсен) *дип йазған. Албайдым* – Алмыйм. *Қонбойсоңмо?* – Кунмыйсыңмы?

Затланышлы фигыль формалары. Хәзерге заман хикәя фигыльнең әдәби формасы I зат берлек санда тулы һәм кыска вариантларда күзәтелә (чагышт.: әдәби телдә һәм күп кенә сөйләшләрдә дә шулай ук): *Мән оуқытамын* – Мин укытам. *Мән сөйләжәм тадарча* – Мин татарча сөйләшәм. *Су ийәсе тарта, мин қурқаймын* (куркам).

Кушымчаларда әдәби телдәге *-ый/-ий* урынына *-ай/-әй* әйтелергә дә мөмкин, тик ул системалы түгел. Мондый хәл калмакларга катнашкан этник компонентларның йогынтысы көчле булу белән аңлатыла булса кирәк: *Тадарча йырлайбыз* (җырлыйбыз). *Тешем сыстай, азаwы сыстайды* (сызлый).

II зат берлек сан кушымчасында тарихи *н* саклана: *Қазы тығасын* (тыгасың – тутырасың) *ат суйсан, анан ашайсын* (ашыйсың).

II зат күплек сан берлек формасына *(-сың/-сең)* өстәмә рәвештә *-ар/-әр* (< *-лар/-ләр)* кушымчасы ялганып ясала: *Бы йаққа барасыңар* (диал. *барасыңнар*) – Бу якка барасыз. *Күрсәтергә апқайтасыңар* (алып кайтасыңнар > алып кайтасыз).

Хәзерге заман хикәя фигыльнең калмак сөйләшенә хас традицион формасы *-ады/-әде/-ыйды/-иде* кушымчасы белән ясала һәм 2 нче төркем зат кушымчалары ярдәмендә төрләнә: *аладым, аладың, алады, аладық, аладыңыс, алады(лар).* Мисаллар: *Самза пыжырадық, йеде-сэгез қадын* – 7–8 хатын чәкчәк пешерәбез. *Без аларны чақыртадық, тырыжадық, өстәлләр йасайдық* – Без аларны (өлкәннәрне) чакыртабыз, тырышабыз, өстәлләр ясыйбыз. *Чабата болғон, қаадыр анықы ағачы булады* – Чабата булган, кайдадыр аның агачы була. *Қырық көн булады* (була). *Быраады аныңкы монда торады* – Аның энесе монда тора. *Ақча бэрбэйте* (бирми). *Эжек ачық, анта таwықтар, қойлор торото* – Ишек ачык, анда (ул абзарда) тавыклар, сарыклар тора. *Пөгөн китөдө алар* – Алар бүген китә. *Өн салып сықтайды* – Кычкырып елый. *Белбидем, қаа китт+икән* – Белмим, кая китте икән. *Әле пичте бозадық* (мичне сүтәбез).

*-ды/-де* кушымчасы саңгырау вариантта да әйтелә, тик ул сирәгрәк. Бу исә калмак сөйләшендә саңгыраулаштыру

күренешенең пассив булуы, чикләнгәнлеге һәм ике сузык арасында *т* авазының яңгыраулашуы белән аңлатыла.

Көнчыгыш диалектларның башка сөйләшләрендәге кебек үк, әлеге сөйләштә дә *-ты/-те* кушымчасы башка сүзләргә, сорау алмашлыкларына да ялгана: *Әнийемте* (әнием) *инде минеңке йәшләй қалған.*

Хәзерге заманның аналитик формалары. Калмак сөйләшендә эшнең гадәтилеген, даимилеген белдерә торган *-тқан/-ткән (-а торган/-ә торган)* формасы бар: *Өлчөйткөн бездеңке тадау* – Безнең эти гадәттә үлчи. *Йәйен тачок була торған, былафкы уйный идек* – Җәй көне гадәттә кичке уен була, йөзек салыш уйный идек. *Силос салатқанбыз өлөннәң* – Үләннән гадәттә силос салабыз. *Ураган дип қойотқомбыс* – Ураган дип куябыз (көчле җил иссә).

Эшнең шушы мизгелдә башкарылуын белдерә торган *-ып/-еп + утыра* яки *йата* төзелмәсе: *Ана, Көлчийаның кэлеб утыра* – Әнә, Гөлҗиһаның килә. *Мин барғанда мамайы қайтыб утыра* (әбисе кайтып килә). *Сез өй сайын йөреп йатасыз* (йөрисез).

Үткән заманнар. Билгеле үткән заман, әдәби телдәге кебек, *-ды/-де/-ты/-те* кушымчасы белән ясала, төрләнеше дә әдәби телдәгечә: *Ул молло болдо айылда* – Ул мулла булды авылда. *Кийноктөр тектеләр йәжел* – Яшел күлмәкләр тектеләр. *Чабата болған, без кибәдек* – Чабата булган, без кимәдек. *Печинд + эштәдек, берг + өстөк* – Печәндә эшләдек, бергә үстек.

II зат күплек сан *-(н/ң)ор/-н(ң)өр* (< *-нар/нар)* кушымчасы белән ясала: *Көрдөңөрбә?* – диал. *көрдөңнәрме?* – күрдегезме? *Барка бабаға кердиңэрмү?* – Барка бабага кердегезме?

Билгеле үткән заман функциясендә *-ған/-гән* формасы кулланыла, ул I затта тартым кушымчалары да ала: *Без анда торғанбыз* – Без анда тордык. *Тайғаға* (ав. ис.) *кучеп киткәнебез* (киткәнбез).

Күптән үткән заман, әдәби телдәге һәм татар теленең күпчелек сөйләшләрендәге кебек, *-ган/-гән* һәм *иде* ярдәмче фигыле белән ясала: *Монан көлгән идем* – Моннан көлгән идем. *Көп килгөйнилэр, бийүлөрө көп болды* – Күп килгәннәр иде (артистлар), биюләре күп булды.

Нәтиҗәле үткән заман, әдәби телдәге кебек үк, *-ған/гән* кушымчасы белән ясала: *Бер бала тыwғансың* (тапкансың), *чачың аппақ. Терәнгән килеш қалқып киткән* – Сөялгән килеш йоклап киткән. *Өчөрөп* (сүндереп) *қуйғансыз тилебизырны. Инәсе көрбөгөн* – Әнисе күрмәгән.

II зат күплектә зат кушымчасы *(сыс/-сес<-сыз/-сез)* кыскара: *Беркемдә дә чай эчмәгәндерес* (эчмәгәнсездер).

Калмак сөйләшендә дәвамлы үткән заманның түбәндәге формалары күзәтелә:

*-а + иде: Киндераш, дары бырын чәчәләр иде* – Элек киндер, тары чәчәләр иде. *Тадарча кыруk уйный идек* – Татарча түгәрәк уен уйный идек. *Қаш қарайталар иде.*

Бу конструкциядә зат кушымчасын төп фигыльгә ялгау очраклары да бар, тик бу күренеш сирәк: *Суғып суқмада ашыйбыз иде киндерашны* – Киндер орлыгын киледә төеп ашый идек.

*-а/-ә торған/-атқан/-эткән: Көләч қазып, көләчтән алатқан идек тәмне соу* – Чишмә казып, чишмәдән ала торган идек тәмле су. *Элек зор алтын сырға* (алка) *бар иде, дутый дип қуйа торған ийек. Тоқмоқ йазый торған идек* – Тукмак ясый торган идек. *Қалықтан җийштырып йөрөткөн идек* (йөри торган идек). *Айыл арқылы Йургаға* (ав. ис.) *барат иде* – Авыл аркылы Юргага бара торганнар иде.

*-ыр/-ер иде* (бу форма бик сирәк): *Йәйен одордық* – Җәен утар идек.

Билгесез киләчәк заман кушымчаларында фонетик үзгәрешләр күзәтелә. Иренләшү: *Сийлөр сезгә көп* – Сезгә күп сөйләр.

Киң авазларның тараюы яисә, киресенчә, тар авазларның киңәюе: *Анда барарсыз* (барырсыз). *Басмыйм дисәң дә басарсың, тормош булғач. Малдарын күрәр* – Малларын карар.

II зат күплектә *-лар/-лар* күплек кушымчасы өстәлә: *Қарт бабайлардан сорарсызлар* (сорарсыз). *Бала-барқаңа* (балачагаңа) *сәләм әйтерсезләр.*

Юклык формасы *-пас/-пәс/-бас/-бәс,* сирәк: *-мас/-мәс* кушымчасы белән ясала: *Ул тиз чықпас* (чыкмас).

I затта кыскарган вариантлар да күзәтелә: *Алдыйлар аны, йарар, барымын* (барырмын) *тип. Ничек қайтырым* (кайтырмын) *дип қайғырып торам.*

I зат күплек сан *-ық/-ек* кушымчасы белән ясала: *Барарық адаларына дигән* – Аталарына барырбыз дигән. *Қоноққо чакырды, барарық* – Кунакка чакырды, барырбыз.

Боерык фигыльнең II зат берлек саны, әдәби форма белән беррәттән, керәшен һәм мишәр сөйләшләрендәге кебек, *-ғын/-ген* кушымчасы ярдәмендә дә ясала: *Ашлық алғын, ти, ақча бэрбэйте* – Ашлык ал, ди, акча бирми. *Ачқын, ачқын қыйарларыңы* – Ач, ач кыярларыңны.

II зат күплек сан *-ың/-ең* кушымчасы белән ясала. Шуның белән бергә, калмак сөйләшендә бу форма тагын да үзенчәлеклерәк, чөнки аңа өстәмә күплек кушымчасы *(-нар/-нәр/-ар/-әр)* да ялгана: *Анта барып тороңар* (торыгыз) *ти. Тайгаға* (ав. ис.) *бармаңнар* (бармагыз) *дейде бабай.*

Теләк фигыльләрнең калмак сөйләшендә әдәби һәм диалекталь формалары кулланыла: *Сләргә чәй қойобалыйқ* – Сезгә чәй ясыйк. *Хәзер әйтәйен* – Хәзер әйтим әле. *Түгәрәккә пешеримме қуқай?* – Йомырканы йомрылата пешеримме? *Сөләп бирийем* – Сөйләп бирим.

Эчке теләк *(-асы/әсе + кил-)* калмак сөйләшендә дә, мишәр һәм барлык себер диалектларындагы кебек үк, *-қы/-ке/-ғы/-ге/-ақ/-әк + кел-/кил-* төзелмәсе белән белдерелә, зат, сан кушымчалары – төп фигыльгә, юклык кушымчасы ярдәмче фигыльгә ялгана: *Айылда берәү дә йәшәгесе килми* – Берәүнең дә авылда яшисе килми. *Кем саwаб + алғысы килә, чәйнүктә соу биреп тора, йиде чәйнүк* – Кемнең саваплы буласы килә, комган белән су биреп тора, җиде комган (мәетне юганда).

Әдәби форманы куллану очраклары да бар: *Аwылны сағынып* (сагынганмын), *анда торасым килмәде.*

Ният, әдәби телдәге кебек үк, *-мақчы/-мәкче* кушымчасы белән белдерелә: *Тумға бармақчы була балықларға* – Томга (елга исеме) бармакчы була балык тотарга.

Татар теленең күпчелек сөйләшләрендә таралган *инфинитив + итә* ярдәмче фигыленнән торган төзелмә дә күзәтелә: *Әwә, Пәридә мамау аны имдәргә йитә* – Апа, Фәридә түтәй аны имләмәкче була.

Юнәлешләр. Йөкләтү юнәлешен *-гыр/гер, -кыр/кер, -ғаз/-гәз/-ғыз/-гез* кушымчалары белән ясау әдәби тел белән чагыштырганда киңрәк күләмдә күзәтелә: *Алты баланы үзем үскердем* (үстердем). *Күземе қан йәйде, қызым балнисаға йөрғөзде* – Күземне кан басты, кызым больницага йөртте. *Тешле баранасы* (тырмасы) *бар, тот та йөргез* (йөрт), *суқа белән сөрдек. Өйгә чит тенне керкезмәң тигән* – Өйгә чит динне кертмәгез, дигән. *Суwақ үткэзип бетергин* – Суык тидереп бетергән.

Бер юнәлеш урынына икенче юнәлеш формасы куллану очраклары бар: *Йыwышың қоллороғоздо* – Кулларыгызны юыгыз. *Сезнең халық бик бәйләнә* (бәйли) *бит. Бераз эшләрне эшләнделәр* (эшләделәр) *дә, кэтеп қалды. Әйтешкәннәрдер* (әйткәннәрдер), *мин белмәйем.*

Затланышсыз фигыль формалары. Инфинитив. Калмак сөйләшенә инфинитивның әдәби формасы *(-ырга/-ергә)* хас. Шулай итеп, сөйләш себер диалектлары системасындагы башка сөйләшләрдән аерылып тора һәм зур үзенчәлеккә ия. Мисаллар: *Су чумарга керәсең, соу йып-йылы анта* – Су коенырга керәсең (суга), су җып-җылы анда. *Дусларымның қәтре калған, Ничек бәқилләтергә* (халык җыры). *Әни бирмәскә тырышты, бармассың тип. Аның кешесе кирәк йунатып* (юнәтеп) *йөрергә. Ничек барбасқа керөк.*

Урал һәм Себер төбәкләрендә таралган татар сөйләшләрендәге кебек үк, инфинитив *белү, башлау* фигыльләре белән бәйләнешкә керә һәм әдәби телдәге *-ып/-еп, -а/-ә* кушымчалы хәл фигыль функциясен башкара: *Йәштәр йырларға* (җырлый) *белмиләр. Мән бәйләнергә белбәйдем* – Мин бәйли белмим.

Исем фигыль. Калмак сөйләшендә дә, әдәби телдәге кебек, исем фигыль *-у/-ү* кушымчасы белән ясала: *Баллар қайтуwына пәлеч пешердек. Элек* (эшкә) *соңға қалу йоқ иде. Элке көдрә йасау йоқ* – Элек бөдрә ясау (чәч бөдрәләтү) юк (иде).

Билгеле бер төркем сүзләрдән *-мыш/-меш* кушымчалы формалар ясала: *Әйтмеш* (әйтү) *буйынчы ғына пежерәлмәссең* (пешерә алмассың).

Сыйфат фигыльләр, нигездә, әдәби телдәгечә. Сөйләшкә хас үзенчәлекләр аларның фонетик вариантларында чагыла.

Хәзерге заман сыйфат фигыльнең *-тқан /-ткән /-а торған/-ә торған* формалары актив кулланыла: *Қой қыратқан қайчы* – Сарык йоны ала торган кайчы. *Йыwышатқан қомған* – Юына торган комган. *Өй түбәгә чыға торған бачқыч* – Чормага менә торган баскыч.

*-ыр/ер, -ар/-әр: Бу йерләр су басар болоннар* – Бу җирләр – су баса торган болыннар. *Йебәрәр ойо йоқ* – Җибәрергә исәбе юк. *Майға салыр чақта қамырны тартып-тартып йибәрергә кэрәк.*

Үткән заман сыйфат фигыль: *Абаудың чыққан бәрәңге чөбөн кақтық.* – Апаның бәрәңге (арасына чыккан) чүбен утадык. *Бәйлиген көчөк өрдө.* – Бәйләгән эт өрде.

Хәл фигыльләр. *-ып/-еп* кушымчалы хәл фигыльнең семантик функцияләре әдәби телдәгечә: *Мамайлардан соражып йазалар* – Әбиләрдән сорашып язалар. *Ашық уйный идек, соу буйынан таш йийып* – Су буеннан таш җыеп, бишташ уйный идек. *Айақлары йеңел болып* (булып), *йаңғыр йауды алар килгәч.*

Сөйләштә бу форманың юклык кушымчасы *-майчы/-мәйче, -мыйча/-мичә* вариантларында күзәтелә: *Йамғыр болмайчы қороп қалды йелэктэр* – Яңгыр булмыйча, җиләкләр корыдылар. *Қышын артлы кашаwайда күчергәннәр киленчәкне, йәш малайлар арқан тотқаннар, керетмичә қапқада.*

Калмак сөйләшенең специфик үзенчәлекләреннән берсе *-ып/-еп* кушымчасының төшүе: *Тағы лә + китте* (эләгеп китте). *Нәғыйм қайт + китте* (кайтып китте). *А + қайтып сандығына басқан* – Алып кайтып сандыгына тыккан. *Әкип* (< эпкилеп) *қойдо* – Алып килеп куйды.

Мондый күренеш әүштә-чат сөйләшендә аеруча актив, калмак сөйләшендә ул чагыштырмача сирәк очрый.

*-ғач/-гәч* кушымчасының түбәндәге вариантлары һәм эквивалентлары бар:

*-ғач/-гәч, -қач/-кәч* (әд. вариант): *Мән эчмәгәч белмимен әремне. Менәкә мән чәрләп киткәч кәлде инде. Мән кәлгәч зақ тормады;*

*-ғачын/-гәчен, -қачын/-кәчен: Алар Җиләдәйдә* (ав. ис.) *булғаннар, соу басқачын* (баскач), *тайгалыққа* (урманлыкка) *бу йаққа чыққаннар. Ол әйткәчен* (әйткәч) *кебиткә кердем қайтышлый;*

*-ғансын/-гәнсен: Минән олуwы үлде, үлгәнсен* (үлгәч) *монда ал + кәлеп* (алып килеп) *күмделәр;*

*-ғанчы/-гәнче, -қанчы/-кәнче* кушымчалы хәл фигыль кушымчасының *-ғынчы/-генче, -қынчы/-кенче, -ғынчык/-генчек, -қынчык/-кенчек* вариантлары күзәтелә: *Кәбиткә йеткенчек бер өй бар. Қысылып тормағыз, қайтқынчық чай эчеңәр* – Уңайсызланып тормагыз, киткәнче чәй эчегез. *Айгүл килгенче дорамын* (килгәнче торам).

**Ярдәмлек сүз төркемнәре.** Бәйлекләрнең составы белән калмак сөйләше әдәби телдән, нигездә, аерылмый, тик кайбер бәйлекләрдә фонетик үзгәрешләр чагыла: *менән/менен/мелен/белән/белә/белән* – белән, *хәтлек* – хәтле, *шикелле/шигелле* – шикелле; *кебек/күк/күwек* – кебек, *аша, сайын* – саен һ.б. Мисаллар: *Бусаға аша әйбер алырға да йарамый, теләнче булдыңмы диләр. Нүгәрләр йегетне қыз йанына озаталар, қыз күчергәндә сақчы шикелле озаталар, кәwеп-қәтәр булмасын дип. Арчақ менен* (аръяк белән) *қайтып китте.*

**Кисәкчәләр.** Сорау кисәкчәсе тар *(-мы/-ме,* ягъни әдәби) һәм киң *(-ма/-мә)* вариантларда әйтелә, сөйләшкә хас үзенчәлекләр белән бәйле рәвештә, аның күптөрле вариантлары бар: *-ба/-бә, -ма/-мә, -бы/-бе, -мы/-ме, бо/-бө, -мо/-мө, -му/-мү, -бу/-бү.* Мәсәлән: *Барба?* – Бармы? *Мамаwың кәләбә?* – Әбиең киләме? *Бер йәшле тайның йалына бер кәртмә кәсәләр йәшен белер өчен, ике йәшлегә – ике кәртмә* (киртек), *табунда күпмә* (күпме) *тай барын белер өчен. Қоноқтор болодолормо?* – Кунаклар буламы? *Кердиңәрмү?* – Кердегезме? *Көрдөңөрбә?* – Күрдегезме? *Қонбойсоңмо?* – Кунмыйсыңмы? *Журналиссыңарбы?* – Журналистлармы сез?

Татар теленең Урал һәм Себер төбәкләрендә таралган сөйләшләренә хас *қой/қуй* раслау кисәкчәсе калмак сөйләшендә дә күзәтелә: *Перг + өстөк қой, бергө+ штәдек* – Бергә үстек бит, бергә эшләдек. *Пес кошмодок кой* (бит) *аны.*

Калмак сөйләшендә *чы, ачы* кисәкчәсе кулланыла, ул раслауны, җөпләүне белдерә: *Қар белән йаңғыр, йаз-көз wақытта чы сл'акот' инде* (карлы-бозлы бит инде). *А-чы, Сәрийә, кәбит ачық қой* – Әйе шул, Сәрия, кибет ачык бит.

### *Синтаксик үзенчәлекләр*

**Сүзтезмәләр.** Исем-исем сүзтезмәләрдә, компонентлары нисбәтлелекне белдерсә, бәйләнеш бернинди кушымчасыз да була. Материаллар күрсәтүенчә, кушымчасыз бәйләнеш аеруча бәйлек сүзләр булганда күзәтелә: *Без йақта* (безнең якта) *бернәстә дә йуғыйде. Үзебез телдә сөйләшөбез* – Үзебезнең телдә сөйләшәбез. *Үзебез телдә төгел, Қазан телдә йырлайбыз* – Үзебезнең телдә түгел, Казан телендә җырлыйбыз. *Өй түбәгә* (түбәсенә) *шипер кәрәк. Зират тау башта* (тавы башында) *соу чәчештек* (сибештек). *Бес йақта айу йуқ* – Безнең якта аю юк.

Фигыль сүзтезмәләр. Кайбер фигыльләр башка килешне таләп итәләр: *Нигә аны* (аңа) *тийәсез сез? Айылыма сағынғам қой, қызым көүчереп алған* – Авылымны сагындым бит, кызым алып килде.

Исем-сыйфат сүзтезмәләрендә билгесез килештәге аерымланган аергычлар килеш кушымчасы алалар: *Мамайлар түгәрәкне кийеп қуйа бүрек* (түгәрәк бүрек), *өстеннән йаулық бәйлиде.*

Хәбәрлек. Исем хәбәрләр, татар теленең күпчелек сөйләшләрендәге кебек, калмак сөйләшендә дә зат кушымчалары ала: *Йәшсез әле* – Сез яшь әле. *Мән сурадым қой анаң, қазақсыңба, қырғыссыңба* – Мин аннан, син казакмы, кыргызмы, дип сорадым бит. *Син сөйлә, син беләрсең.*

Билгесезлек, фараз катыш сорау нәтиҗәле үткән заман формасы ярдәмендә дә белдерелергә мөмкин, бу аеруча II затта күзәтелә: *Wапа абзыйда булмағансыз* (булмагансыздыр)? *Чай эчмәгәнсес?* – Чәй эчмәдегезме?

Аналитик төзелешле гади яки кушма җөмләләр күзәтелә: *Қойаш қайа әйләнә, ул анда әйләнә, анын өчен келбағыш әйткәннәр. Аwырмасын, сызламасын өчен, әбиләр шыпшыйлар* (пыш-пыш укыйлар). *Нәрсә тели, бөтөрәсен* (бөтенесен) *йасыйлар туйға. Кем саwаб алғысы килә, чәйнүктә соу биреп тора, йиде чәйнүк. Қандий* (ничек) *әтерсең, андий күмәрләр* – Ничек әйтсәң, шулай күмәрләр.

### *Лексик үзенчәлекләр*

Калмак сөйләшенә үзенчәлекле лексика хас. Әмма төп лексик-семантик төркемнәрдәге нигез лексика татар теле белән уртак. Бер төркем диалектизмнар себер диалектлары өчен гомуми характерда. Биредә калмак сөйләшенә хас диалекталь сүзләрнең кайбер төркемнәрен берникадәр яктыртып үтәбез.

**Йолалар, гореф-гадәтләр**: *сеп* – бирнә (кыз әйберсе), *сеп салышу* – бирнә әзерләшү, *нүгәр* – кияү егете, *имдәү* – имләү, *тачок* – кичке уен, *былафкы уйнау* – йөзек салыш уйнау, *тадарча кырук* – әйлән-бәйлән, түгәрәк уен, *бичыринка* – аулак өй, *ашық уйнау* – бишташ уйнау, *доғалық* – бөти һ.б.

*Қорбанныққа үгөз алып суйдылар, пешереп сарандылар йамғыр, азан әйттеләр. Кийәү йулы дип күчтәнәч биргәннәр. Кумдыйда* (сандыкта) *булыр қызнықы приданнары. Киштем* – җирле халык атамасы.

**Туганлык атамалары**: *ада-инә* – ата-ана, *тәтәү* – әти, *мамау* – әби, әти-әнидән олы, кардәш яки чит хатын-кыз, *көкөм* – эне яки сеңелгә, каене яки каенсеңелгә, балдызга эндәшү сүзе, *қартәнәй* – әби, *қартәтәй* – бабай, *әкә* – абый, *йорчы* – 1) каене, 2) каениш, *тон бала* – беренче бала, *қанинә* - каенана һ.б. *Картопко отостық* (утырттык), *абамнар* (абыйлар) *олулар эде, алар эштәделәр.*

**Кеше һәм аны тасвирлый торган сүзләр:** *чығанақ* – беләзек, *төндер* – чукрак, *қалқып киту* – йоклап китү, *чынча бармақ* – чәнчә бармак, *эшләкәй* – тел кереше, *пичәл* – рахит, *тискәре* – кире, *кәс* – әшәке, явыз (кеше), *өн салып йылау* – кычкырып елау, *тезә* – тез, *тағым* – тез асты һ.б.

**Йорт-җир, хуҗалык эшләре һ.б.ны белдерә торган сүзләр:** *айыл* – авыл, *ызба* – өй, *синек* – өйалды, *кәсәнкә* – чолан, *түр* – сәке, *түр асты* – идән асты, *күшәгә* – сәкегә, караватка корган чаршау, тәрәзә, ишек пәрдәләре, чыбылдык, *тығым* – түшәм, түшәм тактасы, *тәwермән* – тегермән, *тешле барана* – тырма, *чау* – су чүмече, *стайка* – җылы абзар, *алны* – тышкы абзар, *тап* – йомычка, *одоу* – утау, *колосса* (< колодец) – кое, *урғыч* – урак, *балчы* – умартачы, *чырақ* – нечкә агач, кулга кадала торган шырпы), *суқмо/суқма* – киле, *тырмаwыч* – кул тырмасы, *тартмағач* – каба, *кол'ко* – кисәү агачы, *табадан/ табадын* – таба, *кәләсә* – тәгәрмәч, *чанақ* – чана, *тушник* – күмер чүлмәге, *тотқо* – табагач, *сәкәлүк* – уклау, *туғолоқ* – чынаяк чокыры һ.б. *Балыққа қатқан қалтыларын тотолар до китәләр. Қаймәл йамғыр – болбойда* кайвакыт, яңгыр булмый.

**Аш-су белән бәйле сүзләр:** *самза* – чәкчәк, *пиреженик* – ачы камырдан, эченә җиләк-җимеш салып, табадагы майда әйләндермичә генә пешерелә торган камыр ашы, *кош(т)/ көш(т)* – ит, *пыштақ* – сыр, *йурағанға* – төчегә (камыр турында), *ләчинкәле туғач* – эчле кабартма, *пәлеч* – бәлеш, *аш/озон аш* – токмач, *көрөч* – дөге, *мишкә май* – ак май, *лүпсә* – иттарткычтан чыгарылган кипкән шомырт, *чөпчәрә/шөшпәрә* – пилмән, *сөртмәч* – юка (камыр ашы), *арма* – куырмач, *әчекәй/иҗекәй* – корт һ.б.

**Кием-салым атамалары:** *артсалма* – жилет, *кәбәч/кибәч* – түбәтәй, *чарық* – чүпрәктән, тиредән яисә күннән теккән аяк кием, *мәләй/мәләй* – бияләй, *кийнөк/кинок* – күлмәк, *әйнек* – догалыклар салу өчен ясалган бәрхет янчык, култык астына асып куела, *пима* – киез итек, *өүтек* – итек, *йышым* – йон оек, *кашник* – беләзек (җиң очында), *китән* – киндер (тукыма), *чолок* – оек, носки, *күгезмөк* – сырган жилет, *қоштон* – балитәк, *төштөк* – түшлек (бизәнү әйбере), *кип* – кыяфәт *(Кипләре дә, төсләре дә шул уқ)* һ.б.

**Терек һәм терек булмаган табигать.** Җир-су һәм рельефны белдерә торган сүзләр: *тайғалық* – урманлык, *қойо* – бәке, *көләч* – чишмә, *бөк* – болын, су баса торган болын һ.б.

**Хайваннар дөньясы белән бәйле диалектизмнар:** *тайчақ* – тай, *қончақ* – колын, *ләчкә* – колын, *боға* – үгез, *қой* – сарык, *сазу ғорт* – кандала, *сипкә* – комбаш (пескарь), *қоча* – тәкә, *майған* – үрдәк, *турбақ* – бозау (ана булганы), *қышлақ* – кыш чыккан бозау, тана, *чағwан* – шөпшә һ.б.

**Үсемлек атамалары:** *қандық* – татлы тамырлы үсемлек, *эт борно* – гөлҗимеш, *тыт* – карагай, *қарағат* – карлыган, *қызыл қарағат* – кызыл карлыган, *ағач* – урман, *қалба* – кыргый юаның бер төре, *чучқа йапрағы* – әрекмән, *сарғай* – сарана, *чалқай* – кычыткан, *қызылча/қызылчы* – чөгендер, *мәркүп* – кишер, *киндераш* – киндер (үсемлеге), *әлән* – җитен, *көгөмәй* – кара җиләк, *көпөрөц* – кара кура җиләге, *сайғанақлы* – чәнечкеле, *йоморт* – шомырт, *қаштақ* – пешмәгән җиләк, *йамбас* – җир җиләге, *қыйтмыр* – гөлҗимеш: *Қыйтмыр йуwып саттыған итек* – Гөлҗимеш җыеп сата торган идек. һ.б.

### *Сөйләү үрнәкләре*

**Аш-су турында.** Пес йақта қыстыбый қамырын пич өстендә (каршында) быжыратқан. Уwыс қуйы, сап-сары, быжрыб ашайтқан, сап-сары, тәмнү. Сыйыр посаулаб алса қәйер бирәм перәр қарчыққа. Йырақ йулға болса, пер кисәк итмәк кисәген бала бер тешнәп алып, салып қуйасың, паланың эризығы өзелмәсен өйдән тип. Қайтқақ йомшартып эткә бирәсең қәйергә, балам сау сәләмәт қайтсын дип пер кизәк итмәкне алай тығып қуйасың.

Пашына чипчик зур түгел, ақ җылан башы тағып қуйалар ыйы баланықы. Бишеккә туwалық мендәр астына баланыңқы (салалар), айу тырнағы бола мендәр аста, балаға шайтан килмәсен дип.

Пиреженик ачыға қой, йарты (литр) соу, экке қуқой, сары май, мишкә май да әйбит, йомшақ итеп кенә қуйасың, күпкәч қағып (он өстәп яңартып) қабартасың, сәwәләп (әвәләп) тағы қабартасың, анаң эченә әз генә йиләк салып қаплайсың, өстө артыпрақ торсын, табаданға саласың майға, асты қызарғач, әләндермәйсен, майын өсөнә чәчеп-чәчеп кенә торасың.

Әнийемнеңке сеп отыс тәңкә, сондоқ, электә сеп салышқаннар, йастық, төшәнчек, чыбындық, сөлгө. Қызныңқы ратн’алары

сеп салышалар. Сепкә салалар қодағыйлар. Сондоққа төйәп күчертәләр қызнықы әйбирлирен, аны нүгәрләр алып чығып чанаға утыталар. Минеке адам (әтием) инәйне көүчереп алған. Нүгәрләр – йәш малайлар, арқан тотқаннар, керетмичә торалар қапқада. Мән табақ менән wак канфит тотып торам. Қозоқ (эрбет чикләвеге) қойалар иде киленнеке түбәсенә, бал менән май қаптыралар ийе, йәймә йәйәләр. Қайнәнисе, йахшымы килдегез, ди. Бусаға аша атлап керәсен. Бусаға аша әйбер алырға да йарамый, теләнче булдыңмы diләр, бийағына чығыб аласың. Қаршалг̱анда бал-май қаптыралар, йастыққа йә сөлгегә бастырғаннар, килен килеп баса йастыққа. Бала-барқа (бала-чага) талашып, йуллашып, үзенә тарталар. Эжек баwы сатып алады нүгәрләр. Каралwатқа күшәгә тартқаннар тыйықлап (томалап).

*Сөйләүче: Айнагулова Гайшә (1921 елгы). Тумаел*

**Тормыш-көнкүреш турында.** Өйәңкеләр йаңған күрерсез, шулар төбөндә қурчақлар булған. Әрберсенең қурчағы булған. Өй төбәсендә дә шүрлекләртә қурчақлар булған. Майчамал маманыңқы (әби) да полған. Мотыйғулла бабайларны уғытқан, тингә керткән. Қурчақлы кешеләр қалмады инте. Wәли бабай бик қуwатлы мулла булған, парсын да денгә күчереп петергән.

*Сөйләүче: Мәүлетов Робинзон Рәхмәтулла улы. Тумаел*

Пес кечечәк қалтық, Сибертә торған итек. Әтәбесне соғышқа алп кәттелер. Пес аилға көчтек. Инәм қорсақту қалта. Картопко отостоқ. Абамнар олулар эде, алар эштәделәр. Энэм тегүче иде, байбақ (тиредән тегелгән аяк киеме, унты) тегәткән ите, кечек аиллардан кэлэ тығаннар иде. Орос аиллары да бар, бестән йырақ имэс. Алар килә тоғаннар итек тектергәле, кийнөк, бэшмэт, чарық тектергәле. Чарықны пайбақ пэлэн кийэлэр. Кинөклөр йағалу, энечлү булған, астан ич тимэ тэ (һични дә) қоймойтолар. Ыштан озоннү кейгэндэр. Пицәт итәлә йоқ қой бестең тел (безнең тел белән китап басмыйлар бит). Элке қарағат (кара карлыган) йудық (җыйдык), сата тоғон итек. Wаринйа ажабый тығын (ашамый торган) итек, пестә көпөрөц (яр бөрлегәне) тә йуwалар, көгөмәй (кара җиләк), қыйтмыр (гөлҗимеш) йуwып

саттырған итек, астыған (кура җиләге), тырнакүс (мүк җиләге) пес йақта үспэй (үсми). Инәм сыйыр саwа тыған те, налук сала тығыннарте (торганнар иде). Кабыста чәчә тығын итек, қызылча (чөгендер), тыква. Йазын сыу йәйә, қапчықлап қыр суған йыйа тығамбыс. Киндерашны төйөп сала тырған ыйық тәрки (ачыга пешерелгән кабартма) быжырғанта (пешергәндә).

Йәш wахытны бишеккә китап (догалык, иске китап) йазып салалар шайтан алыштырмасын дип. Йылан башы кебек нимә була торған ите, ақ, тешләре дә көрөнөп торадыр ите, чипчигенә тегеп қойодоғон. Балаға күс тисә, әби өшкөрәдер ите. Кәҗә бәкәйебес пар иде, Сәрби мама өшкөрдө дә бетте. Белемчеләр булған (им-томчылар) элек, хәзер йоқ қой. Арпа чықса та тис бетә, бәләкәй генә. Терсәк була, ансы зур булып чыға. Арпакөрпө, мә қуқыш тип, тфу-тфу тип төкөрәбес.

Қорбанныққа үгез алып, суйып, быжырып, сорандылар йамқыр, азан әйттеләр. Зур қазанлар, шунда пыжыртылар, ажаттылар, сыу белән уйнап, берсен-берсе чәчрәп. Алланың эрәхмәте, йауды, кәзер бит йуқ менәкә. Өйдән табақлар, қажықлар китер (биредә: китереп). Пала-барқа (бала-чага) йаланайақ. Үгесне йығытып суйдылар, элек аwылыбыста бәрәкәт пар иде.

Йома көннө ағым су да туқтап торор ди, бер эш эшләргә йарамаған.

*Сөйләүче: Вәлиева Мәмдүхә Ахунҗан қызы (1918 елгы), Новосибирск өлкәсенең Колывань районы Акбалык авылы*

Чын қалмақтардыңқы сөзлөрөн оғоп, сөйлөп бирийем. Бәйлиген көчөк, қурқымаң. Сөйлөп пирәрек (бирәбез), қоноққо чақырдылар, таңда барарық (барабыз).

Йәйен тачок (уеннар) боло торғон, былафкы (йөзек салыш уены) уйный идек, тадарча кырук уйный идек, парлу кешене чакырасың, йырлыйлар:

Икегез бергә торасыз,
Буйларығыз бер икән;
Икегез дә пар килгәнсез,
Уйларығыз бер икән.

Вичеринка болодоғон, аулақ өй. Ашық уйный идек, соу бойон-нон таш йийып. Йәштәр йырларға та белпәйделәр. Йәштәр йоқ қәзер. бер табач (әз генә; бер уч) халық қалды монда қәзер. Мең баш мал иде, аты да бар, тайчағы (колын) да бар иде, йегеп өрәткәннәр (җигәргә өйрәткәннәр) ләчкәсен (тай). Боғаны җигеп, сыйыр тотоп баранит қылтым, тешле баранасы бар, тот та йөргез суқа белән.

Қарт әбиләр ақчалар таққаннар, доғалық болғон. Доғалықны уқымышлы халық йазып бирә. Күз тигәнен белсәләр, аның доғасы да бар, шул кешедән аwызынан соу чайқатырыб алған-нар, баланыңқы айақ-кулын йүwешләгәннәр, башында чипчик зур түгел, ақ жылан башы тағып қуйалар ыйы, бишеккә доғалык, мендәр астына баланықы айу тырнағы, балаға шайтан килмәсен дип. Йә қызыл чебрүк тағып қуйа баласыныңқы муйнына.

Урманның, соуныңқы ийәсе бар бит, қыш wахытны қычу (кечкенә) чанақ белә китеп қала иде ағачқа (урманга), көм буй-ына йағып тора торған идек. Минеке абам (апам) суға барған, су чумарға кергән wахытта, озон чачы, утыра ди, тарағы алтын, тараб утыра ди, суға төшөп киткән, абам қороқоп қайтқан. Су ийәсе тарта, мин қурқыймын. Тынычсыз ызбалар да бар ул. Бусаға аша әйбер алырға да йарамый, теләнче болдоңпу диләр, бийағына чығыб аласың.

Әнийем атасыз-әнәсез үсеп. Әнийемнеңке периданы бу сон-доқ. Электә сеп салышқаннар (бүләк бирешкәннәр), ратн'а-лары сеп салышалар. Сепкә салған диләр ике йақлап, берсе берсенә салалар, сеп салышу хәзер йаңадан чықты. Йастық, түшәк, чаршау, сөлгеләр биреп, сондоққа төйәп күчертәләр, аны нүгәрләр алып чығып чанаға утырталар. Нүгәрләр – йегет-нең иптәшләре, нүгәрләр йегетне қыз йанына озаталар, қыз күчергәндә сақчы шилле (шикелле) озаталар қәwеп-қәтәр булма-сын дип. Қаршалғанда бал-май қаптыралар, йастыққа йә сөлгегә бастырғаннар. Килен килеп баса йастыққа. Сөлгене бала-барқа (бала-чага) талашып-йуллашып үзенә тарталар. Ишек баwы са-тып алуларны да чала (аз, чак кына) беләм. Бессең мамау (әби) ника оуқытты, ника дип қойотқамбыс (куябыз, дибез).

*Сөйләүче: Басымова Шәфика Корбан кызы. Тумаел*

**Тормыш-көнкүреш, туганлык атамалары һ.б.** Мәнеңке адам-инэм оуқығаннар. Абыстай (1) әд.; 2) апа) өйләрен йийыштырды, эштеды. Инэм оуқытпады. Абыстамнынқы озур ызба (өй), анықы қызы Алабуғада торады, бесгэ килэт (килә). Без аларны чақыртадық қырық көн булады да. Тырыждық, саңзалар (торпыча) йазадық. Бырады (абый) аныңқы монда торады. Мәнең Алабуғада болғаным йоқ. Песнең тәтәү (биредә: бабай) ол йақтан полпто, тәтәү (әти) аwылдыңқы, бабаулар, мамау да өлөп пөткәннәр. Абый – олу, брат – кечү. Нәчек әйтешкәннәрдер, мән пелмәйем. Мэн сийләжәм тадарча. Паллар көпрөк (күбрәк) эде, артсалма (сырган жилет), кәбәч (түбәтәй) кейгесәделәр. Ороччо (киле сап) пөснөкө, кийөнтөлү (көянтәле) өлчәү былы. Безтә өүзе бэйлэгэн мэлэйне (бияләйне). Кийнөктөр (күлмәкләр) текteләр йәжел. Адазы безденке айылдан, безнен тороснан китап та йаздылар. Адазы (атасы) тоқсон эке, тоқсон өч йәштә, молло болдо айылда. Слэр тағы мамайлардан соражып пағың. Ғәйшә мамау дийәдек без. Барқайақ саз йанында, көп сөйлөр иде. Көкөм (үзеннән кечерәкләргә эндәшү сүзе), оуғыганны йарадам.

Бездеке тормош нейчекмә? Тартмағач (каба) былы үwерәбез (эрләү), мэлэйне (бияләй) бэйлэгэн, көрөк (кирәк) нимәне эштедык, қол'қо (кисәү агачы), монда йыwынатқан қомғон, монда табадан (таба). Қарт бабайлардан да сорарсызлар. Чарада (ит тагарагы) қош (ит) чапқан, чапқычы бар, чөгөн (чуен) былы пыжыратық қошно, кәртүкне. Сумза (ит сумсасы) пыжырадық мал сойғач. Пиреженик чөчөдән ол, қуқай, йомжақ қамыры. Минем инәм дә пежерә, эштэде-эштэде, йетмеш бэшкэ йетте. Қамырды сәwәләп-сәwәләп(әвәләү) йайып (җәю), эженә йиләк салып пыжырасың майда, айландырмайсың, майны сэбеп-сэбеп кенә торалар. Чәчәктин болады, читләре қытырмақ полады. Ачығанға өрөжөп (кабарып) чығады, йурағанға (төче камыр) өрөшмәй. Мэн соуғанны йарадам. Ойлы (Олейна – май сорты) әйбәт самсаға. Ләчинкәле (начинкалы) туғач (кабартма) та пыжырабыслар. Пәлеч ул көштөңке, балықнықы – пирок.

Эрем (ирем) соуғышқа барбады, зәғыйп полпто. Аурыб алдым менәкә қату. Алты баланы өүзөм өскәрдөм. Олу қызым ире

йуқ (ирсез) қалды, чәчләре қамыштий. Сэнең дә алтаумы? Сэн пер бала тыуғансын, чачың аппақ. Ана, Көлчийаның кэлеб утыра, қалач әкилеб утыра, кебиттэ болғондор.

Сыйырлар йаңы тоуды (бозаулады), берсе боға (үгез) тоуды, берсе теше (тана (бозау) тоуды. Қойлары (сарык) көп, бәрәннәгәне дә бар, тыубағаны (бәрәнләмәгән) да бар.

Әтей, әнәй өләп кэйткэн, анда чатырық (чардуган) көргөнсес, мэйне қартәтәй (бабай) өскөргәннәр. Қышқылыққа суwақ (суык) бестә. Анта икенче әби-бабайға барып тороңар (торыгыз), ти қартәнәү, бы йаққа барасыңармы ти. Беркемдә дә чай эчмәгәндерес? Бестеңке айыл (авыл) озор.

Аш (токмач), шорбоға салған қамырны аш дибез, озон аш (токмач), шақмағ аш. Дөмәләгән (парга пешкән) көрөчне (дөге) йарадам, майда дөмәләп кенә, парлап қына алып май салып, йемеш салып бәйрәмнәрдә пежерәбез, ул қәдерле аш. Бәлечләр, шурба, пылау, соңғарақ чай бирәбез, қатемнәрдә андый.

Уwыз қуйы, сап-сары, пежереб ашайдылар. Сыйыр посаулаб алса, хәйер бирәм берәр қарчыққа.

Ачы (карале), Сәрийә минән бәләкәйе. Адам (атам) йәшләй өлдө, суwағ алдырған, әнийемнеңке әнийе – мамау көптән өлгән, Пайдулла әкәм (абыем) қатыны йиңә була, ул қатын Көлчийан абам (апам) белә ике туған балалары. Мамамныңқы ике систырасы үлде. Соуғыш йылларда аwырчылық булды. Йәйен қыр үләне белән тамақландық, балтырған, сарғай (сарана), қандық (юаның бер төре), күбергән (юа). Сай күбергәне, таш күбергәне (кыргый суган), чалқай (кычыткан), алабода (алабута).

*Сөйләүчеләр: Басимова Шәфика Корбан кызы, Садыйкова Бәнат Мингали кызы, Айнагулова Гайшә (1921 елгы).Тумаел*

**Авыл тарихы, йолалар һ.б.** Айылдыңқы (авыл) тарихны силәргә кем бар? Мийең әтийем – адам (әтием) энде – айылдыңқы, минеңке инәм дә қалмақ. Алар Җиләдә, Тум арйақта булғаннар. Соу басқачын, тайғалық (урманлык) тип бу йаққа чыққаннар. Айыл зор болпто. Бер табач (уч) қалық қалды монда қәзер. Мең баш мал, анда анчы уқ, ике зор пастук, бер күс

(бөртек) қалмады қәзер. Ашлық чәчкәннәр, балық балықлағаннар: чуртан, чабақ, кәрәс, қарабалық, сипкә (пескарь), нәлим. Мырмашовка әйтәделәр, аны белән балық тоталар. Қышын қойо тишэделәр. Кәрчәшкә, марда диләр талдан үреп, алый да тотқаннар (балықны). Сләргә чәй қойоб алыйқ? Йылқы ите, йылқы майы дигәннәр, элек андый булған, бийә, айғыр, тай (колын). Бозау қандый була, тай да андый. Қазы тығасын, анан йәйгедә ашайсын, өй башында қоротадылар.

Соуны көлдөн, тоз ташыйлар соу буйыннан, йомасына (атна) бер ләтпә, икемә барады. Монда тайга булған. Көлөч (кое) қазып, көлөчтән алатқан идек тәмне соу.

Қышқыта пима (киез итек) басадылар, өүтекне (итек) дә үсләре тегэделәр. Чабата болған, бес кибәдек, қаадыр анықы ағачы булады.

Суwақ (суык) бестеңке йақ, Сибирийә, аның өчөн йуртыларда торғаннар. Бөк (тугай, болын) полпты кәң, Қарасу дигән пыротока болпты. Мәнәкә соу чоумарға керәсен, бы йақта қара соу, Курйа инде ул.

Тупсада (киле) исесең (тою) бәдер (төче күмәч) булады суқма (киле сабы) белән, қул тигермәнендә йарадылар, идергәннән (суктыру) қалған башақны суқтырып ала да.

Бер кисәк итпәк кисәген бала бер тешнәп алып салып қуйасың, баланыңқы эризығы өзөлмәсен өйдән. Қайтқач йомшартып эткә бирәсең хәйергә, балам сау сәләмәт қайтсын дип тешнәтеп каласын да.

*Сөйләүчеләр: Абзалимов Фәрит, Абзалимова Минзифа, Тартыкова Вәсимә, Садыйков Сөнгат Мөҗәй улы. Тумаел*

**Үсемлекләр турында.** Мэн эчпэгэч белмәймен әремне. Әрәхмән йафрағын йабам, бездә кән (күп) ол. Киндераш, дары (тары) бырын чәчәләр иде. Сазу үләнне (әрем) дә эчэләр. Менэкэ мэн чирләп киткәч кэлде инде абам (апам), укул сайа (казау) өүз-өүзөнө.

Ашлық чэчкэндәр, бодай, арыш, соло, арпа. Песнеңкеләр чәчпәделәр микән.

Айылда берәү дә эшлэгесе килбәй. Мән бер ғырада (түтәл) пыйас (суган), бер ғырада кәбестә оутызамын (утыртам). Қәзер

әйтәйен: тайгада (урман) қарағай (нарат), қайын, шишка ағачы (эрбет, кедр), қосоқ (эрбет), миләш, этборно (гөлҗимеш), шоморт, қарағат (карлыган), қызыл қарағат өүсәде. Тыт, сазүлән (әрем), ағачта (урман) төмөн-төрлө (мең төрле) өүсәде. Ачу қымыз ақ чәчәклү, ашлық арада үсәде. Чучқа йапрағыныңқы (әрекмән) қырмаwығы (тигәнәк) йәбешеп қала торған. Сарғайныңқы (сарана) төбө суған фурмасына, қат-қат. Ашлығ алғын, бөгөн әкилдем. Ақча бэрбэйте эшләгэнгэ, ашлығ әкиләте, мөн дө өч йөз тородо.

Без йақта бернәстә дә йуғ ыйде. Туқмақбашлар үсәде, алабода, чалқай (кычыткан) бар. Бәрәңге, гырадада үсәде мәркүп, қызылчы (чөгендер), пыйас (суган), қабақ утыртарға йарадам.

*Сөйләүчеләр: Әминова Миңнехәят, Садыйкова Рәйхәнә Фәхри кызы, Садыйков Барый Корбангали улы. Тумаел*

**Кием-салым турында.** Көнәк (күлмәк) ыскыладлап, төймәле, кашниклы (беләзек). Қайсы қуштанлы (бала итәкле) тегелгән, бэленнән бөрмә йасап, кәң қысқа йәң. Партықлар (алъяпкыч) пойаслу (билле), күкрәге белән бергә озон партык, қайсы йарты ғына.

Көнақныңқы (күлмәк) қайчан йақасы булады. Ситса йаулық байлап йөриделәр, кашамир йаулықлар полпто. Қошқо көндө йаулықтан, шәл, мамық шәл, зур шәлләр (кышын юл йөргәндә ябына торган шәл) йабынып йөриделәр. Байларда ақ йебәк шәл болпты, оссон чачәкле (чуклы). Әбиләр түгәрәкне кийеп қуйа бүрек, өстөтән йаулық, ақ булып. Қартлар қысқа қунычлы галуш пима (киез ката) кейәте. Боронқы атулар (киез ката) болпты, йомышақ қунычлу, қайсы уйықлы (каюлы), қазан йақлар читеге. Күбесе кейтәнне (киндер (тукыма) кейгән көнәген (күлмәк) дә, ирләр чалбарын да. Кейтәнне эләннәң (җитен) эшләгәннәр, киндераштан да.

Элек зур алтын сырға (алка), дутый дип қуйа тоғаннар иде. Ақчалар таққаннар қарт әбиләр. Чачны ишәделәр толомға, чачқа үргәнне тәңкә дигәннәр ийе, йөзөк, беләзекләр қатқаннар, қәзер дә андый уқ. Доғалықны уғымышлы қалық йазып бирә. Элгәре артсалма (жилет) эченә мамық салып тегеп қуйа торғаннар ите.

*Сөйләүчеләр: Рафикова Майсифә, Сайбаталова Наилә, Садыйкова Гөлҗиһан. Тумаел*

# ТОМ ДИАЛЕКТЫНДА ХАЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕ ҺӘМ ФОЛЬКЛОР
**(этнолингвистик аспект)**

*Флера Баязитова*

Россия Федерациясенең Азия өлешендә, Көнбатыш Себернең көньяк-көнчыгышындагы Том һәм Кемерово өлкәләрендә яши торган татарларның сөйләше том диалектына карый.

Том диалекты өч сөйләшкә бүленә:

1. Әүштә сөйләше
2. Чат сөйләше
3. Калмак сөйләше.

Том диалектын күп галимнәр өйрәнгәннәр. А.И. Дульзон, А.М. Абдрахманов, Д.Г. Тумашева хезмәтләрендә беренчеләрдән булып том диалекты этнолингвистик яктан тикшерелгән. Соңгы берничә дистә ел дәвамында диалектологлар Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдиновалар да бу төбәкләрдә экспедицияләрдә булып күп материаллар тупладылар һәм аларны фәнни әйләнешкә керттеләр[1].

Том диалекты сөйләшләренең формалашуында өч этник төркем катнашканлыгы күрсәтелә:

---

[1] *Рамазанова Д.Б.* Том диалекты // Татар халык сөйләшләре: Ике китапта. Икенче китап / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б. Казан: Мәгариф. 2008. 463 б.; *Баязитова Ф.С.* Себер ареалы татар диалектларында этнокультура лексикасы (йола һәм мифология текстлары яссылыгында). Казан, 2010, 736 б.

«Из проживающих сейчас по нижнему течению Томи тюркоязычных групп **эуштинцы,** сохранившиеся теперь только в деревне Эушта были отмечены в 1526 г. С. Герберштейном. Об их прежних местах жительства нет точных данных.

**Чаты,** проживающие в ряде деревень вблизи г. Томска, в начале XVII в. кочевали еще на р. Чик – левом притоке Оми.

**Калмаки,** живущие вблизи г. Юрга, являются потомками телеутов, которые осели по р. Томи в начале второй половины XVIII в.»[1].

Том өлкәсе Том районында әүштә-чат сөйләше таралган авыллар түбәндәгеләр: Әүштә (Эушта), Абытай (Черная Речка), Калтай (Калтай), Умавыл (Барабинка), Кызылкаш (Тахтамышево).

Кемерово өлкәсе Юрга районында калмак сөйләше таралган авыллар: Кышлау (Зимник), Тумаел (Юрта Константиновка), Искедим (Большой Улус).

Биредә төрки халыклар әле VI гасырда ук Алтай ягынә нан үтеп кергәннәр, IX–XII гасырларда Обь елгасының югары өлешләреннән кимак-кыпчак кабиләләре, XII гасырда Енисей кыргызлары, XIII гасырда монгол яулары вакытында төркиләр үтеп керә. XVI–XVII гасырларда инде Көнбатыш Себернең җирле төрки халкы формалаша, алар арасында күпмедер дәрәҗәдә угорлар, самоедлар, селькуплар да катнашып, үз булып, тел һәм көнкүрештә берникадәр эз калдыра.

Том елгасы ярының кыя ташлары өстендә борынгы кешеләрдән истәлек булып калган рәсем-язулар турында галимнәр тикшеренүләр уздырып торалар, үз фикерләрен белдерәләр. Алар фәндә «томская писанина», «тутальская писанина», «никольская писанина» исемнәре белән билгеле. Бу рәсем-петроглифларда кыя ташларына уеп атлар, пошилар, уклы-җәяле

---

[1] *Дульзон А.П.* Диалекты татар-аборигенов Томи // Ученые записки Томского пединститута. Т. XV. Томск, 1956. С. 120; *Дульзон А.П.* Этнолингвистическая дифференциация тюрков Сибири // Структура и история тюркских языков. М.: Наука, 1971. С. 198–208.

аучылар сурәтләнгән. Шундый серле рәсемнәр Том елгасының ике як яры буйлап сузылган текә кыяларда табылып тора икән. Күрәсең, борынгы заманнарда ул урыннар һәм Том елгасы үзе дә ниндидер бик серле ритуаллар белән тыгыз бәйләнгән як булган. Аларны археологик планда да өйрәнеп тору зарур. Әлеге рәсем-язулар кыяның көньякка, кояшка каршы урынында, кешеләргә үтеп керү мөмкинлеге булмаган яшеренрәк урыннарда сакланганнар. Ул табылдыклар шушы җирдә яшәгән борынгы халыкларның йола үтәү, кояшны, табигатьне олылау, урман җәнлекләренең үрчемен теләү, урман хуҗаларына табыну һ.б.ны чагылдыра торган истәлекләр булу ягыннан кызыклы.

XVII гасырда Том шәһәре төзелә башлый. Кемерово өлкәсенең Юрга шәһәре тирәсенә руслар һәм җирле төркиләр килеп утыра. Кемерово өлкәсендәге себер татарлары сөйләше фәндә том диалектының калмак сөйләше буларак билгеле[1].

Кемерово өлкәсен еш кына Кузбасс дип атап йөртәләр, чөнки биредә Россиядәге иң зур ташкүмер бассейны ята.

Кемерово өлкәсе Көнбатыш Себер тигезлегенең таулар белән очрашкан урынына туры килә. Өлкәнең күпчелек өлешен Алатау, Салаир тау сыртлары, таулы Шория алып тора, таулардан күп кенә зур һәм кечкенә елгалар агып чыга. Су артерияләренең иң зурлары: Том, Кия, Яя, Иля.

Кемерово өлкәсендә себердәгечә континенталь климат, ягъни биредә озын һәм тирән карлы кыш, эссе һәм кыска җәй. Тауларның һәм тигезлекләрнең күп өлеше урман белән капланган.

Өлкәнең тарихы гаять кызыклы. Моннан 30 мең еллар элек биредә аучы кабиләләре яшәгән. Бу турыда курганнарның археологик казылмалары, борынгы кешеләрнең яшәү урыннары һәм кыя ташларына уеп ясалган борынгы рәсемнәр күрсәтеп тора.

Кемерово өлкәсе Себернең кешеләр иң тыгыз урнашкан төбәгеннән исәпләнә. Төп халкы шәһәр һәм бистәләрдә яши. Шахталарда һәм рудникларда шахтерлар күмер һәм руда чыгара.

[1] *Тумашева Д.Г.* Диалекты сибирских татар. Казань, 1977. С. 237–238.

Биредә яшәүче җирле төрки халык элек-электән рудадан тимер ясауның серләрен белгән. Шуның өчен аларны борынгы рус язмаларында тимерчеләр (кузнецы) дип, яки «кузнецкие татары» дип атаганнар.

XVI гасырдан бу җирләргә руслар күчеп утыра башлаган. Халык бер-берсе белән аралашкан, тәҗрибә уртаклашкан, көнкүреш үзенчәлекләренә төшенгән.

Авылларда яшәүче халык бирегә төрле сәбәпләр аркасында килеп урнашкан. Соңгырак чорларда килеп төпләнгән авылларда шулай ук татар теленең урта һәм мишәр диалектына караган сөйләшләре дә сакланган.

Өлкән буын кешеләренең сөйләвенчә, бу якларга Столыпин реформасы чорында, ягъни 1906–1907 елларда, иркен буш җирләр эзләп килеп утыручылар булган. Мәсәлән, Юрга районы Сарсаз авылы шундыйлардан. Шулай ук, репрессияләнеп яки кулак итеп сөрелгән, күп җәфалар чиккән халыклардан оешкан авыллар да бар. Мәсәлән, Анжир районы Теплая Речка – Җылы Елга авылы. Әлеге авылның халкын «спецпереселенецлар» дип тә атап йөрткәннәр. Бу авылның сөйләше урта диалектның минзәлә сөйләшенә якын. Биредә шулай ук сугыш елларында Идел буеннан сөрелгән немецлар да күп. Алар аеруча татар авылларында урнашып калырга тырышканнар. Хәзер алар барысы да татарча сөйләшә. Альма исемле әби хәтта татарча имтомнарны да яхшы белгән. Авыл халкы аны олылап «үзебезнең духтыр» дип йөрткән. Шуннан ерак түгел генә урнашкан икенче авылны «Яңа авыл» (русча Нижегородка) дип атыйлар. Бу авылның сөйләше исә мишәр диалектының Пенза өлкәсендә таралган сөйләшенә якын, бик матур сакланган татар сөйләше булып тора.

Экспедиция вакытында безгә калмак сөйләшенә караган, борынгы җирле үзенчәлекләр нык сакланган Кышлау, Искедим, Тумаел авылларында материаллар туплау насыйп булды.

Кышлау (Зимник) авылы Юрга районындагы бик борынгы авыллардан санала. Аның барлыкка килүенең төгәл генә датасы билгеле түгел. Тарихчылар һәм этнографлар (мәсәлән, Кемерово

университеты галиме В.М. Кимеев) фикеренчә, бу авыл XVII гасырда оешкан булырга мөмкин. Ләкин археологлар, һәртөрле торак калдыкларын өйрәнеп, аларның тагын да борынгырак чорлардан калган булуы турында язалар.

1995 елда Кышлау авылында Кемерово университеты галимнәре археологик казылмалар ясап, фәнни тикшеренү эшләре алып барганнар. Авыл янындагы Искедим елгасы буенда, аның сул кушылдыгы Кожановка янында бик борынгы курган-каберлек табылган. Ул каберлектән каен тузына салып күмелгән кеше калдыклары чыккан. Аның аяк очына аю табаны үрнәкләре төшереп ясалган балчык савытлар да куелган булган. Шундый ук «серле» курганнарның Кышлау (Зимник) авылының тирәягында берничә урында булуы билгеле.

Югарыда искә алынган Кышлау, Искедим, Шалай, Тумаел (< Тум + аел; *аел* сүзе биредә авыл мәгънәсендә кулланыла) авылларындагы җирле халыкны калмаклар дип атап йөртәләр. Шалай һәм Искедим авылларындагы җирле халыкның бер өлеше, христиан динен кабул итеп, урыслаша, ә бер өлеше исә керәшен булып кала.

Калмаклар, Кемерово өлкәсендә яшәүче төрки халык – телеутлар белән бер тамырдан булып, хайван асраучылык һәм аучылык белән шөгыльләнгәннәр һәм күченеп йөргәннәр. Соңыннан шушы тирәләрдә төпләнеп, утрак тормышка ияләнгән өчен булса кирәк, аларны ак калмаклар яки калмаклар дип йөртә башлаганнар (калмак – «калу» сүзеннән). 1734 елда Себерне өйрәнүче галим Г.Ф. Миллер: «Том елгасының көнчыгыш ярында Константиново (Тумаел) авылында татар-телеутлар яши», – дип язып калдырган[1].

Кышлау авылын биредәге җирле төркиләрнең кышкы торак урыны булган дип саныйлар. XIX гасырда Кышлау авылына Идел буе татарлары һәм Урта Азия төркиләре килеп утыра. Җирле калмаклар һәм аларның сөйләше ассимиляцияләнә, татар

---

[1] *Миллер Г.Ф.* История Сибири. Т. I, 1937; Т. II, 1941.

сөйләшләре белән якыная. Биредәге халык ислам динен, гарәп графикасын, татарның рухи һәм матди мәдәниятен кабул итә.

Кышлау авылында ярты авыл – калмак, ярты авыл – мишәр. Калмак очы, мишәр очы, дип әйтәләр.

Лингвистик яктан калмак теле биредә яшәүче Том өлкәсе татарларының том диалекты калмак сөйләше дип таныла. 1930–1950 елларда биредәге мәктәпләрдә татарча укыганнар. Татар мәктәпләре ябылу сәбәпле хәзерге авыллар урыслашып бара. Яшьләр рус телендә генә сөйләшәләр. 1990 еллардан авылларда татар теле факультатив дәрес буларак кына укытыла башлаган.

Калмак сөйләше бигрәк тә фонетик яктан кызыклы һәм үзенчәлекле. Биредә алтай теле йогынтысында иренләшү гармониясе көчле: *болодогон* – була торган, *сөзмөкөр* – сүзмәкәр, сүзчән; *өзүм* – үзем, *көстүгүм* – күзлегем, *мончо* – мунча, *үкмөк* – икмәк һ.б. Морфологик үзенчәлекләрдән берничәсен күрсәтеп китәбез: I һәм II зат күплек сандагы киләчәк заман формалары: *без аларык* – без алырбыз, *сез барсаңар* – сез барсагыз; хәзерге заманда: *нәк мәа кыйгыртырсын* – ник миңа кычкырасың; кабатлаулы үткән заман: *сөйләшеп утырткан идек* – сөйләшеп утыра идек һ.б.

Том һәм Кемерово өлкәләрендәге җирле себер сөйләшенә казан татарлары сөйләшенең йогынтысы зур булган. Моны алар элегрәк мәктәпләрдә татарча уку һәм бер үк авылда берләшеп, аралашып яшәү нәтиҗәсе дип аңлаталар.

Лексикада җирле сөйләш өчен хас булган сүзләрдән берничәсен күрсәтеп китәргә мөмкин: *инау* – әни, *адау* – әти, *әкәү* – абый, *абау* – ана, *мамау* – әби, *бабау* – бабай, *күкәм* – үзеңнән кече туганыңа эндәшү, *бога* – үгез, *майган* – үрдәк, *пияз* – суган, *кызылча* – чөгендер, *мәркүп* – кишер, *тогом* – йомырка, *түбө* – түшәм, *сирәңкә* – шырпы, *күш* – ит, *сонма* – киле, *тырып* – торма, *сырга* – алка, *чалқай* – кычыткан, *карағат* – карлыган, *мишкә* – гөмбә, *дүләнә* – камыр җиләге, *гөреч* — дөге, *қозоқ* – кедр чикләвеге, *самза* — урама, *сөртмәч* – юка, күзикмәк, *төштөк* – түшәк, *әйкүл* – хәситә, *сак* – пальто, *артсалма* – җиңсез камзул, *кәбәч* – түбәтәй, *тағайа* – бүрек, *мөйеш* – почмак һ.б.

## ГАИЛӘ-КӨНКҮРЕШ ЙОЛАЛАРЫ ЛЕКСИКАСЫ
(ТЕКСТЛАР)

### Туйлар

### *Саучы*

**Саучы** – яучы; кыз димләргә килгән кеше.

– Ата-инәсе малайныкы өйләндергесе килә, өйләнергә wахыт йиткән. «Саучылаґалы кирәк, өйләндергәле кирәк», – тиләр. Барайлар бу йақтан ата-инәсе, туґаны. Саучылап баралар. Қызґа барып кергәч хәбәр бирәләр.

«Менә, қода-қодаґый килә сиңа саучылап».

«Өрөхсәтме, кергәле буламы?» «Була, була».

Қаршылайлар, өстәлгә тастырхан (ашъяулык) йәйеп йибәрәләр, доґа қылайлар. Өстәл йанына утырып чәй эчеп алайлар, сөйләшәйләр.

«Без бик зур йомыш белән килдек. Менә синең қызың бар, минем малайым бар. Синең қызыңны саучылап килдек. Йақшы йер, йақшы кешенең баласы».

Малай қызны белми, қыз малайны белми әле. Бер генә килмәй инде, өч қатар баралар саучыґа. Өченче қатта инде ыризалық бирәләр. Элек ай башы белән баралар ыйы бит. Айның унбишенә, йә йегермесенә, ыризалашалар инде. Туйлары була иде *(Кызылкаш)*.

**Саучы** бер ыштан балагын чыгарып килә:

– Бер балаґын чыґарып киләдегән саучылар.

«Хуш килдеңез, әйдә, үтеңез».

– Бик элеке заманда саучы булып килгән кеше бер балагын төшереп қуйа икән, бер ыштан балаґын күтәреп қуйа икән. Исәнләшеп, сәләм биреп, қадер-хөрмәт қылып килешеп қуйґаннар.

– Инәмә уналты йәш булґан. Саучы килгән бер ыштан балаґын чыґарып. Дүрт қызлары булґан икән.

«Қайсы қызыбызґа килгәннәр икән», – дигәннәр. Бу уртанчы қызны сорарґа килгән. Өрөхсәт белән кергәннәр, сәламләшкәннәр.

«Без Тум суwы аша килдек. Мәймүнә дигән қызыңна йаучыы лап килдек».

«Хуш килдегез».

«Мәһәрен ни сорасағыз да бирәбез, туйны салышыйық», – дигәннәр *(Умавыл).*

«Бәрәкәтле тормыш булсын, маллы булсын», – дигәннәр.

**Саучы** килгәч, һәр ике якның нәсел-нәсәбен тикшерәләр, сорашалар:

– «Қызға саучы килде», қардәш-туғаннары килде», – диләр ийе. Йақын туғаннары килгәннәр қыз сорашып. Бу үзе йақтан йиған қардәш-туғаннарын. Бик қаты тикшергәннәр. Нинди кешеләр алар. Бөтен нәселен, туғаннарын йийганнар. Ул нинди кеше, нинди бәндәләр, нәселе нинди, бик қаты сорашқаннар. Нәселендә бер бозық күңелле кеше булса, қызны бирмәгәннәр. Бик қаты тикшерү була иде қызны биргәндә *(Әүштә).*

– Бер килүдә ыриза булмаганнар әле, сырук (< рус. срок) қуйганнар қызның әтиләре. Тирә-яктан, қардәш-туғаннардан сүз иштырып йөриләр, тотып қына қызны биреп йибәрмиләр.

Киңәшеп, килешеп сөйләшеп, ыриза булып килешеп туйлар йасап қызны биргәннәр *(Әүштә).*

## ***Сорату***

**Сорату** – кызны яучылау.

– Қызны соратып қуйғаннар икән, бөтен сипне (бирнәне) қыз әзерләп утыра *(Әүштә).*

## ***Қачып бару***

**Қачып бару** – ата-ана белән сөйләшмичә, аларның ризалыгыннан башка гына кияүгә китү.

– Қызлар қачып та бардылар. Мин дә қачып бардым. Қыз өйендә бийедем бер малай белән. Ул миңә күз қыса. Икенче көнне хат килә. Хат өстенә хат килә.

«Қачам инде», – дийәм. Инәм өйдә йуқ. Күршеләргә керәм, «утырғалы», – дийәм.

Чығып киттем. Зур йақшы ат бәйләүдә тора. Атқа утырып кийәү өйенә киттем. Ул мине күтәреп кертте синәк (< рус. сени) ишек алдына. Арттан быратлар килә мылтықлар белән. Мине йәшеренделәр, күрсәтмиләр.

«Үзең килдеңме, әллә көчләп алып киттеләрме?» «Йуқ, йуқ, үзем килдем», – дийәм *(Кызылкаш)*.

## ***Қыз өйе***

Кийәүгә китә торган кызның өендә, кияү килгәнче, авылның барлык кызларын чакырып, күңел ачу мәҗлесе оештыралар. Ул шулай «қыз өйе» дип атала. Кыз өендә егетләр чәчәкләр тотып килгәннәр. Кызлар исә аларга бүләкләр әзерләп торалар. Кыз өендә уен-көлке, җыр яңгырап тора.

– Туй алдында йасайлар қыз өйе. Қызлар қара-қаршы йырлашалар, бийешәләр. Ирләр, йегетләр бичуркага (кич утырырга) керәләр. Қызны қалфақ кийертеп, шәл бөркәп утырталар. Қара-қаршы бийиләр қызлар-йегетләр. Гармушка була.

– Қыз өйендә қызларны төшереп бийетәйләр. Қыз кийенеп басып торай. Қызлар күп булай. Нүгәрләр тип малайларны кертәйләр.

– Қыз өйендә уйын була, бийү. Кийәү йақтан килә йегетләр, нүгәрләр. Анда қызны йәшереп қуйайлар, күрсәтмиләр. Қыз – кийәүне күрмәде, кийәү – қызны күрмәде. Қыз өйенә малайлар да килә, күкерәгенә чәчәкләр кадап. Чәй эчәләр. Малайлар чәчәкне кызларның күкерәгенә қадыйлар. Қызлар бүләк бирергә тийеш ул малайларға.

– Қызлар бийегәле төшәбез түрдән.

– Йәшләрне, қызларны чақыралар қыз өйенә. Кем чақырган, шунда барғаннар. Анда малайлар бүләк биргәннәр қызга.

Қыз өйендә йырлашабыз:

Йөзегезгә, йөзегезгә
Йөз карадым, туймадым.
Сезне нурдан йаратылган
Микән дийеп уйладым.

Сандугач қунган имәнгә,
Имән башын игәнгә.
Йырламыйм, йырла дигәнгә,
Йырлыйм, сине сөйгәнгә.

Гөл арасында йөрисең,
Гөлләргә үреләсең.
Ачық йөзләрегез нурлы,
Күркәмле күренәсез.

Сандугачлар килер әле,
Килер дә китәр әле.
Сақ белән Соқтан да үткән,
Бездән дә үтәр әле.

Алмағачның ботағына
Баулар бәйләсәк иде.
Йинаулашып, бергәләшеп
Җәйләр җәйләсәк иде *(Әүштә).*

### *Чақырту*

**Чақырту, чақыртуға йөртү** – ярәшелгән кызны мәҗлескә йөртү.

– Қыз бер йыл утыра. Чақырту дип туғаннары чақыртуға йөретәләр туйға *(Кызылкаш).*

### *Никә, неге*

**Никә** – никах.

– Никәгә барғанда йегет күмәче дип, икмәк алып барғаннар. Йегет күмәченә тоз утыртасың, әйбәтләп тастарханга бәйләп алып барасың *(Әүштә).*

**Неге ашы** – никах ашы.

– Неге ашларын қалтаға салып алып барғаннар *(Умавыл).*

### *Туй хатым*

**Туй хатым** – туй көннәрендә уздырыла торган дини мәҗлес.

– Никәдән суң туй хатым. Әрwахларны искә алып қоръән уқытатлар. Туй хатымға әркем ошлап килә салым. Қыс йақ та, кейәү йақ та туй хатымға килә. Буш қул бармыйсың. Акча, ит, қаз, қаймақ, туғац (төче күмәч) пешереп бардым *(Кызылкаш).*

### *Қыз йылату*

**Қыз йылату** – кызны кияү йортына озатканда моңлы көй белән җырлау.

– Қызны күчереп акиткәндә қыз утырып йылый башлый. Қызлар йырлый:

Әткәйемнең мунчасы
Тау башында булсачы.
Әткәм-әнкәм қулларында
Тагын бер-ике йыл торсамчы.

Пайкәл йылға балықлы,
Йанкәй мамық йаулықлы.
Пайкәл сулары қомлырақ,
Песнең башлар моңлырақ.

Ал пилбауларың атлас,
Сыуларға салсаң да батмас.
Қулығыздан киткән қыслар
Сағынсағыз да қайтмас.

Қыс палақайның йатқан урны
Қасанқынай йақта пер тақта.
Шул тақталарны қысғанып
Сатып йебәрәләр пер йатқа.

Тотонышалар қыслар йыларға. Шундый йырлар йырлап алып киттеләр *(Кызылкаш)*.

### *Аталық, инәлек, үкел ата*

**Аталық, инәлек, үкел ата** – туйда кияү белән кәләшкә икенче ата, икенче ана итеп билгеләп куелган кешеләр.

– Аталық, инәлек қуйайлар, ыризалық сорыйлар қыздан.

– Аталық бер олу кеше инде. Кийәү йағыннан була аталық. Аталық дигән кешесе қараwыллый кийәүне.

– Малай йақтан абыйсы бар – ул аталық була тоған. Үкел ата дигәннәр.

– Аталық мына хәрендәше. Аталық утызайлар, қыз өчен ул җаwап бирәй:

– Берәр йақын кешесен аталық итәләр. Әкәм дип йөриләр аталықны.

«Бардыңба – бардым»,

«Алдыңба – алдым».

Малайдан да, қыздан да сорайлар өч қатар. Аталықны қыз йақтан қуйайлар. Зурлайлар инде. Аталық ул күптән түгел генә өйләнгән йәш кеше була *(Кышлау)*.

### *Қызны күчереп килү*

– Қызны күчереп килгәндә бау тотайлар, атларға бау тотайлар. Аларға ақча, қозоқ сибәйләр.

Қызны аттан төшереп, уң йаққа бастырайлар, бал белән май қаптырайлар.

Барлу кеше қаптыра:

«Балда-майда торсоннар», – дип.

Камфит, қозоқ (чикләвек) сибәләр, балалар талашайлар. Йәймә йәйеп сибәләр қозоқны, қалын йәймә йәйәләр. Қызның башыннан сибәләр *(Абытай)*.

### *Қыз бикләү*

**Қыз бикләү** – никахтан соң егет белән кызны кавыштыру.

– Бүген қыз бикләргә инде дип йөриләр. Пирбуй көнне никахтан суң қыз биклиләр. Қыз белән малай икесе қала. Түшәкне қызныңқы йақыннары җәйә. Пастилне қарыйлар иртәгәсен. Үзе урынын иштырмасын, кергән йеңгә иштыра. Ул белә малай хәлен.

– Аулақ өйгә бикләйләр. Қыс йақтан әкәләре алып бара аулақ өйгә. Теге йақтан да нүгәрләр (кияү егетләре) бара мылтық мынан. Қыс мына йегет күрештеләр инде, аларға чәй қуйасың, қомған, тас, суwын, пастилын әзерләп бикләп китәсең инде. Монда туй бара. Икенче көнне қыс йақтан әкәсе-абасы (абыйсы-анасы), малай йақтан әкәсе-йеңгәсе (абыйсы, җиңгәсе) барып, ишекне ачайлар, чәй қуйайлар. Қода-қодағыйлар, хәрендәш-туғаннары килә. Никахта бикләгәндә генә бер-берсен күргәннәр *(Кышлау).*

### *Қуйын канфиты*

**Қуйын канфиты** – кияү күчтәнәче; аны, кыз куенында кунып чыкканнан соң, кияү күчтәнәче итеп өләшәләр.

– Килен белән кийәүне айырым өйгә бикилиләр. Анда қунып чыққач, кийәү қуйын канфиты қалдырып чыға. Аннан мунчаға баралар.

– Қуйын канфиты өләшкәннәр кийәү белән қыз қунып чыққан сун. Балалар җыйылып киләләр. Аwылдағы бөтен бала килә қуйын канфиты алырға *(Әүштә).*

### *Сип, сипне алып бару*

**Сип** – кызның бирнәсе.

– Икмәк-тоз белән сипне алып бардылар. Алдан тозны алып бардылар, аның артыннан икмәкне алып бардылар тезелешеп. Сипне ақ чеберәкләргә бәйләп, гөлләп, тезелешеп алып бардылар.

Қодаларына, қодаларға көйнәкләр, йаулықтар қуйайдар. Сип тип атала. Тоз-туғачлар мән барайлар *(Әүштә).*

**Қызға малай йақтан бирәләр:**

– Без қызны бирәбез, йөз тәңкә бирегез, – диләр. Бер йәш кенә турбак тойоққа бирегез, қысырақ диләр. Суйарға инде. Бер

пот бал, чәкчәк йасарға. Барын да бирделәр. Бөтен радн'алары көйнәк бирделәр. Бер зур сандық тутырдылар. Без кечү ийек әле. Барын да тутырып алып бардылар қызға малай йақтан. Бал күп, умарта күп ийе.

– Қызның атасы кийәү йақтан ақча сорый, байтақ ит сорыйлар, гөрөс (дөге), сары май, шикәр китереп китәләр туйға қәдәрлек. Қыз йағы қода сорый, кийәү йағы китерә *(Кышлау).*

### *Килен хезмәте*

– Қәйнинәм әйтә:

«Килен, чық йилтеккә (келәткә). Ачқыз ал да кер. Чапчақ (кисмәк) эчендә орбақ (көрпә, кибәк) бар. Ул орбақны ал да турбаққа (танага) сал».

– Қазан йағына себерәктән (себердән) килен алғаннар. Инәсе аш йасарға (токмач) қушқан килененә, минем күкәмә (апага). Ул қамырны басқан, йәйәргә кирәк.

«Инәм, сәкәлүк қайа?» – дип сорый икән. «Нәстә ул сәкәлүк?» Ул себерәкчә сәкәлүк, ә казанча – уклау. Сөйләп-сөйләп аңлатып биргән.

– Инәм себерәкчә әйткән:

«Таплар иштырып алып кер әле». Бу бақыр кергән дә сораған «Нәрсә табарға?» Ә ул тап – йомычка. Пичкә йағарға.

– Қоймақ пешерәбес.

«Тап алып кер әле». Мин чықтым тышқа. Тордым, тордым. Ни табыйм? Белмим, ни тапқалы. Кердем.

«Инәм, нәстә ул тап?» Йомычқаны тап дийәләр себерәкләр.

– Кийәү Казан йақныкы булган.

«Хөсәйен, син састөп китер әле!»

Әтийем сазга барып, нәрсәдер эзләгән, белмәгән ни китергәле. Ә инәм себерәк иде.

«Қарчық, миңа саз төбе табып бир әле», – дигән.

Инәм көлгән: «Састөп – ул көрәк», – дигән.

– Йилгәктә (иләктә) оннар иләйләр киленнәр, орбағы қала. Сыйыр шәйкәсенә салабыз орбақны, типшегә (тагарак).

– Икмәкне ачытқы белән пешерәсең. Элеке «куwашна» (ипи күәсе) диләр ийе. Қайсы кеше «кушана» дийә. Аусақ (усак) агачтан була куwашна. Олу мичтә пешерәләр.

– Элеке пичне йағасың. Пумала белән себерәсең ике кат. Элеке суқма пич булған балчықтан. Қалачны аунатып табақта күптерәсең (күпертәсең) *(Кышлау).*

### *Туй атлары*

– Туй атларын көллиләр (гөлли, ягъни бизи), шыңғырақлар (кыңгыраулар) тагалар.

– Утызар пар ат йигеп баралар. Умбиш-йегерме хәзәин бара йақшы атлар йигеп.

– Қыз алырға барған йирдә қода булған кеше, киленнең қайнатасы йақшы ат алып бара. Урамның бер йағыннан икенче йағына арқан сузған була. Йиккән ат сикереп чықсын шул арқанны. Шундый иде. Сикереп чыга алмый икән, түли, ақча бирә. Аннан суң арқанны чишеп қуйалар, кертәләр. Йақшы атлар сикереп чыға торған ыйы арқаннан *(Умавыл).*

### *Туйда җырлашулар*

Туйда қайын инәм безгә җырлады:

Алтын балдақ, көмеш қаш,
Кирәк булса, сандық ач.
Сезнең кебек булса булыр
Сәхрәләрдә сандугач.

«Аwылның беренче қызын малайыма алдым», – дип мақтанды.

Кийәwем җырлады:
Без андый малай түгел,
Без мондый малай түгел.
Төрле қулларға йарыйбыз
Күгәргән калай түгел *(Әүштә).*

### *Кыруг уйнау*

– Кыруг уйныйлар қызлар. Йөргәнең белән кыругта йөреп чыгасың. Бийергә төшерсәләр, йөргәнең белән төшерәләр.

Кыругларда уйнаганда
Әйләнмиме башларың?
Күз өстендә хәләм кебек
Синең қара қашларың.

Кылупларга килеп керсәң,
Салып кер галушыңны,
Бер қычқырып жырлап җибәр,
Йаратам таwышыңны.

Тумыски дип йөретәләр
Үзебезнең қаланы.
Қарурманнар, бийек таулар
Каплый безнең араны.

Бийек тауга менмә, дустым,
Бийек тауда җил-даwыл.
Булма матур, бул бәхетле?
Бәхетсезлек бик аwыр *(Әүштә).*

– Баш қашында (тау башында) йинала идек, йәшләр белән тотынышып кыруг уйный идек. «Ал Зәйнәбем» уйный идек *(Кызылкаш).*

**Аш-сулар**

Том һәм Кемерово өлкәләрендә элек-электән атларны күп асраганнар. Шушы якның кырыс табигатенә җайлашкан атлар кыш көне дә җирдән тояклары белән карны казып, үзләренә ашарга азык таба торган булганнар.

**Ат ите** – иң күп кулланыла торган ашамлык. Ат итеннән казылык тутыру да гадәти күренеш. Әле хәзерге чорда да күп өйләрдә казылыкны затлы ризык итеп кунаклар алдына куялар.

**Қуллама** – ит белән токмачтан әзерләнгән ашамлык.

– Қулламаны ат суйғач баш итеннән пешерәбез. Баш ите йомшақ була. Тоқмачны күкәйгә генә басып, шақмақлап кисәбез, итнең шулпасына салып, тоқмачны қайнатып алабыз. Шулпаның өстен жыйып алып, суган, борыч салып, ит белән тоқмач өстенә сибәбез. Менә сиңа қуллама! *(Әүштә).*

***Күш, кож***

**Күш** – ит: **ат күше** – ат ите;

**майған күше** – үрдәк ите;

**боға күше** – үгез ите.

– Күшне күп ашағаннар. Бер қышқа дүрт-биш ат суйғаннар. Зур-зур сөйәкләр жыйылып қалған, әле дә чығалар бақчадан.

**Қуй күше** – сарык ите.

– Қуй күшеннән шулпа, пылау пешерәләр.

**Ат күше** – ат ите.

– Ат күшеннән қазы тәмле була. Симез күш кирәк.

**Күш бәлеше** – ит бәлеше.

– Ат суйғанда, боға суйғанда күш бәлеше пешерәбез *(Кышлау).*

### *Қазы тутыру*

**Қазы** – казылык.

– Итне туңырып элеп қуйалар келәткә. Йаңа йылдан соң қазы тутыралар, җәй буйы қазы ашыйлар.

– Күшнең (итнең) йомошагын, қазысын бергә турыйсың. Қазы – самый симез җире. Тоз белән борыч салып бер атна тотасың. Пийаз (суган) салмыйсың. Аннан туңырасың да тышқа апчығып эләсең қараңгы җиргә.

– Қазы – ат кожыннан (итеннән) була. Симез булсын кож. Қыр сөргәндә қазы ашый, тамақ туқ була.

– Ат итен эчәккә тутыралар да ызба башына меңгереп эләләр. Ит бөгелеп тормаса, қазы әзер була. Хәзер ул заннар (гадәтләр) бетте инде.

– Йаз мәлендә тутыралар қазыны. Итне зур кәстрүлдә тозлыйсың. Сугы-нийе белән тора. Инәм боға (үгез) итеннән дә тутырды қазы.

– Ат итен нәзек кенә кисеп, йақшы ғына тослайсың. Тос сеңә. Майы белән бергә тослайсың. Март айында қазыға тыға башлыйсың, ат эчәгесенә. Өй башына (чормага) эләсең. Ул кибә. Утыс, қырық, илле була. Аш-шулпа йасайбыз, пешереп тә, қыздырып та ашайсың. Йыл да йасайбыз қазы.

– Суғымны суйабыз да арт санын алабыз. Ике кәстрүлгә тозладым. Өстенә су салам, саллафан қуйып қалдырам. Қыш буйы утыра, йил суқмый.

– Ат эчәгесен йуwып киптерәм. Қарт атнықы кирәк, йәшнеке тетелә. Тозлаған итне шунда тутырасың. Кәзәнкәдә тора йилдә. Кибә, өлгерә. Җәй буйы қазы ашыйбыз.

– Қазы турап пылау да пешерә, аш пешерә. Қырығар қазы тутыралар қайсы кеше *(Әүштә)*.

### *Балык шулпа*

– Җәйен балықтан балық шулпа пешерәбез, туйга да шулай йаратабыз *(Сарсаз)*.

### *Бәтер, пәтер*

**Бәтер, пәтер** – төче күмәч.

– Бәтер пешерәбез чөчедән. Майга салабыз да пешерәбез. Ул бәтер була, хәйергә бирәбез *(Тумаел)*.

### *Ипи, ипекәй*

– Матча, матча йанында ағач киштә қадақлаған. Ипиләр шунда йуғарыда торған. Сорамыйча җайлы-җайсыз алып ашамағаннар. Ипекәйләр бик кадерле булган элек *(Куркули)*.

### *Кейәү өкмөге, кийәү икмәге*

**Кейәү өкмөге** – кияү ягыннан китерелә торган күчтәнәч калач, ак күмәч.

– Кейәү өкмөге дип қалач салайлар, телемләп-телемләп өләйләр. Кейәүнең инәсе пешереп аппара *(Кышлау)*.

**Кийәү икмәге**:

– «Аwыз итеңләр, кийәү икмәге», – диләр. Йемешләр кушып пешерәләр.

Никага (никахка) барганда кийәүнең инәсе пешерә кийәү икмәген *(Әүштә)*.

### *Кийәү чөпчәрәсе*

**Кийәү чөпчәрәсе** – кияү пилмәне.

– Қамырны күкәй салып басасың да төйгән ит саласың да кийәү чөпчәрәсе пешерәсең. Кийәү кысты алғалы килгәндә пешерәсең инде аны *(Кызылкаш)*.

– Дүрт читкелле чөпчәрә йасыйлар (ягъни дүрт почмаклы пилмән ясыйлар) *(Кышлау)*.

### *Озын аш, шақмақ аш*

**Озын аш** – озын итеп киселгән токмач.

**Шақмақ аш** – шакмаклы итеп кисеп әзерләгән токмач. – Туй-ашқа шақмақ аш уңай.

### *Умач*

**Умач** < ума+аш:

– Озын ашқа карағанда, умач ашы тәмлерәк. Сөтлү ашқа, балтырған ашына умач уwып салабыз.

### *Чумар*

– Чумарны инде тоғомға (йомыркага) чиләсең (басасың). Без шулай «чиләбез» дип әйтәбез.

«Қайа чумар, кеше башына унар», – дип пешерә идеге. Балтырған белән чумар пешерәбез *(Тумаел).*

### *Сөртмәч*

**Сөртмәч** – юка итеп җәеп, казанга салып, майда пешерелгән күзикмәк.

– Сөртмәчне элек коръән ашларына пешергәннәр, хәзер аны белмиләр инде. Күкәйгә қамыр басып, аны йука итеп җәйәләр дә, зур қазаннарда май қайнатып, майда пешерәләр.

Сөртмәчләрне туғызар-туғызар итеп туғыз җиргә өйеп куйғаннар. Ник туғызарны пешергәннәр, анысын әйтә алмыйбыз *(Кышлау).*

### *Шәңгә*

**Шәңгә** – бәрәңге пәрәмәче.

– Шәңгәне ачу камырдан пешерәләр. Бәрәңгедән дә, туаруктан да әйбәт була шәңгә. Оло мичкә йағалар да тығалар шәңгәне *(Сарсаз).*

### *Шишара*

**Шишара** – кечкенә ипи.

– Ипи камырыннан шишара салабыз. Ипи пешкәнче бу шишара йарты сәғәт эчендә пешеп чыға. Шул шишара белән чәй эчәргә күрше әбине эндәшәбез:

«Әйдә кер, шишара белән чәй эчеп алыйқ».

Шишара озынча була. Ике-өч сыр ясап қуйалар. Шишараны мич төбендә пешерәләр, ә көлчә табада пешә *(Куркули)*.

### *Пиреженник*

**Пиреженник** [< рус. пирожки] – кечкенә бөккән.

– Камыр кабарып чыккач та җәйәсез дә, эченә қара қарлығанмы, маланмы салып, бер ун ыштук йасап қуйасың да табаданға салып пешерәсең майда. Аны ике йақлап пешермисең, бер йақлап қына пешерәсең, өстенә майны сибеп торасың.

Қарағат (карлыган) күп үсә бездә. Бер чиләк қарағат җыйып алабыз. Аны қайнатасыңмы, қоротасыңмы. Ул менә пиреженник эченә салырға да бик әйбәт була қарағат *(Кышлау)*.

### *Самза, самса*

**Самза, самса** – әче камырдан пешерелгән кабартма.

– Самза – әче камырдан була. Күкәйгә қамыр басып қабартабыз да, кискеч белән кисәбез. Казанда майда пешерәбез Элек самзаны сөртмәч өсләренә өйеп қуйа торған булғаннар. Тастархан йәмле булып тулып торган. Қамырың унҗса, самза бик қабарып пешә *(Әүштә)*.

### *Баwырсақ*

– Бавырсак; инде күкәйгә генә изеп түгәрәк-түгәрәк итеп, вак кына итеп май эчендә пешерәбез. Ачы қамырдан була. Өстәлгә қуйарға матур, сарыға манган күкәй кебек тора ул.

### *Қырық қат*

– Төче қамырны йуқа ғына итеп җәйәсең дә қамыр өстенә мәкне пешереп җәйәбез шикәрләп. Мәкне әз генә қайнатып алабыз шикәрләп. Шуны қамырға җәйәбез дә төрәбез, аннан кисәбез. Шул қырық қат була. Ачы қамырға да шулай уқ мәк йағып пешерәбез.

Киндер орлоғы төшен дә җағабыз қырық қатқа. Инәки шулай пешерәдерийе киндер орлоғы белән. Тимер кәйләдә чичти майланғынчық төйәдерийе шул киндер орлоғын. Туқмач қамырына җәйәдерийе *(Сарсаз)*.

### *Балтырған*

– Қырны жаратқанға күрә қырға барамын, балтырғанға барамын. Балтырған жыйып алып қайтам. Менә сезгә дә пешерәм балтырған. Күкәйләр салып, қаймақлар алып пешерсәң, қуwырсаң да була балтырғанны. Бик тәмле. ул балтырған. Мин жаратам аны. Урманға барырдай қарчықлар жуқ хәзер.

**Балтырғанлы умач:**

– Әле беркөн генә балтырған турап, умач уwып аш пешерн дем. Балалар балтырған алып қайтып бирде.

**Ачы қатық қатып былтырғанлы умач пешерү:**

– Менә әле дә инәки умач уwарға онны иләп өстәлгә қуйған да үзе чығып киткән. Ачы қатық қатып балтырғанлы умач ашарга килегез.

### *Чалқай*

**Чалқай** – кычыткан.

– Чалқай – бик файдалы нәстә ул. Элеке қартлар аннан аш быҗырган, чалқайлы аш ашағаннар.

Чалқай белән айақларын чапқаннар мончаға кереп, айақ сызлағанда чапқаннар. Быҗырып ашағаннар қартлар. Чалқай бөтөн йирдә үсә ул *(Кышлау)*.

### *Шишка*

**Шишка** – кедр (эрбет) чикләвеге.

– Шишка күп була. Кидрачлыкта була шишка. Айулар да шишканы йарата. Шишка булмаса, җиләк булмаса, айулар малларга да ташланалар *(Әүштә)*.

### *Күбүргән*

**Күбүргән** – юа.

– Күбүргән тумар җирдә үсә ул. Пучуклап җыйасың. Күбүргән дип әйтәләр.

**Сай күбүргәне** – сазлык юасы.

**Таш күбүргәне** – ташлык җирдә үскәне.

– Кышлауға барсаңар, Кышлауда күп үсә ул. Табанлап (учлап) җыйасың, табачқа җыйасың да өзеп-өзеп, пучоклап бәйләп қуйасың биленә *(Тумаел)*.

## *Канба*

**Канба** – русча *черемша* диләр.

Тозлап та җуйалар канбаны, җаймаҗлап та ашыйлар.

– Көн туса, шушы канбага жыйылып китәбез аwыл балау̇лары. Урман эчендә җапчыкны тутырып, шушы канбаны алып җайтабыз да, шуны аш та итәсең, ботҗа да итәсең. Күп булып үсә ул канба. Урып барасың да барасың.

Айу йөри урманда, ә без канба жыйып йөрибез *(Жылы Елга).*

## *Саргай*

**Саргай** – андыз.

– Сарғайның чәчәкләре салынып тора. Аның төбендә күкәй шикелле нәрсә үсә икән. Аннан бутға йасап, сөт салып ашаганнар *(Кышлау).*

### МӘГЪЛҮМАТ БИРҮЧЕЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

**Том өлкәсе**

**Әүштә** авылы: Галәветдин (Галук), Корбанбаев Мәхмүд, Кабаева Фаизә, Корбанбаева Көлҗәвәр, Корбанбаева Көлсәрвәр, Корбанбаева Сания, Кусаиров Ходжәт, Кучкульдинов Әбүбәкер (Әүбә), Нәҗметдинова Идия, Нәҗметдинова Майура, Сәйфелмөлекова Бибиниса, Сәйфелмөлекова Рәхимә, Тушакова Мәүлия, Үтәгәнова Мөршидә, Фәсхетдинова Нәсимә, Хәмитов Харис, Хәмитова Нәгыймә, Шәрипова Зөләйха.

**Кызылкаш** авылы: Акумбатова Зөбәйдә, Аплина Хәмдениса, Баязитов Насыйбулла, Бикулов Халикъ, Вафина Хәдичә, Казаков Әпсәләм, Казакова Гөлҗиһан, Казакова Сания, Рәхимова Нурия, Сәйфәмөлеков Гаяз, Фәйзуллина Наилә, Хәйдәрова Сария, Шаһивәлиева Диләфрүз.

**Умавыл:** Абакаева Гайникамал, Абакаева Мәрхәбә, Бикмуллина Альфира, Бикулова Рауза, Измайлова Мәймүнә, Латыйпова Маһруй, Мамышева Маһирә, Мамышева Румия, Мөхәммәтҗанова Сафия, Мөхәммәтшин Әхмәтгали, Муксунова Майса, Нәҗметдинов Насибулла, Пономарева Әминә, Пономарева Шәмсенур, Сәйфелмөлекова Нурия, Үтәгәнов Хәлиф, Фәхретдинова Нәзия, Шәйдуллина Сәкинә.

**Абытай** авылы: Вәлиуллин Марвит Шәрип улы.

**Калтай** авылы: Әбдрәшитова Зәйнәп, Фәтхуллин Шәрип, Хәлилов Ибраһим.

**Кемерово өлкәсе**

**Юрга районы Кышлау** авылы: Әбдрәшитов Рәшит, Әбдрәшитова Мәрвәрит, Әбдрәшитова Мәрвәрия, Әбдрәшитова Фәридә, Батталова Гафифә, Зариева Хәерниса, Кармушакова Заһидә, Кармушакова Мөхәррәмә, Кәшифә апа (Кәшей), Кинҗәгулова Мәрьям, Кинҗәгулова Суфия, Кусов Рафис, Кусова Мөршидә, Кусова Флера, Мазитова Мәстүрә (Мамай), Садыйкова Майнур, Селиванова Рәхимә, Сиражетдинов Фәрит, Тартыкова Галия, Фәйзуллина Галия, Фәйзуллина Фәрхиямал, Фәйзуллина Хөллә, Хисаметдинов Кәбирҗан, Хөснетдинова Кәшифә, Шахманова Лилия.

**Юрга районы Сарсаз авылы:** Батталов Мәлик, Бикчәнтәев Камалетдин, Гыйләҗетдинова Мәрфуга, Кусов Абдулхак, Фәйзуллина Сафура, Хабышева Мәхмүзә, Шаһабиев Рәшит, Шаһабиева Сания.

**Мариин районы Куркули авылы:** Абякова Тәслимә, Вәлимөхәммәтова Камилә, Гафурова Хәлимә, Ибраһимова Гөлнур, Кәлимуллина Рәхилә, Фусаинова Гарифә.

**Ижмор районы Яңа авыл:** Алеева Зәйнәп, Алимова Хәлимә, Әхмәтова Гайшә, Әхсәнов Әюп, Гобәйдуллина Зәлидә, Ризванова Сания, Ходайбирдин Морат, Ходайбирдин Сөнгат, Ходайбирдина Зәбидә, Ходайбирдина Зөбирә, Ходайбирдина Рәшидә, Ходайбирдина Яуһәр, Юнысова Фәһимә.

**Яшкин районы Тумаел** авылы: Айнагулова Нурия, Атнагулова Кәйшә, Басимова Шәфика, Кәримова Әкълимә, Лазерова Наилә, Пасимова Шәфика, Пономарева Майбәдәр, Садыйков Бари, Садыйков Сөнгать, Садыйкова Гөлҗиһан, Садыйкова Рәйхана, Сәвәргулова Зияфә, Тартыкова Фәрәзә.

**Анжир районы Җылы Елга** авылы: Алеева Фәүзия, Алиев Нурулла, Алтынбаева Фатыйма, Биккулова Бәгыймә, Бикмулла (Бикүш), Газизә (Газүш), Галиева Әсма, Гарифә (Гәрфүк), Латыйпова Асия, Латыйпова Фәния, Мәййәмәл (Маюк), Мөслимова Суфия, Мусина Даирә, Мусина Мөслиха, Ризванова Мәрьям, Рамазанова Фәния, Сәйфулла (Сәкүк), Хәкимова Рәшидә, Хәкимова Сания, Шабаева Мөршидә, Шабаева Рәшидә, Шабаева Яүһәрия.

## ТОМСК ТАТАРЛАРЫНЫҢ ТЕЛ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ ҺӘМ РУХИ МӘДӘНИЯТЕ

*Миңнира Булатова*

*Том буйлары, Том буйлары,*
*Борылып аққан аның сулары.*
*Том буйлары, Том буйлары,*
*Сызылып атқан алсу таңнары.*

Җырларда данланган Том елгасы тирәли сибелеп утырган Абытай, Казан, Калтай, Кирек, Кызылкаш, Умавыл, Яңавыл, Әүштә исемле татар авылларына һәм Томск шәһәренең «Татар Бистәсе»енә фәнни сәфәребез милләттәшләребезнең гореф-гадәтләрен, көндәлек һәм мәдәни тормышларын яктырткан материаллар тупларга һәм тел үзенчәлекләре җәһәтеннән фәнни нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирде.

Томск шәһәренең «Татар бистәсе» XVII гасыр башында ук барлыкка килгән. Аның төп урамы «Татарская» дип атала. Бу урам, башыннан ахырына кадәр, искиткеч матур итеп бизәкләп эшләнелгән, агачтан салынган ике катлы йортлардан тора. 1914 елга кадәр бистәне шәһәрдән Исток дип аталган кечкенә ерганак аерып торган. Хәзер бу Исток җир астыннан агып, Том елгасына килеп кушыла. Аның шушы өлешен Заисток дип атаганнар.

Татар бистәсенең М. Горький урамындагы 35 нче йортта татарларның төп җыелу урыны – «Татар мәдәни үзәге» бар. Ул 1906–1910 елларда ук салынган һәм ерактан ук күз явын алып

торырлык зәңгәрсу төстәге «Кәрим бай йорты»нда урнашкан. Заманында сәүдәгәр, хәйрияче, җәмәгать эшлеклесе Кәрим Хәмитов аны үз гаиләсе өчен салдырган булган. Бай атлар үрчетү белән шөгыльләнгән, рус-япон сугышы чорында патша гаскәрен дә атлар белән тәэмин итеп торган. 1919 елда, бай үлгәч, гаиләсе башка урынга күченә. Йорт дәүләткә кала һәм биредә 1920 елдан Төрки-татар укыту семинариясе, ә 1930 елдан Төрки-татар педагогия техникумы вакытлыча эшләп алалар. Кәрим байның үз проекты буенча төзелгән бу йорт хәзерге көндә федераль дәрәҗәдә сакланыла торган архитектура һәйкәле дип санала. Боларны безгә Татар мәдәни үзәге хезмәткәре Сафиуллина Елена Шәүкәт кызы сөйләде. Татар мәдәни үзәгенең барлыкка килүенә 20 ел, ә Кәрим бай йортына алар 1996 елда килеп урнашалар. 1994–2005 елларда үзәкне Әбдрәшитов Йосып Якуп улы, ә 2005 елдан Сабирова Флюра Гафур кызы җитәкли. Мәдәни үзәкнең гөрләп алга китүенә 1970 елда оешкан «Халкым моңнары» вокаль ансамбле ныклы этәргеч була. Коллектив белән җыр-моң яратучы, мандолинада өздереп уйнаучы Әнвәр Шәйдулла улы Зиннәтов җитәкчелек иткән. Хәзер бу ансамбль эшчәнлеге, олы яшьтәге әби-бабайлар саны кимү сәбәпле, сүлпәнәя төшкән. Биредә тагын зур уңышлары белән сөендереп «Нур» хор ансамбле эшләп тора. Быел алар Новосибирскида ике елга бер уздырыла торган «Себер йолдызлары» дигән конкурста катнашып беренче урынны яулаганнар. Үзәккә 4 яшьтән башлап 80 яшькә кадәр күпләп кеше йөри. Төрле яшьтәге балалар татар җырларын, шигырьләрен, биюләрен, кул эшләрен бик теләп өйрәнә. Бу йортта татар мәдәниятен саклау белән шөгыльләнә торган 15 тән артык берләшмә эшли. Өлкәннәр өчен «Замандашлар» ретро-клубы, «Ялкын» вокаль-инструменталь ансамбле, яшьләр өчен «Айнур» бию төркеме, «Дуслык» клубы һ.б. бар.

Кәрим бай йортына кушылып ук урнашкан бинада Себер, Томск, Заисток районы тарихына караган төрле материалларга бик бай «Заисток» музее бар. 30 елдан артык музейны җитәкләүче Лидия Васильевна Муравьева Татар Бистәсе һәм Кәрим бай турында бик күп мәгълүмат бирде. Аның Заисток

районы тарихына багышланган «Моя малая родина (из истории Заистока)» исемле китабы (автордашы – Н.Г. Савельева) басылып чыккан. Бу хезмәттә Кәрим байның килеп урнашуыннан алып, бөтен гомер юлы, яшәеше, ул үлгәннән соң бу йорттаниләр булуы турындагы мәгълүматлар һәм байның балалары, оныклары сөйләгән истәлекләр урын алган.

Томск шәһәренең Татар бистәсендә ике мәчет тә бар: ак мәчет һәм кызыл мәчет. Халык әйтүенчә, татарларның күпчелеге кызыл мәчеткә йөрсә, башка милләттәге мөселманнар ак мәчеткә агыла.

Том авыллары халкы безне ачык йөз белән каршы алдылар. Хәтта Татар мәдәни үзәгенә 10–15 ләп «Нур» (берничәсе «Халкым моңнары»ннан) ансамбле апалары җыелышып безне көтеп утыралар иде. Алар үзләренең туган якка мәхәббәтләрен көй-моңнары, җыр-биюләре аша җиткерделәр. Ярымтүгәрәк итеп тезелешеп утырып, Себер ягы, аның халкы, көнкүреше турындагы төрле хәлләрне, легенда, бәетләрне сөйләп ишеттерделәр.

Гомумән, фәнни экспедиция вакытында бай һәм бик кызыклы материал тупланды. Җирле сөйләш үзенчәлекләрен яктырткан, традицион культура, авыллар тарихы, гореф-гадәт, йолаларга караган этнолингвистик материаллар һәм күпләгән лексик берәмлекләр җыелды. Җирле сөйләш үзенчәлекләренә килгәндә, аралашу, әңгәмә алып бару вакытында шул күзгә ташланды: 60 яшьтән түбәнрәк информантларыбыз әдәби телдәрәк сөйләшә һәм рус сүзләрен рәхәтләнеп кулланалар, тәрҗемәсен әйтә дә алмыйлар. Өлкәнең тел үзенчәлекләрен беренчеләрдән булып ныклы өйрәнүче тел белеме галимәсе Д.Г. Тумашева һәм аннан соңгы буын фән докторлары Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Баязитова, биредә том диалектының әүштәчат һәм калмак сөйләшләре таралган дип исбатлыйлар[1].

---

[1] *Тумашева Д.Г.* Диалекты сибирских татар. Опыт сравнительного исследования. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1977. 295 с.; *Рамазанова Д.Б.* Себер диалектларыннан материаллар. Казан: Фикер, 2001. 143 б.; *Рамазанова Д.Б.* Татар теленең көнчыгыш диалектлары. Төмән: Вектор Бук, 2007. 258 б.; *Баязитова Ф.С.* Себер ареалы татар диалектларында этнокультура лексикасы: йола һәм мифология текстлары яссылыгында. Казан: Алма-Лит, 2010. 738 б.

Д.Б. Рамазанова әүштә-чат сөйләшен Д.Г. Тумашева хезмәтләренә таянып һәм үзе 1996, 2005 елларда уздырылган экспедиция вакытында туплаган материалларына нигезләнеп «Татар халык сөйләшләре» дип аталган китапта тасвирлый. Шунда ук Т.Х. Хәйретдинова, Ф.С. Баязитова белән берлектә 2003 елда уздырылган экспедиция материаллары нигезендә аның тарафыннан калмак сөйләше дә тәфсилләп языла[1]. Әлеге сөйләшләрдәге үзенчәлекләр күбрәк өлкәнрәк яшьтәге әбибабайлар сөйләмендә сакланган. Күрәсең, сөйләш вәкилләренең үзара аралашып яшәве, татар әдәби теленең совет чорында көчәеп килгән татарлар сөйләше борынгыдан себер җирендә көн күргән «себерәкләр» сөйләшенә ныклы тәэсир иткән. Алар Татарстаннан башлап көнбатышка таба территорияне «Казан як» дигәннәр. «Безнеңке мамау-бабаулар (*әби-бабайлар*) Казан йактан (*ягыннан*) килгәннәр» дип сөйлиләр. Монда Түбән Новгород, Пенза, Сергач якларыннан күпләп мишәрләр дә килгән һәм алар себер сөйләше йогынтысына бик бирелмәгән. Мәсәлән, Мөхәррәмов Фәсхетдин Кәлимулла улы сөйләвенчә, башта кирҗаклар яшәгән Кирек авылына Сергач районының Парчалы (хәзер Тукай дип атала) һәм Бозлау авылларыннан мишәрләр гаиләләре белән күченеп килеп утырганнар (авыллар тарихы турында мәгълүмат сөйләм үрнәкләре бүлекләрендә тулырак бирелә).

## Фонетик үзенчәлекләр

***Сузыклар.*** Әүштә-чат сөйләше сузык авазлар составы ягыннан әдәби телдән, нигездә, аерылмый. Ә калмак сөйләшендә *а* авазы мишәр, себер һәм урта диалектның кайбер сөйләшләрендәге кебек иренләшмәгән: *қатыштыру* – әдәби ка$^{о}$тыштыру (чагыш.: тевриз сөйләшендә, ягъни янәшәдәге Омск өлкәсе татарларында, сүз башындагы *а* авазына, әдәби телдән аермалы

---

[1] Татар халык сөйләшләре: Ике китапта: Икенче китап / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б. Казан: Мәгариф, 2008. Б. 427–459.

буларак, бик көчле иренләштерү хас, ул $о^{а}$, хәтта *о* рәвешендә дә әйтелә: *ќ*$о^{а}$*пќа* – әд. ка$^{о}$пка)[1].

Сузыклар өлкәсендәге үзенчәлекләр төрле тәңгәллекләргә, комбинатор үзгәрешләргә кайтып кала. **а~ы** (*ы* авазы урынына *а* авазын куллану): *суwаќ* – әд. суwык (суык), *аwырап йатты* – авырып ятты; **ы~а:** *туйғынча* – туйганчы, *йаңы* – йаңа (яңа); **ө~о:** *йөн* – йон; **о~у:** *тоғыс* – тугыз, *зор* – зур, *ќоанды* – куанды; **ө~ү:** *көптән* – күптән, *өскәрү* – үзгәрү; **ү~и:** *күгүwөн* – кигәвен, *үтек* – итек һ.б.

Әдәби телдәге *-ый/-ий* дифтонгына *-ай/-әй* дифтонгы тәңгәлләшә: *сөйләй* – әд. сөйли, *теләй* – тели, *барлай* – барлый.

III зат хәзерге заман хикәя фигыльләрнең *-а/-ә* кушымчасы да *-ай/-әй* дип яңгырый: *төшәй* – әд. төшә, *үсәй* – үсә, *күренәй* – күренә һ.б.

***Тартыклар*.** **ц~ч:** *мәцет* – әд. мәчет, *кецкенә* – кечкенә, *ацыќ* – ачык, *перенце* – беренче, *цыпцыќ* – чыпчык; **п~б:** *пийыл* – быйыл (быел), *пала* – бала, *поронғы* – борынгы; **б~п** (алынма сүзләрдә): *былау* < плов – пылау; **м~б:** *малан* – балан, *йарабый* – йарамый, *әйбә* – әйеме; **з~с** (ике сузык арасында): *кизеп* – кисеп, *баразың* – барасың; **с~з:** *ќасылған* – казылган, *барабыс* – барабыз; **й~җ:** *йеләк* – җиләк, *йыр* – җыр; **ж~ш** (ике сузык арасында): *тажы* – ташы, *ќыжын* – кышын, *быжыраќ* – пычрак; **ќ~х:** *ќатын* – хатын, *бәркет* – бәрхет һ.б.

Кушымчадагы башлангыч *л* авазының үзеннән алда килгән тартыкларга *(п, к/ќ, т, с, ш, ц, ч)* охшашлануы:

а) күплек кушымчалары: *ќунаќтар* – әд. кунаклар, *орыстар* – урыслар, *ќоштар* – кошлар, *кирпецтәр* – кирпечләр;

ә) сүзъясагыч *-ла/-лә, -лык/-лек* кушымчаларында: *баштаған* – әд. башлаган, *көстек* – күзлек;

б) сыйфат ясагыч *-лу/-лү (-лы/-ле)* кушымчасында: *тәрәстү* – әд. тәрәзәле, *ике йаташту* – ике йаташлы (ике катлы) һ.б.

---

[1] *Булатова М.Р.* Себер дә үзебезнеке (Омск татарларының тел үзенчәлекләре) // Милли-мәдәни мирасыбыз: Омск өлкәсе татарлары. Казан, 2015. (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән; алтынчы китап). Б. 195.

Уңай ассимиляция күренеше: *с, қ, к, р, п, т, ш, ц* тартыкларыннан соң килгән төшем һәм чыгыш килеш кушымчаларындагы *н* авазы *т,* ә сонорлардан соң *д* авазы белән тәңгәлләшә: *сөтте* – әд. сөтне, *мәктәпте* – мәктәпне, *бестеке* – безнең, *тамырдың* – тамырның һ.б. *Йәштәргә кирәк клупты эшләткәле* – Яшьләргә клубны эшләтергә кирәк.

## Морфологик үзенчәлекләр

Иялек килеше, әдәби *-ның/-нең* кушымчасы белән беррәттән, *-нықы/-неке* кушымчасы ярдәмендә дә ясала: *Калхустықы* (әд. колхозның) *ысклат иде. Бу атамныңқы* (әтиемнең) *бер туған сестрасы. Бы орысларныңқы* (урысларның) *заимкасы. Ишмәй бабамнықы* (бабамның) *өйөндә ул. Менә бу Тумавылныңқы* (Тумавылның) *халығы – инәмнеңке туған йере.*

Компонентлары нисбәтлек мөнәсәбәтендә торган исем-исем сүзтезмәләрне (әбинең күлмәге, урам коесы һ.б.) кушымчасыз куллану: *Қасан йақ* – Казан ягы һ.б. *Сез йақта* (әд. сезнең якта) *сөйләйләр инде. Анда Воронин йақтан* (ягыннан) *килеп урлаганнар. Аwыл йанында Қазанцево заимка* (заимкасы) *булай. Икенце атнада тегендә туй, йегет йақта* (егет ягында) *туй.*

I һәм II зат алмашлыкларның юнәлеш килеше *мәңа/маға/ маңа/миңә, сәңа/сағa/саңа/сиңә* формаларында ясала. *Син баштай* (әд. башла), *мин сиңә* (сиңа) *булышырым* (булышырмын). *Син миңә* (миңа) *әйт кенә сүзләрен. Миңә* һәм *сиңә* формалары Башкортстанда яшәүче татарлар сөйләшләрендә, бигрәк тә курмантау сөйләшендә, бик актив[1].

Сорау алмашлыклары: *кем/ни/нимә* – әд. нәрсә, *қандый* – ничек, нинди, *қайсы, қанца* – ничә, *қацан* – кайчан. *Қандый* (әд. ничек) *әйтим инде. Әйтәй син монда килен булып килденмәле, урлап килгәннәрмә, нимәй итеп, қандый* (нинди) *булғансың, сөйлә.*

*Анца* – ‘шуннан бирле, шул чаклы, шул хәтле′ рәвешен куллану: *Алтмышынцы йылда тормошқа цығып, анца* (аннан <

[1] *Булатова М.Р.* Морфологические особенности татарских говоров ареала «Юг Башкортостана». Казань, 2013. С. 104.

шуннан бирле, ул чаклы) *торам инде. Анца* (шул хәтле) *қазлар, ике ат, өцәр сыйыр буладаған.*

Сыйфатлар азагындагы *-ы/-е* сузыклары *-у/-ү* белән тәңгәлләшә: *терлү* – әд. төрле, *йәмнү* – ямьле, *йарлу* – ярлы, *сикемнү* – сөйкемле һ.б.

Сөйләштә *-дый/-дий (-дәй/-дай*) кушымчасы белән рәвешләр ясау актив: *Элеккеләрдә генә сандық булған, бездий* (әд. безнең кебек) *халықта булбаған. Әнийемнеңке күлмәкләр бөдрә-бөдрә итеп, халадай* (халат кебек) *йеңнәре киң, итәкләре қатқат, қуштанлы* (бәбәй итәк) *итеп тегелгән.*

*-а/-ә/-ый/-и* кушымчалы хәзерге заман, нигездә, әдәби телдәгечә: *сизәм/сизәмен, сизәсең, сизә; сизәбес, сизәсес/сизәсеңнәр, сизәләр.* Мисаллар: *Мин китәмен циткә, йырақларға. Бесне ташлап китәсес* (әд. китәсез). *Вечерға урыс аwылыннан да қызлар киләләр. Шулай итеп донйа көтәбес* (көтәбез). *Ул аwылға да барасыңнарба* (барасызмы)?

Чат урынчылыгында II зат күплектә *-сыңнар* кушымчасына *-ңнар/-ңдар* кушымчасы тәңгәл килергә мөмкин: *Йәш wақытта қандай* (әд. нинди) *уйындар уйнағанды искә төшөрәңдәрбә* (искә төшерәсезме)*?* – Яшь вакытта нинди уеннар уйнаганыгызны искә төшерәсезме? *Сес қайа бараңнар, дийеп әйтәй* – Сез кая барасыз дип әйтә (сорый). *Нигә қороға эцәңнәр* (эчәсез)*? Йетешегез, ашаңнар* (ашагыз), *эцеңнәр* (эчегез)*, тип қыстайбыс қунақтарды.*

Көнчыгыш диалектларга хас *-ты/-те* кушымчалы хәзерге заман хикәя фигыль күбесенчә *-ди* формасында кулланыла: *борадим – әд.* борам*,* юклыкта – *борбайдим* – бормыйм; *борайдиң* – борасың, *борбайдиң* – бормыйсың; *боради/бораты/борат* – бора, күплектә *борадиләр/борадылар/бораттар* – боралар.

III заттагы нигез форма (*күрә, килә*) *-әй* кушымчасы белән дә ясалырга мөмкин (*күрәй* – күрә, *киләй* – килә) һәм аңа *-ди* күрсәткече ялгана. Берлектә – *күрәйди*, күплектә – *күрәйдиләр*. Юклык формасы: *күрбәй* – күрми, һәм шуларга *-ди* күрсәткече ялгана: *күрбәйди*. Мисаллар: *Килбәйдем* – килмим. *Минзифаға*

*булышай* (әд. булыша). *Қунаққа киләйдиләр* (киләләр). *Оцрашуға килбәйди* (килми).

Күптән үткән заманның ике формасы күзәтелә: *-ған/-гән/-қан/-кән + иде* формасында (*барган иде*) һәм *даған* сыйфат фигыль + *ите* ярдәмче фигыле ярдәмендә (*барадағаннар ите* – бара торганнар иде). *Минем атам бик матур йырлыйдаған ите* (әд. җырлый торган иде). *Урамда, су буйында йәйен йөридағаннар, уйныйдағаннар иде* (йөри, уйный торганнар иде).

Ул *-адаған/-отоған* (-а торган) формалы хәзерге заман сыйфат фигыльгә нигезләнеп тә ясала. Үткән заманда даими булып тора торган, гадәти булган эшне белдерә: *Лисичканы, груздасын йыштырма* (җыеп) *қайтып, тостап қышқыга әзерлидәгәнбес. Фронтовикларға дип бәйлидәгәнбес бийәлий, наски. Өцәр сутый ашлыққа йер қазыйдағаннар көнөнә.*

Бер юнәлеш урынына икенче юнәлеш формасын куллану: *Мамаwына* (әд. дәү әнисенә) *барышып* (барып) *килделәр. Салқын мунцаға кереп тә йуыша* (юына) *идем. Цәйе суымаған* (суынмаган). *Көлөшләнәбес* (көлешәбез) *шулай. Хәйер өләп* (өләшеп), *мулла цақырайлар. Тотондым йылашқалы* (< йылағалы – еларга). *Кецкенә цақта мунцада мине инәм йуыша* (юындыра) *торған иде. Мат' мачеха йыштыра* (җыя) *идем.*

Әдәби телдәге *-ырға/-ергә* формасындагы инфинитив белән беррәттән барлык себер диалектларындагыча *-ғалы/-гәле* формасы хас: *Сөйләйгәле қушай сиңә* – Сиңа сөйләргә куша. *Тыңнағалы* (әд. тыңнарга) *ғына йаратам. Мин мишкә* (гөмбә) *йыштырғалы* (җыярга) *йөрим. Көйөм дә йуқ йырлағалы* (җырларга). *Ғыйлмима мамай* (әби) *ике сәғәткә қәдәр йомға көннө йуwашқалы* (юарға) *йарабый, мондой эште эшләгәле* (эшләргә) *йарый дийә ите. Қайа уңай сатқалы* (сатарга) – *барадағанмын. Ышкулға килгәле* (килергә) *тийеш.*

Сыйфат фигыль: *-адаған/-атаған/-атқын* (әд. *-а торган*): *Он саладаған саwыт* – Он сала торган савыт. *Чәчкә тағадағаннары йуқ. Элек әнийемнең әйберләр, кийемнәрде саладаған сандығы қалған иде. Пецән цабадаған* (чаба торган) *йергә китәй.*

*-ганчы/-гәнче* формалы хәл фигыль сөйләштә *-ғынцы/-генце*, *-ғанцақ/-ғынцық/-генцек* вариантларында кулланыла: *Доғалықты ышкулға барғанцақ* (әд. барганчы) *йөрәдағаннар тағып. Мин килгенце* (килгәнче) *қайтып киткән.*

Бәйлекләр: *менән/мынаң/менәң/белән* – әд. белән: *Аның менән* (белән) *күгемәйгә йөрөй дәгәнбес. Циләк менәң йөгөреп-йөгөреп су ташыйдағанбыс. Мин абам* (апам) *мынан вечерға йөрбәйдем.*

Сорау кисәкчәсе *-ба/-бә/-ма/-мә/-бы/-ме* вариантларында күзәтелә: *Хәер қуйдым, доға қылырсыс, әйебә* (әйеме)? *Синең элекке әйберләрең барма* (әд. бармы), *фотоға төшөргәле? Қызың бар түгелбә* (түгелме) *инде*?

Сөйләштә *ғуй/ғой/қуй* (рус. ведь) раслау кисәкчәсе кулланыла: *Циккән цепрәкттәрде музейға бирдем ғуй* – Чиккән чүпрәкләрне музейга бирдем бит. *Күршеләр қуй* (бит), *кереп күрәрбес*. Омск өлкәсе татарлары белән чагыштырганда, әүштә-чат сөйләшендә бу сирәк күренеш.

## Синтаксик үзенчәлекләр

Исем-исем сүзтезмәләрдә, компонентлары нисбәтлекне белдерсә, бәйләнеш бернинди кушымчасыз да була: *Сез йақта* (әд. сезнең якта) *пешергәле осталарма* (осталармы)*? Қызылқаштан* (авыл исеме) *урлады иртән қорбан бәйрәм көн* (көнне). *Бестә Черна Речка мулла* (мулласы) *йөрәй көбесенцә. Менә тиз* (тиздән) *булай Ураза бәйрәм* (бәйрәме).

Сыйфат-исем сүзтезмәләрдә сыйфатның кушымчасын төшереп калдыру: *Ул ал урамда* (әд. алгы урамда) *торай иде, без арт урамда* (арткы урамда) *торай идек. Цийған* (чегән) *қаш* (тау) *пашында ал урамда* (алгы урамда) *торадаған ите. Пестеке Садоwайа, ал* (алгы) *урамнықы – Берегоwайа, анан ар* (ары) *урыс аwыллары.*

Хәрәкәтнең төшем яки урын-вакыт ноктасын белдерә торган исемнәрне баш килештә куллану очраклары да бар: *Бабайым ишеғалды* (әд. ишегалдында) *нәрсәдер йасап тора икән. Ишеғалды* (ишегалдын) *йабабыс бит – ул сарай.*

Кайбер фигыльләр башка килешне таләп итәләр: *Бала берас айақтан* (әд. аякка) *баса башласа, утыра башласа, ағац кроват*

*инде. Аwылда* (авылны) *пычратмаңнар* (пычратмагыз), *күл йаnына килмәңнәр. Чигү белән ун йәшләрне* (яшьләрдә) *булғандыр. Без бәләкәй булғанда Рәхим бабай безне* (безгә) *әйтәй иде: «Кеменәр йақшы йөгерәр, айылны* (авылны) *түгәрәккә әйләнеп кем алдан чықса, аңа бер камфит» тип.*

Җөмләдә *туу, тудыру* сүзендәге аермалыклар: *Ә мин бер бала менән икенце балам, икене тудым* (тудырдым/таптым) *Байазитовтан. Бу аwылда туылып* (туып), *монда үстем. Пала тудым* (тудырдым), *қайнинә сем'асын қарадым. Тетка дүрттебиште туған* (тудырган), *ул белә инде.*

«Син ничәнче елгы?» дигән сорауга, *-ғы* кушымчасы урынына *-нықы* кушымчасын куеп әйтү: *Мин қырық беренце йылнықы* (елгы). *Минеке әби белән бабай 1887 йылнықы* (елгы) *берсе. 1931 елнықы* (елгы) *мин булған.*

## Лексик үзенчәлекләр

***Затларны белдерә тогрган сүзләр:*** *баба* – авыл бабайлары, *баба/бабау* – дәү әти, *мамай* – әби, карчык, *мама/мамау* – дәү әни, *нәнәм/нәнә/инәй/инә* – әни, *тәтә/тәтәм/эттә/ата* – әти, *күкәм/күкәләр* – энем, сеңлем, *аба/абам* – апа, *әкә* – абый, *инә/әни* – ирнең әнисенә дәшү, *ата/әти* – ирнең әтисенә, *кендегәц әби* – кендек әби.

***Тормыш-көнкүреш белән бәйле сүзләр:*** *тора* – шәһәр, *йаташту/йаташлы йорт* – катлы (этажлы) йорт, *сарай* – ишегалды, ябык йорт алды, *аран* – сарай, *синек* – ишегалды, веранда, *көпкә* – кечкенә җылы абзар (тавыклар, бозау асрар өчен), *кәзүнкә/кәзүңке* – чолан, *кәтәк* – кетәк (рус. курятник), *әцәлдек* – туалет, *басмақ* – күперчек, *пиц* – мич, *кәцәк* – тәрәзә кырые (эчке яктан), *терәстү* – тәрәзәләр, *чанақ* – кечкенә чана, *табатан* – таба, *шимовка/чимовка/цимовка* – күмер ала торган соскыч, *келүкә/қыйчауғач/кәкре тимер* – кисәү агачы (кочерга), *цумец* – чүмеч, *сућма* – киле, *сәкәлүк/цәкәлүк/ықлау* – уклау (рус. скалка), *туқмақ* – төйгеч, *типшә* – он иләр өчен агач савыт, *түбә* – түшәм, *цәй тәринкәсе* – чынаяк тәлинкәсе, *шама* – чәй чүбе (рус. остатки заваренного чая, чаинки), *шәрәмнек* – сукыр

лампа, *өстәл* – урындык, *зур өстәл* – өстәл, *себерке* – миллек, *тырмаwыц* – тырма, *могол* – чүмәлә.

***Кием-салым, чүпрәк-чапрак:*** *пима* – киез итек, *сырға* – алка, *қуштақлы итәк* – бала итәкле, *мәрцән* – мәрҗән, *кибәц* – кәпәч, түбәтәй, *байбақ* – оек, *тағыйа* – бүрек, *қоршау* – тәрәзә пәрдәләре, *күчәгә* – чаршау, *йастық* – мендәр, *фәрдә* – пәрдә.

***Аш-су:*** *қазы* – казылык, *күч/күшт* – ит, *чегелдәк* – бавырсак, *туач* – паштет, *лүпсә* – киптереп төелгән шомырт, яисә шуңа шикәр кушылып ясалган ашамлык, *бәдер* – черек бәрәңге күмәче, *хәлвә* – камырын токмач рәвешендә кисеп ясалган чәкчәк.

***Терек һәм терек булмаган табигать:*** *боға* – үгез, *кәзә* – кәҗә, *песи/мыжық* – мәче, *көцек* – эт, *қуй/мәшкә* – сарык, *әтәц* – әтәч, *цебен* – черки, *майған* – үрдәк, *цыцқан* – тычкан, *цалца* – талпан, *утрац* – утрау, *эт борны* – гөлҗимеш, *күгәмәй* – кара җиләк, *күк йеләк* – кара бөрлегән, *қарлыған/қарағат* – карлыган, *малан* – балан, *таш* – төш (рус. косточка), *күбергән* – кыр суганы, *ләпләк* – чөгендер, *қы(з)цылца* – кызыл чөгендер, *мәшкә/ мишкә* – гөмбә, *пыяс* – суган, *мәркүп* – кишер.

***Эш-хәрәкәтне белдерә торган һ.б. сүзләр:*** *йетешегес* – ашагыз, *йыштырғалы* – җыярга, *әкиләләр* – алып киләләр, *қырсый* – кисә, *тиргәү* – җыю, әзерләү, бизәү (мәсәлән, бирнә әзерләү, йортны кирәкле әйберләр белән бизәү), *қурқыған* – курыккан, *туған* – тудырган, *йаман* – начар, *төнен* – төнлә.

Себер татарларының фонетик, грамматик, лексик үзенчәлекләре һәм аларга хас булган гореф-гадәт, йола һ.б.лар сөйләү үрнәкләрендә аеруча тәэсирле яңгырый. Җирле халыктан тупланган материалның (сөйләү үрнәкләре) беренче яртысында әүштә-чат сөйләшендәгечә язылса, икенче яртысында мишәр диалекты сөйләшләрендәгечә (бигрәк тә сергач сөйләше) бирелгән. Текстларда сүзләрнең әйтелеше транскрипциядә бирелә. *Я, ю, е* хәрефләре урынына [йа], [йә], [йу], [йы], [йы], [йе] авазлары, өстәмә билгеләрдән [w] – ирен-ирен өрелмәле тартык аваз һәм [қ], [ғ] – тирән тел арты тартык авазлары кулланылды. Кыскартылмалар: *әд.* – әдәби, *рус.* – русча, *һ.б.* – һәм башкалар.

ЭКСПЕДИЦИЯ ВАКЫТЫНДА ӘҮШТӘ-ЧАТ, КАЛМАК СӨЙЛӘШЕ ВӘКИЛЛӘРЕННӘН ЯЗЫП АЛЫНГАН, ХАЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕН ЧАГЫЛДЫРГАН МАТЕРИАЛЛАР (СӨЙЛӘҮ ҮРНӘКЛӘРЕ)

## Авыллар тарихыннан

***Умавыл/Омайыл (Барабинка) авылы.*** Мен Омаил торысында силәгәле итәм (әд. *сөйләргә телим*). Орысца ул Барабинка, ә татарца – Омаил (Умавыл) дип аталадый. Аилның (*авылның*) исеме Ом-судан цыққантыр, ул порон заманнан су буйында торадый. Ом-су Том-суға Қафтан аилдан йырақта төгел ағып батай (*төшә*). Омаил бек поронғы аил. Аны 1575 йылда Пономаревтарың (муәзин ул булған) бабайларнықы бабайлары баштаған дип әйтәдийләр. Анықы (*аның*) тоқомнары аилда бестеке заманға қәдәр торадыйлар. «Йарти Омаил – Пономаревтар, йарти – Абанейлар», – дип келеп әйтеп қуйабыс. Цыннап, Абанейлар, дересцә Абаниевтар, көптән бестеке аилда йәшидиләр, йедебә-сигеспә бойын санап цығарасың. Алардан башқа аилда көп (*күп*) «килгән кешеләр»: Измайловтар, Қамаловтар, Сайдашевтар Қазан йақтан (*ягыннан*), «тоболоқтар» Абанейлар, Орта Азийадан – Хайровтар, аннан соң Муксуновтар Томаулдан (*авыл исеме*), Айбаттар, Сайфамлүковтар. Бик көп Үтәгәновтар, Мамашевтар һәм башқалар. Аилдағы йорттар бетеннәй электән үқ ағацтан салынғаннар. «Тора (*Томск шәһәре*) булбаған әле, ә бестеке Омаил булған», – андый бабайлар бескә сөйлидиләр. XX ғасырнықы башында, Омаил бек зор, йәмнү (*зур, ямьле*) аил болған: ике йаташту (*катлы*) йорттар, зор матур терәсту (*тәрәзәле*), йалт иткән тимердән өй баштары – бай аил! 1929 йылдан соң аилыбыс йарлу булды. «Раскулачивание», «саботаж», «колхоз», «сослать» – йаңы сөстәр (*сүзләр*), йаңы кежеләр (*кешеләр*), йаңы рәистәр аилыбысты йелгә тараттылар. Мәцетте йаптылар. Мәцеттеке қәләмнәренә (*келәмнәрен*), циккән кийестәренә, паластарны, қораннәрнә арбаларға тийәп исполкомга әкиттеләр. Аил өскәрде (*үзгәрде*). Хәзер аилда көп орыстар, цит илләрдән килгән кешеләр торадыйлар (*торалар*). Аилда йеде урам: ике урам – Советская, Береговая «Иске Омаилда»,

биш урам – «Йаңы Омаилда» – «монолиткада». Бәребер минеке аилым иң матур, йәмлү, йанға, күскә (*күзгә*) сикемнү (*сөйкемле*). Табиғатебес әле бай – урманнар, болоннар, колләр (*күлләр*), цишмәләр, терлү цыпцықтар һәм қоштар қоандырайлар (*куандыралар*) халықты. Омаилда хәзер мәктәп, клуб йоқ, бар бер кибет. Балалар да әзәйде. Алар Қафтанға (*авыл исеме*) уқығалы беренце класстан уқ тоғызынцыға йә онберенцегә қәдәр йеридиләр.

*Сөйләүчеләр: Абанеева Әминә.*
*Умавыл.*
*Әбдрәшитова Зөмәрә Минһаҗ кызы (1936 елгы).*
*Кызылкаш авылы*

***Абытай (Черная речка) авылы.*** Мин Аудайылнықымын (*авыл исеме),* Абытай тип тә әйтәйләр. Ул цақта бестең аwылда үзебестең халық қына торадаған. Урыстар булбыйдаған. Бес урысца сөләшә (әд. *сөйләшә*) дә пелбәй идек. Бақца утыртпый идек. Аттар күп тотай иде атамнар. Йәйен пецән цабай иделәр. Қышын ул пецәнне тораға (*шәһәргә*) алпарып сатадағаннар. Қацан-қацан урыстар килеп аwылдағы ирләрне обосқа йаллыйлар иде. Өркеткә (*Иркутскка*), Нарыймға обостар аwылдан үткәндә, қарлар шығыр-шығыр итеп торадаған. Қыштар ул цақта бик суақ булай иде. Айаққа кигәле пималар (*киез итекләр*) барыбысқа да йетпәгәц, өйдә сәкедә генә утырып ашық уйныйдағанбыс. Ноғыт таш булай даған. Аларны сикертеп бер қулға сәкедәге ноғытты алып өлгәргәле кирәк. Бик қызық уйын ул. Кицен, кәрәсин лампасы байырақтарда ғына булғац, бес шәрәмнек (*сукыр лампа*) йақтысында, йә тимер пиц йақтысында йыйылышып, қурқыныц хикәйәләр сөйлидәгәнбес.

*Сөйләүче: Әбдрәшитова Зөмәрә*
*Минһаҗ кызы (1936 елгы).*
*Кызылкаш авылы*[1]

---

[1] З.М. Әбдрәшитова Абытай авылында туып-үскән Сәйфәмлюкова Әсхәпҗамал (1903 елгы) хатирәсен җиткерде.

***Калтай авылы.*** Бу аwылға 1964 йылны килдем. Мин Башкортостанның Дәүләкән районы Чуенчы дигән татар аwылыннан килен булып төштөм. Ике улым, бер қызым бар. Сыйыр саwычы булып эшләдем. Иртән китәм, кичен кайтам. Мин килгән йылны, 62 йылны, йартысы Ленин йулы колхоз иде. Йартысы урыс. Бүленгән иде. Матур иде Қалтай. Әби-бабайлар бар иде, йәш′ләр. Әле 85 йәш Калтайга. Монда бөтөнесе дә килгән қалық (*халык*). Суғыш wақытында да.

Сөләүләр буйынча, Қалтай теге очта булған, өченчегәме күчкән ул. Монда безнең ферма иде. Молоканка бар иде – сөт кабул итү, сепарат чығару урыны. Урманға, покоска йөрөдек. Печән чаптық. Калмакский утрачы (*утрау*) йанында су бар. Күл бар иде, беткән дә инде. Ғыйляҗев күле бар монда, анда Ғыйляҗев Ғәзиз абый тора иде. Светлый дигән бар. Ум бар – ул Барабинка (*авыл исеме*) йылғасы, зур түгел генә. Томның протогы дип атала. Утрачта бер күл бар. Аны Төпсез күл диләр иде. Аннан без баланға бара идек.

*Сөйләүче: Фәхретдинова Рәйхана*
*Фәйзрахман кызы (1938 елгы).*
*Калтай авылы*

***Туктамыш/ Тахтамыш*** (легенда). Борон заманда бестең бабаларыбыс йырақ йерләрдән күцкилгәннәр (әд. *күчеп килгәннәр*). Йахшы йерләр эстәгәннәр (*эзләгәннәр*). Анда-монда туқтап қарағаннар. Ошаған урын таппағаннар. Ту йере йәмсес, ту суы тәмсес булған. Зур, киң сулар буйлап та барғаннар, күлләрне дә үткәннәр. Бара торғац, бер матур урынға кил′еткәннәр. Бер йақта зур су ағай (*ага*) икән, аңа чип-чиста кецкенәрәк суның тамағы төшәй икән. Шул кецкенә суға Ауды дип исем биргәннәр дә, аның тамағыннан үргә киткәннәр. Бик матур, бийек йарлу урынға килеп йеткәц, шунда туқтағаннар. Су буйлап йеләктәре пешкән шоморттар, қызарған эт борно (*гөлҗимеш*) үсәй икән. Суы бик циста да, тәмнү (*тәмле*) дә икән. Бийек йардан тирейақтар ап-ацық күренторай икән. Бестең татарлар белән қала урысы килгән булған. Ул сораған: «Где дома будете ставить?».

Болар әйткәннәр: «Бу йердә туқтамышбыс». Шуннан урыс қала башлығына «Юрты Туктамышевы (Тахтамышевы)» дип йасқан. Бу аwылның исеме булқалған (*булып калган*).

*Сөйләүче: Әбдрәшитова Зөмәрә*
*Минһаҗ кызы (1936 елгы).*
*Кызылкаш авылы*

***Умавыл/Омайыл (Барабинка) авылы.*** Теге йақтан, Булгарийа йақтан килгәндә тегүцеләре килгән. Икеме-өцме семйа ғына килгән. Чуқындырғаннан қацып килгәннәр беснеңке (әд. *безнең*) Умавылға. Скрипачи килгәннәр. Бай кешеләре килгән: Сөләймановлар, Исмәғыйлевлар... Анан инде Сөләймановлар Понамаревка әйләнгән. Мәзем булып эшләгән мәчеттә. Исмәғыйлевлар Измайловка әйләнгән. Урыслар әйләндергәннәр. Аннан инде қушылғаннар. Қурчақлар килгән. Қурчақ уйнауцылар менә Барабинскийда. Цепрәктән матур қурчақлар йасап уйнағаннар. Башта чучелодан, ағацтан йасауцылар булған. Монда килбәгәннәр алар. Мәчет салғанар. Тахтамышта булған оноғы, Чиңгизханның оноғын озатқан. Тыңнамаған күрәсең. Йасақ түләгәннәр мондағылар Тахтамышқа. Тахтамыш ханы булған. Мангуллар нимәгә (*нәрсәгә*) табынғаннар. Чучело йасағаннар. Безнеңкеләр қушыла башлағаннар алар менән. 605 йыл аларға. Безгә дә еде йөзме йыл, Умавылға.

Безнекеләр килгәндә алар матур бүрәнәлү йорттар салғаннар. Алар зоны йердән килгән. Ә болар йурты булған. Шул Тахтамыш ханнары. Ә тегеләр инде йорт салғанар тиз генә. Монда барып, Тахтамышқа қаршы урнашқан булғаннар. Костерлар-ниләр, монда матур йер. Мәчет, Том (*елга*) күренә матур йердән – йарда – бийек йердә. Цүпләр, әллә ниләр чүбәннәргә атып-атып киткәннәр. Болар булған инде. Болар монда йеннәр икән дип, тегендә киткәннәр, Умавылға түбәндәрәк. Скрипачлар, музыкантлар, тегүчеләр булған. Орыслар (*урыслар*) соңрақ килгән. Килә-килә килеп йеткәннәр монда. Мәскәүдән, Қазан йақтан килгәннәр. Матур қалық (*халык*) булған безнеңкеләр. Зәңгәр күслү (*күзле*), бийек. Ә болар өләнешкәннәр, Томныңқы теге йағында инде

Кемеревский област′тән. Берсе инде қалмақлар. Алар да төркөй ғуй (*төрки бит*). Берас йәшелрәк күслү. Рыжоватый. Матур төгелләр. Алар бер-берсе белән қушылғаннар. Ә черкеслар матурлар. Минең бабамныңқы хатыны үлгән. Ул аны алған. Өләнгән. Шул черкесларныңы. Шул токомға мин киткәнмен.

*Сөйләүче: Әгъләмова Шәрфук*
*Рәҗәп кызы (1933 елгы).*
*Умавыл*

***Казан авылы (Казанка).*** Аwылда хәзер дачниклар. Өц урам. Артта дөртенчесе – йаңы урам. Пестеке Садоwайа, ал (әд. *алгы*) урамныңы – Берегоwайа. Пестеке йартысы урысца, йартысы – татарца. Хәзер монда йартысы орыс (*урыс*). Суғыштан соң, Томскийныңылар алар орыслар. Элек дачалар йуқ иде. Пестең аwыл зор төгел. Қандый (*ничек*) булған, шундый инде. Қалароwаға (*авыл исеме*) хадәр дачниқтар. Ғызылғаш, Умавыл, Қалтай – татар аwыллары. Анан ар (*ары*) урыс аwыллары. Әнийем Тумаwылдан (рус. Константиновкадан) килде. Атам мондағы. Бес – себерәктәр. Минеңке бабайымныңы туғаннары килгән. Алар йүргә йақныңы (*ягыннан*), Йүргәдән. Аларны сорап урыннарын алғаннар. Лагер ачқаннар анда. Йүргә ул Тайғадан ары.

Суғыш башланғанда миңә (*миңа*) унйеде йәш булған. Әнә уннан тотонғаннар песте қуғалы эшкә. Қайа ғына қумадағаннар песте. Аwылда ферма бар иде, зор (*зур*) иде. Урманнан қайтмадық, ағац кистерделәр, лесзаготовка. Тум (*елга исеме*) аша йәйәү (*җәяу*) барабыс, йәйәү қайтабыс. Қайтып ике генә көн булмайбыс, бесте тағын қуалар. Без 15 йәшлү қыс палалары. Қалтайдан, аннан урыс аwылыннан урманға кереп китәдәгәнбес эцкә, заготовкаға.

Узбәк, қырғыз, қазах эшкә киләләр, килеп эшләйттәр. Көтүцебес бестнеңке – қазах. Башта қырғыз көткәле (*көтә*) иде. Хәзер кибет тә йуқ, халық та йуқ. Дачниклар йәйен генә торай (*тора*), қыжын (*кышын*) алар китеп қалалар.

*Сөйләүче: Гобәйдуллина Гашурә*
*Исмәгыйль кызы (1928). Казан авылы*

***Кызылкаш авылы.*** Қаш – калку урын (рус. возвышенность). Төс түгел, матур булғанға – қызыл. XVI ғасырның 1 нче йартысында барлыққа килгән. 1500 дә ничәнче йыллар була инде. Казаковларның шәҗәрәсен уқыған wақытны, анда шулай дип әйтеп йазғаннар. Мәскәү тракты буйлап қазақлар анда торғаннар. Азықтарын сақлыйдаған урыннарын барлыққа китергәле тийеш булғаннар. Холотник дип әйтәй торған идек. Менә сез монда килгән wақытта Черная Речканы үттегес. Ауды аwыл и Абытай дип тә әйткәле инде бес аны. Аны беснеңке себерәктәр шулай дип әйткәндер инде. Но бу йылғаның исеме Ауды. Ул ағачлар ауды микән инде. Ул йақта хутор кебек бер урын бар. Күпер. Ул йағында уйсулық. Менә шуннан өстә, бийегрәк урында. Қышын қарлар салып, йазын бозлар салып, менә шунда ағызып сақлыйдаған (*саклый торган*) өлөш. Ул йерләрне саттылар. Қазақлар сақчылар булғанда Казаковлар менә шуннан соң аwыл үсә башлаған. Шулай итеп сөйләйләр. Патша армисендә хезмәт иткән солдат күп пулған. Монда йәшәгән халықны инородецы дип әйткәннәр. Инородецларны армыйаға албағаннар. Минең әтийемнеңке әтисе Қазан губернийасының Саба йақларыннан булса кирәк дип әйтәйләр. Ә без урысча сөйлибез хәсер. Хәсер монда килгән халық. Менә минем әнийем йақтан да әтийем йақтан да җемтөп себерәкләрдән беркем дә йуқ. Алар инде аралашып беткән бестең туған тумачалар. Шуңа күрә сөйләмдә дә себерәк сүстәре дә, қырғыз сүстәре дә бар. Мәктәп салып уқыта башлағац, Татарийадан килгән уқытучылар менә шул әдәби телдә өйрәтә башлағаннардыр. Минем апам 1943 йылны бетергән иде ул Томскидағы татар педучилище дип әйтеп. Татарский педучилище булган 1925–56 йыллардама. Бу аwылда татар теле берас уқытылды. 1990 йылдан 2000 йылларға қәдәр. Бер ун йыл тирәсе. Педучилище бетергән менә без уқыттық та инде.

*Сөйләүче: Әбдрәшитова Зөмәрә*
*Минһаҗ кызы (1936 елгы).*
*Кызылкаш авылы*

***Яңавыл (Березовая Речка).*** Йаңаwылға күбрәге Татарстанның Саба районыннан килгәннәр. Ике бабай да Қазан йақтан (*ягыннан*) килгән. Менә минеке (*минеӊ*) әбейләр килгән Қазақлар дигән аwыл булған. Анан Тәкәнеш дигән аwылдан. Менә Биби әбиләр иде. Хасановлар Мәтәскә дигән аwылдан. Алар революцийәгә қәдәр килгәннәр. Бабайның абыйсы моннан суғышқа киткән 1914 йылны. Олы Шомар дигән аwылдан. Сәғыйт бабай. Неграмотный сем′йа булған.

Урманчылық менән шөғылләндем, ағачлар утырттық. Йәнәшә Кирәк аwылы. Аwыл тирәли 13 заимка булған. Килгәннәр дә утырғаннар урыслар. Килгәннәр анда қайа биш кеше, қайа ун кеше. Шулай қалғаннар тороп. Аwыл йанында Қазанцево заимка (*заимкасы*). Белоруслар булған и пол′аклар. Бәрхет менә донской қазақ булған ул. Қачып йатқан. Заимка Йакимово (*Якимово заимкасын*) күңел ачу өчөн салған. Алар байлар булған Томскида. Аннан сыйырлар тотқан, рабочийлары, кибетләре булған. Малиновский булған аның артында. Бәрхет (*заимка*) – қазах булған, қачып йәшәгән, мал тотқан. Йасап май сатқаннар урысларға тегендә. 25 чақрым бездән Об′ (*елга исеме*) бит. 1885 йылда заимка салынған. 5–6 йыл торып Қазанкаға барғаннар. Кривошечный, Куз′мины, Нижные Озера дигән заимкалар да бар. Атамалары хуҗаларының фамилийәләре буйынча әйтелә. Алар алышынғаннар. 20 йылдан йаңалар килгәннәр и икенче исемнәр. Дубровинада киржаклар иде. Алышынды.

Березова Речка йанында Муса йылғасы, ике тау арасында. Йырақ күл, Зур күл бар. Сара әби йорты йанында күл. Аwыл йанғыннан соң барлыкка килгән. Кедрач булған. Аучылар йандырғаннар. Шунда килгән татарлар. Анда кыругом урыс басып алған булған. Боларның печәнлекләре дә – бернәстә булмаған. Бишмәт кийем теккәннәр урысларға. Урысқа эшләп йөргәннәр. Аннан қышын Могильникқа (*авыл исеме*) барып, печән сатып аладағаннар. Кругом аwыл булғач, болар соңғыдан ғына аwылны төзегәннәр. Шуңа Йаңаwыл.

Башта урыс аwылы булған ул Кирәк, анда киржаклар торған. Татарлар киләй. Аннан әкрен генә урыслар ычқынғаннар аннан.

Киржаклар – старообрядцы. Тәмәке тартмый, араqы эчми алар, сүгешмиләр. Бездә аларның чиркәүләре дә бар. Алар әле дә бар. Алар элекке колхозға да кермичә қачқаннар. Безгә бер киржағы креп йөрәй иде. Үзенең кашығы, крушкасы беләң. Кешене ашатмыйлар, үзләре шуннан ғына ашыйлар иде. Керсәң аларға, аларның посуда айырым иде. Қышын катып үләсең, өйөнә кертмәйләр. Бездә бар қушамат: кеше кире (*рус. упрямый*) икән, «киржак» дийәйләр иде. Алар айырым торғаннар.

Революцийәгә қәдәр йарты аwыл қарақ булған Йаңаwылда. Алар ғаиләләре беләң Барнаул йаққа киткәннәр. Ат җигеп утыртып бара икән хатыннарын, сандықларын. «Куда едете?» дип сорасалар, «В Барнаул» дигәннәр. Цыптыралар берәр табунны анда. Ул wақытта крест′аннар, атлар күп булған. Ирләре ат алып қача, хатыннары боролып йаңадан қайта. Анда Воронин йақтан (*ягыннан*) килеп урлағаннар. Йаңаwылға килеп алыштырганнар алар мондағы атны, тегеләре теге. Бу 1920 йылларда. Йулда қайберләре урлағаннар. Аwылға килеп қыйнағаннар қарақларны, сел′советтан килеп.

*Сөйләүче: Фәхретдинов Сәйфулла*
*Сабит улы (1950 елгы).*
*Яңавыл*

***Кызылкаш (Тахтамышево) авылы.*** Мин Қызыл Қашта торам. Бестең аwыл бик матур урсында салынған. Бер йақта Тум – зур су, ә икенце йақта бәләкәй Ауды (*елга исемнәре*). Өйебес озон күл йанында торай. Йазын күлдәгә (әд. *күлдәге*) су ишек алдына қәдәр керәй (*керә*). Басмақтар (*күперчек*) салабыс йөргәле (*йөрергә*). Өй тәрәсеннән трак күренәй. Мамам (*дәү әни*) тәрәс төбендә машиналар үткәнен озақ қарап утырай. Йәйен ишек алдыбыста йәшел үләннәр үсәй. Су цумғалы Аудыға төшәбес, йә Тумға барабыс. Көс (*көз*) килсә, мишкәгә йөрибес. Мин мишкә (*гөмбә*) йыштырғалы (*җыярга*) йаратам. Қалаға аппарып та сатабыс, үзебес тә ашайбыс, қунақтарға да бирәбес. Бескә йәйен қунақтар көп (*күп*) киләй. Матур йер дийәйләр. Минең күкәләрем (*эне-сеңелләрем*) дә урманға йөрәйләр, тол′ко хәзер

цалца (*талпан*) көп, қурқып қына, кийенеп йөрибес. Ну көзөн цалца булбый, ә урманда чиста, матур урыннар күп. Әле мамам күгемәйгә (*кара җиләк*) дә аппарған иде. Үткән йәйне күп шоморт йыйдық. Шоморт бик уңған иде. Мамам шоморттан лүпсә (*киптереп төелгән шомырт*) йасай. Қыжын (*кышын*) лүпсәдән пирошкилар пешерәй. Мамамның пирошкилары гел тәмне булай. Қыжын мәктәпкә йөргәле (*йөрергә*) йырақ. Буран булса, бигрәк тә йаман (*начар*): қар тирән, сүктәп бара-бара хәл бетәй. Шкулда шәп, йылу, йақту. Анда уйнағалы да булай. Бестең аwылда торғалы әйбәт.

*Сөйләүче: Әбдрәшитова Зөмәрә*
*Минһаҗ кызы (1936 елгы).*
*Кызылкаш авылы*[1].

## Тормыш-көнкүреш турында

Элек төз-цәй, шикәр сорап йөридәгәннәр күршеләргә. Хәзер йомошқа йөрү йуқ. Хәзер бигрәк тә йеңел, йәштәргә рай. Афтобус киләй, утырап китәй. Қайтып төшәй өйөнә. Элек қалаға эшкә йәйәү йөредек. Көйәнтә менән сөт ташый итек. Сатадаған (әд. *сата торган*) әйбереңне апарасың. Палық апара итек. Сөт, кем бәрәңге апарадағын, ике циләген қойып. Нийе бар сатқалы (*сатарга*) – апара иде. Нижнийга қәдәр ике цақырым. Нижнийдан соң тағын қалаға қәдәр. Биш цақырым була инде. Батқыцты (*баскычны, күперне*) тағын менгеле әле. Туқсан бацқыцларын санағаидем, менгәндә. Тумнан (*елга исеме*) суны ташыйдағанбыс. Элек хайwаннарға былай-былай тишәйләр иде. Осон (*озын*) итеп. Ә үсепескә эцкәле (*эчәргә*) берас циттәрәк буладағын, ағымнықы быйағындарақ инде. Циләк менән йөгөреп-йөгөреп су ташыйдағанбыс йәйен дә қышын да. Хәзер инде қазыдылар бит. Йазын үсебестә су киләй башласа, йөрик тибес қайа малларны апчыққалы дийеп. Бестә бит су басырай (*баса*).

---

[1] З.М. Әбдрәшитова үзендә сакланган бер истәлекне укып күрсәтте.

Бақцаны басты. Быйыл су зур, соңғы су булды. Баштағы су бик булмады, бос менән.

*Сөйләүче: Сәйфетдинова Мөнирә*
*Мифтахетдин кызы (1925 елгы).*
*Әүштә авылы*

Мин йеде классты бетергәндә суғыш башталды (әд. *башланды*). Инәм (*әнием*) олу (*олы*) йәштә иде инде ғуй. Атам (*әтием*) үгәй. Ул колхос фермасында қараwылцы иде. Мине дә фермаға учетчик итеп эшкә алдылар. Сыйырлар йәй пуйы утрацта (*уртау*) торайлар иде. Сөтте битоннар менән көймәдә Тум аша цығарып, ат арбасына төйәгәле (*төяргә*) туры киләй иде. Аннан шул сөтте маслобойға аппарабыс. Утыс-қырық литрлык битоннарны үсебес арбаға күтәреп төйәйбес. Арбадан төшөреп маслобойга керетәбес. Иртәге биштән кицке унға қәдәр эшти идек. Түләү булбый иде. Эшкә цыққан көннө қағаска сысық сысқуйа (*сызык сызып куя*) торғаннар. Бу трудоден′ иде. Шуңа эштәдек, сысыққа.

*Сөйләүче: Назмутдинова Кәүсәр.*
*Кызылкаш авылы*

Монда унйиеде йәшемтә килделәр урлап. Урлама килделәр. Мин Тахтамышеwадан килен булып төштөм. Әтисе-инәсе йуқ, йеңгәсендә үскән малайға. Калхуста 12 йәшемтән эштәттеләр. Әтийем, әкәм (*абыем*) служит итәйе. Аларға йәрдәм иткәле тип. Wәт эштәгән биш йыл. Ни генә эштәмәдек. Урақ та урдық, молотилкада да пулдық. Қыжын (*кышын*) маллар йанында да. Тел′атник қуйадағаннар. Анандый эшти-эшти, эштәдем әлегә қәдәр. Ул калхуста эштәгән. Төнгөсенә китерәйләр: «Синең икәү фронтовиғың, даwай в′азай» дип. Фронтовикларға дип бәйлидәгәнбес бийәлий, наски. Мине инәм (*әнием*) берқайа йебәрмәде уйнағалы клупқа. Бәйлидәгәнбес. Ә икенце көнне бит эшкә барғалы кирәк тағы. Таң атуға.

Бақцада қыйарлар үстергәле (*үстерергә*) мине йөрөттеләр. Қуйларның (*сарыкларның*) йөнөн алғалы булса, мине килеп ақитәйләр. Син остасың дип. Анандый йөрөттеләр. Өцәр сутый ашлыққа йер қазыйдағынбыс көнөнә. Бәрәңгегә қазыйдағанбыс.

Көзен урасын утытқан ашлығыңны. Эштәмәгән эш қалмады. Торф иттерәдәгәннәр бушырақ wақытың булса. Парахутларға йаққалы. Пален кирпец дип аны кисәдәгәнбес. Ике мең сигес йөс кирпец ике кешегә. Кирпецең алтмыш ыштук өйәсең дә, тачка менән болотадан апцығасың.

*Сөйләүче: Сәйфетдинова Мөнирә*
*Мифтахетдин кызы (1925 елгы).*
*Әүштә авылы*

Умавылда чатлар торған. Әти-әнийем Умавылдан. Монда күл булған. Күл киткән. Бөктә (*урман/болын*) тегендәрәк өц күл. Түгәрәк күл – ул бик тирән, түгәрәк. Аны күл дип кенә йөртәләр. Чербашка күле – озон күл. Тот күле – ул да озон күл. Мәцет бар. Муллабыс Қазанка дигән аwылдан. Аwылда ике урам. Иске аwыл – бу иске Барабинка. Йаңасы – Барабинка. Тумавыл дигән аwыл бар (русчасы: Константиновка Кемеровский область), моннан 40–50 км.

Аwылны цыққац тегендә бөк (*урман*) инде андый. Бу йақта урман – йалан, теге йакта урман бөк дип әйтелә. Түгәрәк күл йанында дачалар. Тум ташса йасын (*язын*), аларны батырай. Аwылны батырған иде ғуй, суғыш башланған йылны. Тағын бер өц йылны булды су. Черная Речканы батырды Тум суы. Элек зур фермалар иде, маллар торадаған. Мал, суғым суйған хардәшләрең килеп булыша иде суйышқалы. Йылы wақыт булса, йылғада йуа идек эцәкләрен. Хәзер ашамыйлар эцәкләрен.

Элек мәктәп дүрткә хадәр бар иде. Йаптылар. Биг элек укыттылар (татар телен). Без уқығанда татар иде, татарца уқыдық. Кафтан – рус аwылы. Кафтанга йөрим. Урысца белмим. Эй уқыйсым киләй. Сөйләшәй беләм берас. Но уқығанны сөйләй белмим. «Анда уқый алмыйм. Қалага барам», дим. «Анда баргалы иртә сиңә», ди. Монда уқыдым. Безнең аwылда тоже урыслар татарца уқыдылар. Тумавылдағы қалмақларның телләре дә, йөзләре дә айырылай. Без чатлар. Қалмақлар Тумавылда.

*Сөйләүче: Мөхәммәтшина Фәүзия*
*Сәйфи кызы (1930 елгы).*
*Умавыл*

Мин Йаңаwылдан (рус. Березовая Речкадан). Бабамныкы бабалары Лаиш районы, Қазаклар дигән аwылдан. Алар монда килгәнннәр и беснеңке аwылны барлыққа китергәннәр. Бу тайга уртасында йылға булған, родник суwақ (*суык*). Минеке әби белән бабай 1887 йылныкы берсе. Хәсән бабай белән Мәмдуха әби өйләнешәләр. Алар революцийәгә қәдәр килгәннәр. Томскийдан 75 км шул аwылға барганнар. Килгәц қарабодай, иген чәчкәннәр. Әбинең қарабодай келәте бар иде. Мин үскәндә қарабодайлар йуқ иде инде. Суғышқа бабай пиш паласын қалдырып киткәц, йаңа өйгә күцкәннәр. Аwылда йортты Қасандағы кебек салғаннар. Печка и қазан эчкә кертелеп қуйылған. Бестең бүлмәдә бар иде. Аннан килгән ул андый бүлем анда, йәйен йөрәй итек. Хәдийәба йахшы беләй. Безнеңке әни Кирәкнеке, эти – Йаңаулныкы.

Кирәк – аларныкы анда күл. Родниклары бик тә кецкенә инде анда. Менә бу аwыллар: Барабинка, Черна Речка – алар чурныйлар. Ә без рыжийлар. Ә Кирәктә мишәрләр. Тирән йылга – тирән булғанға.

Бездә заимкалар булған: Бәрхет, Заимка (*исемсез*) һ.б. 3 км бестең аwылдан. Заимка – анда болоннар. Бәрхет – ул урыслардан қалған ул. Безнекеләр килгәндә руслар булған дип сөйләмәйделәр. Симаков заимкасы. Анда кедрачлар үсәй. Йакимов, Қазақ заимкалары. Аларның даже зиратлары да бар ите. Қазақ заимкасында Томскийлар булған. Әби Қазактан, Лаишевский районның. Қазақлар берқайа да булмаған. Қазақ заимкасы урысларныкы бит ул, татарларға қатнашы йуқ. Никита заимка. Ә татарларныкы кеше исемнәре генә.

Йылға бер генә. Без аны йылға ғына дийәй идек. Пецән цабадаған йер – Лугин, әпәт заимка. Бәләкәй күл йәйен кибә иде. Йырақ күл бар тағын.

Берницә семйа килгәннәр. Земл'аклар да бар иде. Төп фамилийәләр: Хабибуллиннар, Гайнетдиновлар, Фахрудтиновлар, Валитовлар, Әбдрәшитовлар (ә Сафиннар земляк қына).

*Сөйләүче: Латыйпова Фәйрүзә*
*Ягъфәр кызы (1955 елгы).*
*Яңавыл*

Минеке қыз фамилийәм Бикулова иде, хәсер фамилийәм Әмирханова. Әмирханов Қазаннан килгән бабайым булған. Мин Ғалиәскар қызы. Галиәскарның атасы Қазанныкылар (*ягъни Татарстаннан*). Галиәскарның атасы Тухтамыш Әхтәмович.

Бу аwылда туылып (әд. *туып*), монда үстем. 1941 йылда 13 йәш. Суғыш башланды, эшләгәле (*эшләргә*) қуштылар. 1946 йылда заготовкада суғыштан қайтқан ирләр менән. Безнеңке әтийебес суғышта қалды, қайтбады. Бес алту (*алты*) бала, мин воспитат′ итттем әкәм менән икебес. Әбийем дә исән иде әле. Эшләттеләр дә эшләттеләр.

Мин кийәүгә бардым. Минем ирем Байазитов. Бала тудым (*тудырдым*), сем′асын қарадым, йәйәү сөт ташып. Мин пер пала (*бала*) менән икенце палам, икене тудым (*таптым*) Байазитовтан. Ә бу инде алар Кемеровский област′тә Юрт Константиновкада тордылар. Алар берwахытта сосланный булғаннар бит. Монда тимәсеннәр тип, күлнең теге йағына цығабыс тип қазанныкылар килгәннәр дә анда торғаннар. Анда тороп, Қызыл Қашка килеп, өйләнә менә бу иремнең әнисенә. Алар Қазаннан килгән булғаннар. Төп қазанныкылар. Аныкы (*аның*) бабасы менә быйыл ғына үлде. 93 йәшендә Қазанда үлде. Вәлүттекен (*Вәлитнекен*) әйтәм. Қазаннан бит алар. Аталары Әмирханов Әбзәл булған.

Әбийем пик уқымышлу ите. Ғыйлмимаға керәбес дә, ул 12 сәғәттән ике сәғәтка қәдәр йомға көнне йуашкалы (*юарға*) йарамый, мондый эште эшләгәле (*эшләргә*) йарый дийә ите. Уйнап-көлеп аның йанында утырып безгә уқыйдаған ите. Миңә (*миңа*) ул wақытта недо этого (мин дә укығалы өйрәнгән булыр идем). Алты пала қарадағанмын. Ун йыл аwырады әкәм (*абыем*). Өч-алты аwылға собранйа йасап йөрдем. Трижды депутат булдым. Сыйыр саудым, передаwайа идем. Депутат звеновой бултым савхуста.

*Сөйләүче: Әмирханова Гафифә*
*Галиәскар кызы (1928 елгы).*
*Кызылкаш авылы*

Монда 1954 йылны килдем, кийәүгә цыктым. Бер күрештем, икенце атнада өйләнештек. 27 йыл тордық. «Нур» коллективында эшлим. Коллективқа ун йыл. «Халық моңнары» ансамбле туктап тора. Җитәкчесе аныңқы Надия. «Нур»ныңқы җитәкчесе Рәифә Бородихина исемле. Аwылларда булабыс, сабантуйларда йырладық. Томск өлкәсендә Старокороткина аwыл бар. Анда керәшеннәр торайдилар. Анда да концерт қуйдық.

*Сөйләүче: Мөрсәлимова Маямәл*
*Шәйхулла кызы (1937 елгы).*
*Томск шәһәре*

Урманнан цыбықларны, ағацларны чанақ (әд. *чана*) белән ташыйдағамбыс. Суғыш wақытында күкәм (*сеңлем*) белән ташый итек. Керәбес урманға, йығытабыс, қырсыйбыс (*кисәбез*), апцығабыс. Пила белән қырсыйдағамбыс. Чанақ (*чана*) зур тартып йөртәдаған. Бес (*безнең*) йақта урманда қарлыған, шоморт үсәй. Күгемәй, тау йеләге, қайын йеләге дә бар.

Суны күлдән ташый идек. Қыш буйы Тумнан монда хадәр көйәнтә белән ташыйдаған итек суны. Хәзер эжик (*ишек*) алдында.

Безнең аwылға айу кергән йуқ. Төлке көп (*күб*) иде. Қуйан ашый идек. Хәзер төлке дә, қуйан да петте. Майған (*үрдәк*) ашый идек. Хәзер аның тәме йуқ. Ашатырға бодай да йуқ. Элек қыр тулы бодай, соло иде.

Аранда (*сарайда*) сыйыр, маллар торай. Аран әнә урамда (*йорт алдында*). Көпкәдә (*кечкенә җылы абзар*) таwық, сарық, бозау тота идек. Пице бар иде. Сыйыр бозауласа, пиц йаға идек. Суwақ булса өшөмәсеннәр дип. Хәзер дә анда йәйен бозау торай. Бу бәләкәй өй безнеке (*бу безнең бәләкәй өй*).

*Сөйләүче: Гобәйдуллина Гашурә*
*Исмәгыйль кызы (1928 елгы).*
*Казан авылы*

Минеңке этийемнәр дә, мин дә, палаларым да биредә үскән. Қалтайда тудым. Мин Қалтайдан монда тормошқа цықтым. Томскқа қәдәр 20 цақрым. Аннан тағы 20 цақрым. Монда қәдәр

(ике аwыл арасы). Клупта «Зилем-зилем» уйынын уйныйдаґанбыс. Круг итеп тотонып йырлыйдаґанбыс. Иремнеке (әд. *иремнең*) энесе бестә Қалтайда иде. Клупта алар инде таныштырдылар бесте. Ирнеңке әни-этисенә әни-эти дип әйтәм. Кемнеке нәрсәсе бар әсерләдек кийәүгә цыққалы.

Унйеде йыл қалада тордом. Монда мәктәп бар иде. Башта өц, анан дөрт. Аннан сәвсим бетте. Батуринаға, Қалароваға (*авыл исемнәре*) китте. Қалтайда сигезгә қәдәр. Үзем татар телендә ике класс уқыйдаған. Бу аwылда да татар теле бар иде. Минеке (*минең*) балаларым уқыдылар ике класска қәдәр татар, ә аннан киттеләр Батуринға. Мәктәпне йапқац.

Маллар тора аранда (*сарайда*). Көпкә йуқ хәсер. Элек бар иде. Көпкәдә бәләкәй босау, йаңы туған, таwықлар бергә торғаннар. Ул бәләкәйрәк. Йердән қазылған. Өстә монандый палатка кебек нитеп таwықлар тотайдамбыс. Сарық булмағанда таwықлар ғына тора иде. Таwықлар булмағанда сарықлар ғына. Хәзер көпкәләр бетте.

*Сөйләүче: Казакова Фәүзия*
*Фәхри кызы (1938 елгы).*
*Казан авылы*

Мин өц кенә класс бетергән кешемен. Өц класс менән хәзер қөрән (әд. *Коръән*) дә уқыйм, аллаға шөкөр. Намазны уқыйм, уразаны тотам. Кийәүгә бардым. Минеке сигез балам булды. Онықтарым бар. 28 йыл сыйыр саwучы (булып) эштәдем. Соңыннан мин ун йыл телятница эштәдем. Передоwой булдым. Аннан садикта ун йыл эштәдем. Уналтыдан кийәүгә цықтым. Мине урлап алкиттеләр (*алып киттеләр*). Әтийем утыра икән самавыр қайнатып. Соңыннан сөйләйди: «Синең өцөн, қысым, ой переживайт итттем». Иптәшемне армийаға алдылар. Бес қат (*хат*) алыштық. Бес заготовкаларға йөрәбес. Силсәүит персидәтеле, милиция менән эшкә қуғаннар элек. Ә бестең ни кигәле йуқ суғыш wақыттан соң.

Йөзәр таwық тотадаған итек. Қаз, үрдәктәребес, таwықтарыбыс булды. Анца (*шул хәтле*) қазлар. Өцәр сыйыр. Өцәр сийыр-

нықы бысаулары буладаған. Ике ат буладаған ите. Бестеке бик мал күп ите. Анда атларнықы конюшн′а иде.

1931 йылнықы найабрынықы мин булған. Паспортта башқа. Абам әйтәй: «Син ништәп сорамыйца барып паспортыңа қуйтың» дийәй. Элек бит йаздырмағаннар. Алар әйтәләр иде: «Менә қарлыған wақытында тудық, пецән өстендә» дип. Кибән күренгәндә туғаннар. Шундай әйткәннәр бит элек. Силсәүиткә барбағаннар, урысца белбәгәннәр. Урыстарны күрбәгәннәр, урыстарны белбәгәннәр. Қоттары цыққан урыстарны күргәле (*күрергә*). Бер урыс килсә, қаца торған булғаннар. Безнең аwылда бер урыс кеше булбаған. Бер марйа булбаған. Абқай әкәне Абдулла дийәбес инде. Ә менә Қызылқашта йартысы урыс, йартысы татар. Айаққа цитектәр кийгәннәр. Минеке дә цитегем бар әле. Бес чабаталарны белбәдек.

Бес Алды дибес речканы. Ағым су Ауды. Анан су ташый идек эчәдаған (*эчә торган*). Йуына торғанны күлдән ташыйбыс. Мунцаға сыйырларыңа эцәсең (*эчерәсең*).

*Сөйләүче: Юнысова Зөрия*
*Гали кызы (1931 елгы).*
*Абытай авылы*

## Йорт салу, йорт-җир турында

Өйне өйгәндә өмә буладаған. Туғаннар киләдырған, алар булышқалы, өйөшкәле бүрәнәләрне. Эшләшкәле киләдәгәннәр. Кем йаллый. Безнеке тоже андый уқ күтәрдек. Матқага ақца қуйадағаннар. Өй урынын основайт иткәндә қуйадағаннар. Уголларына һәм маткага күтәргәндә ақца сала дағаннар.

*Сөйләүчеләр:*
*Курбаева Румәнә Әхмәтвәли кызы (1950 елгы),*
*Касанова Тәнзилә Сәрвәретдин кызы (1941 елгы).*
*Әүштә авылы*

Төнен (эд. *төнлә*) йоқлағаннар пиц пашында. Байырақларның ике бүлмәле булған. Мамауымның (*дәү әниемнең*) ике бүлмәле. Аныңқы қайнанасы бай қызы булған. Өйөн тиргәгән

(*кирәкле әйберләрне җыйган, йортын бизәгән*). Сәғәте, матур сәке, зор (*зур*) өстәл иде.

Монда да кәтәк диләр, таwыққа йасалған абзарда (*абзарны*). Өстә таwықлар. Аста өстәл инде. Уголда утыра иде. Өй эцендә булбай. Монда сәке. Монда зур пиц (*мич*). Ипи пешерәдаған (*пешерә торган*). Аның пашында бес йоқлайдық. Дүртәү сыйа иде.

*Сөйләүче: Әгъләмова Шәрфүк*
*Рәҗәп кызы (1933 елгы).*
*Умавыл*

51 йыл менә бу өйдә торабыс. Теге өйдән бу өйгә чықтық. Күршебездәге мулла менән маткага ақча салдык. Монет ақча. Чақырып көрән уқыттык. Мулла Абытайда (*авыл исеме*) торай. Мулла хәзер аннан киләй, монда хәзер мулла йуқ. Мәцет бар иде. Мәцетте саттылар. Минеке бабайнықы братынықы алып салдылар. Уголда. Қайтқанда күрерсес. Мәцет өйе. Мәцет йуқ. Бер хатын йөрөде мәцет салам дип. Анда кем барсын, Барғалы мамай да йуқ, баба (*авыл әби-бабайлары*) да йуқ.

*Сөйләүче: Гобәйдуллина Гашурә*
*Исмәгыйль кызы (1928 елгы).*
*Казан авылы*

Өйне салсаң, кешеләр йаллыйсың. Ақца түләгәннәр. Өмә йасатып, аларны ашатып-эцереп өйә торған булғаннар. Бес монау йортны дүрт айның эцендә күтәреп, сылап, буйап монда цықтық. Қору (*коры*) өй генә утырды әле. Анда қапқа-ни йуқ, стайкалар да йуқ әле. Стайкалар йасаттық. Монау йортқа қырық пиш йыл. Зур пицтә пешеренә идем. Улым аларны базды (*сүтте, җимерде*). Безнеңке сылаған бүрәнәләр кердем-цыктым иделәр. Су керде. Бездә 2010 йылда су басу булды бик көцлү (*көчле*). Тәрәсәгә хәтле. Ун көн эцендә кипте ул. Халадил′никтар ақтарылған. Мин йөрәм (*йөрим*) Рәмзийәдә. Йөрәм-йөрәм, аннан минем қызым киләй, су керде дийәй. Өц маши-

на Камаз озон ағацтар иде. Алары вис ағып китте. Ананда (*әнә анда*) тулған. Клуп мынан. Хранилище бит колхостыкы, шунан ғына суны туқтатайлар да. Андый көцлү бестең аwылда ғына булды. Қалған аwылларда қырыйдан ғына. Халықтықы үгездәр, аттар ағып китте, бетте. Суны туқтатайлар да инде, шунан ғына.

*Сөйләүче: Юнысова Зәрия*
*Гали кызы (1931 елгы).*
*Абытай авылы*

## Гореф-гадәтләр, йолалар, бәйрәмнәр, ырымнар, ышанулар

### *Яңа туган бала белән бәйле йолалар*

Аwылда бәбәйләйтүце әбиләр бар иде. Әби булып йөри иде минем бабайымныкы әнисе. Бала туғац, өстәл әзерләнәй, мулланы цақырабыс. Мулла баланыңқы қолағына исем қыцқырай. Арақы эцү йуқ қөрән (әд. *Коръән*) уқытқаннан соң. Аш пешерәләр, цәй эцәләр. Бала туғац, бишек бар иде, тибрәтәсең. Ағац кроватлар аннан соң. Доғалар йуқ иде.

*Сөйләүче: Гобәйдуллина Гашурә*
*Исмәгыйль кызы (1928 елгы).*
*Казан авылы*

Қырығына қәдәр дип баладың үзен генә қалдырмасқа. Бишектә йатқан wақытны, әнисенә цығып йөрөп керергә кирәк бит, қайцы қуйалар. Одеал өстенәме баланықы. Мендәр астына төгел. Шайтан килмәсен дип әйтеп. Ә башына кийеп йата торғанына төрлө төймәләр, қабырцықлар. Шайтаннан қурқып, баланы алыштырмасын дип. Қолағына татарца әйтеп, азан әйтеп исем қушалар.

*Сөйләүче: Әбдрәшитова Зөмәрә*
*Минһаҗ кызы (1936 елгы).*
*Кызылкаш авылы*

Қырығына хәтлем цәцен қырапыс. Теше цықты дип бүләк бирәләр. Кем первый күрде, бирәй. Бишеккә доғалық саладағаннар. Күс тимәсенгә доғалық йасдырып элеп қуйадаған итек. Бау менән күлмәкнеңке эценнән, цепрәк эцендә. Ышкулға барғанцақ (әд. *барганчы*) йөрә дағаннар тағып. Менә тиз (*тиздән*) булай Ураза бәйрәм (*бәйрәме*).

*Сөйләүче: Мөхәммәтшина Фәүзия*
*Сәйфи кызы (1930 елгы).*
*Умавыл*

Исем қуштыралар. Мәҗлес йыйалар. Күс тимәсен өцөн маңғайына қором сөртеп қуйайдилар. Шепчикларына төймәләр тегәйдиләр. Беснең балалар бишектә үстеләр. Бишекте үсебес тектек. Шәл барма (әд. *бармы*), қапчық барма – шулардан тегеп-тегеп қуйасың. Материал йуқ бит. Доғалықтар салып қуйай итек. Әтү пәриләр күстәренә көренә (*күренә*) қайсыларнықына. Өй ийәсе қайсы кешегә өйөнә керәй икән. Кеше булып керәй икән.

*Сөйләүче: Үтәгәнова Мәрзия*
*Хөсәен кызы (1937 елгы).*
*Умавыл*

***Баланы тәрәзә аша чыгару***. Менә дөртенце қысым. Гел мамайлар (*әбиләр*) кендегәц әбиләр (*кендек әби*) менән бәбәйләдем. Ике рәт игезәкләр булды. Менә Сабирҗанны алладан сорап башқа әбидән китердем. Тәрәсәдән қысымны. Бәбәйләгәц тәрәзәдән алып. Ишектән алды тәрәсәдән бабайым. Менә теләп алған балам. Торбай балаларыбыс. Бәбәйлим дә дөрт ай йарымда, пиш ай торайлар. Йәш тә еде көн тордо Қадиморат исемле малайым. Аннан ике игезәк малайларым булды. Көйәнтә менән қайттым да базардан аwырап. Менә бер қысымны бәбәйләдем дә, икенцесен бабайыма қуйды апкитергә инде мине. Мунцаға кертә. Әбилек кертә, баланы йуындыра, мине дә йуындыра. Өц мәртәбә дә кертә, бер мәртәбә дә кертә.

***Бәби туйы*** шул исем қуштырабыс инде анда. Бер атнаданма (*атнаданмы*), ике атнаданма. Хәйер өләп (*өләшеп*), мулла цақырайлар.

*Сөйләүче: Кабеева Факизә*
*Абдулла кызы (1923 елгы).*
*Әүштә авылы*[1]

***Балаларны имнәү.*** Күз тимәсен дийеп мин үсем имним. Дарулыйм үсемцә. Им-том үткәрәм, килешә дә. Қором сөртөп қуйайлар күс тимәсен дип. Энәләр, йалтыр-йолтыр бырушкалар тағып қуйалар. Бала бишегенә ысақ (әд. *усак*) ағацы тағып қуйа идек.

*Сөйләүче: Кабеева Факизә*
*Абдулла кызы (1923 елгы).*
*Әүштә авылы*[2]

Элгәре бес күз тигәннән өстәлнеңке почмақларын йуып, 3–4 суға бисмилла итеп ишекнең баwын нитеп баланың башына, күкрәгенә, қулларына сөртөп бисмилла әйтеп, ишекне ачып қыстырадырыйыйқ. Суны түгәсең. Ишекне қыстырасың.

*Сөйләүче: Фәхретдинова Рәйхана*
*Фәйзрахман кызы (1938 елгы).*
*Калтай авылы*

## *Өйләнешү, туй йолалары*

Туй йақшы үтәй (әд. *үтә*). Нивисталар кийенәйдиләр. Йаулықлар, фоталар кийәйдиләр, күлмәкләр алайдилар. Приданны бирнә дип әйтмәдек, просто пүләк. Мин кийәүгә барғанда минеке әнийем бер босау китерде. Босаwының муйынына бер лента пәйләте дә қысылны, аны китерде. Йурғаным бар иде, мендәрем бар и все. Йастығым. Элеккеләрдә генә сандық булған. Бездий (*безнең кебек*) халықта булмаған.

*Сөйләүче: Юнысова Зөрия*
*Гали кызы (1931 елгы).*
*Абытай авылы*

---

[1] Язма Сафиуллина Елена Шәүкәт кызы аудиотасмасында саклана.

[2] Шунда ук.

Нәнәм (әд. *әнийем*) унйиеде йәшендә кийәүгә барған, сурап (*сорап*) алғаннар. Күрше аwылнықы. Ә мине инде урлап, аннан сөйләште, килде. Ниқах булды. Ниқах уқырға мулла килбәгән. Ижап қабул дип бер бабай ғына цақырғаннар. Ижап қабул ғына дигәннәр. Ул ниқах шикелле була икән. Аннан туй йасадық үзебескә күрә инде.

*Сөйләүче: Мөхәммәтшина Фәүзия*
*Сәйфи кызы (1930 елгы).*
*Умавыл*

Бабайым утыра менә мондой мескенем:

«Кәкре бөкрө қарағай
Балта цабына йарамай.
Бабайы да мамайы да
Бер эшкә дә йарамай»,

дисәм, әйләнеп мондой утырып қуйадағын. Ацуланадағын. Анан:

«Мой миленок татарёнок
Я его татарочка.
Урлап қайтқан Абытайдан
Мирауайа татарочка»,

тисәм, бийегән булып китәдағын. Ике йыл хат йасыштым. Базарда бер күрдем дә, қацырып килде. Қырық еде йыл бергә йәшәдек.

Чурна речкадан (*авыл исеме*) урлады иртән қорбан бәйрәм көн (*көнне*). Әтийем намазға китте. Нуқайга барам дип киткән. «Әнийем, мин анда әллә кемгә кереп цығам әле» – дип, йөгөреп цығып киттем дә, кийендем дә, бәйләгән сарық йөнөннән (*йонынннан*) шәл иде. Жикет кидем. И қацтым да килдем. Соратып барсалар мине, әтийем йасый туй. Әтийем ниқах уқыта. Ә қацырып китсәләр, бу йақта йегет йақта ниқах уқыттылар. Әтийем пресидәтел иде, әтийем туй йасады. Монда туй йасар-

лық хәл йуқ иде. Бабайым үзе генә. Йәтим өц бала үстергән унөц йәшеннән.

*Сөйләүче: Кабеева Факизә*
*Абдулла кызы (1923 елгы).*
*Әүштә авылы*[1]

Таныштық, хаттар йазыштық. Ирем Қазан йақнықы (*Казан ягыннан*). Монда килгән Почтоwоға. Офицер иде, суғыш wақытында Йапонийада қатнашқан. 1943 йылда аны уқығалы йебәрделәр Чиләбегә. Анан соң анда қалған. 1945 тә япон суғышы цықты. Қытайда служит итеп монда Почтоwойга килгән. Йарасы бар иде. Солдатлар белән килгән дә. Йазыша башладық. Монда қалды. Матур кеше иде ул. Йуқ, мин әйтәм, бармыймын. Себерәк халқына да барбаймын. «Дом офицеров» дигән помещение бар иде. Минем осон қара цәц, атласоwый бантиқ иде. Икенчегә цәцте кистердем дә, челкалар йасадым да килдем аны күргәле. Нигә цәцегезне кистегес, ди. Йөрөшеп киттек. Анан балаларым берас матур булсыннар тип, аңа бардым ғуй. Кийәүгә цыққалы әзерләгәндә бер нимә дә йуқ. Бер малай, бер қыс үстердем.

*Сөйләүче: Әгъләмова Шәрфүк*
*Рәҗәп кызы (1933 елгы).*
*Умавыл*

Мамауныңкы (әд. *дәү әниемнең*) матур әкәсе (*абыйсы*) булған. Өләнергә (*өйләнергә*) кирәк ғой (*бит*). Ә өйләнергә барғалы үзләре танышмай. Әнисе-әтисе барып сорашай. Үстәре дә бай. Байырақ кирәк дигәннәр. Күзләгәннәр. Бу байның ике қызы бар дигәннәр. Шулай булған электә. Болай танышу йуқ. Инәй-аталар барып күрә. Қызларын күрсәткәннәр матуррағын. Сөләшәләр (*сөйләшәләр*). Аннан сон (*соң*) малайына әйтәйләр. Малайны китерәйләр. Сөләшеп қуйалар. Ниқахқа киләйләр. Ә олосы шадра икән. Малай күрбәй әле аны. Халық инде белә кемне биререн. Бер-берсен күрмичә (егет белән кыз) свидетели йаwап

[1] Язма Сафиуллина Елена Шәүкәт кызы аудиотасмасында саклана.

бирәй: «Ризама?» «Риза». Аннан суң бикләп қуйалар қызны. Қызлар башта киләй. Кийендереп утыртып қуйалар. Монда бите йабылған. Йегетләр гармошка менән киләләр, йырлайлар. Йегетне қалдырып цығып китәләр. Бу килгән дә, йөзөңне күрсәт инде, қатыным, дигән. Ачса, шадыра рыжий нивиста утыра...

Аннан соң икенце көннө кийендергәннәр инде. Алйапқыц менән. Самавар артында утырай, цәй салып торай килен. «Инде әйдә, – ди, әбийем сөйли, – киленегезнең қулыннан цәй эцегес». Әйдәгес, дийә. Кердек, битемнән как будто ошпарили дийә. Утыра шадыра қыз дийә. Менә шул. Йегеткә ошамай инде. Ә йарамый кире боролғалы. Апқайтып китәләр. Икенце атнада тегендә туй, йегет йақта (*егет ягында*) туй. Придан менән қыз килә. Болар инде апкиттеләр придан менән. Аннан икенце килгәндә қодалар киләдаған. Ә монда йоқлау йуқ. Болар килә. Туй була. Әпкитәләр қызны йегет менән теге йаққа, қунаққа. Қунақтан қайталар – син мин любовʹ аларның бик була. Бабай балықчы иде. Алдан үлде. Қалада торалар иде. Суғыш wақытында киткән. Кийәwе киткән иде, балалар қалған. Қызлар аwырап киткән иде. Анда йырақ түгел тора идем. Аларға киләм. Каждый килә көйәнтәләр менән теге аwылдан. Шылтыр-былтыр. Аларға керәләр. Цәй қайнап торай. Бабай пич йаға. «Ах-ха-ха – ба-ха-ха» көләләр. Күңеллеләр. Йеде бала туды (*тудырган*). Аwылда торғанда қайнанасы сүгә икән: «Туасың да туасың (*тудырасың*)». Ә ул: «Синең өцөн булбасын. Нәби мине йарата. Нәбийемне йаратам», дип әйтәдаған. Без аны йараттық әби wақытында. Әйбәт иде ул. Матур бабай иде. Матур-матур балалары туа. Шадра балалар булбый. Йегет кеше (бабайыбыз) қарарақ иде. Бу йаққа тартқан. Әби дигән шадра ак-рыжоватый қыз – қалмақ иде.

*Сөйләүче: Әгъләмова Шәрфук*
*Рәҗәп кызы (1933 елгы).*
*Умавыл*

Унтоғыста кийәүгә цықтым. Элек урлау иде бит. Элек сорау йуқ иде. Ниқах, аннан туй. Сөйләштек икәү, урамға кицен цықтым да, аңа киттек. Ул ал урамда (*алгы урамда*) тора иде,

бес арт урамда (*арткы урамда*) тора идек. Анан (*аннан*) тәтәминәм (*әти-әнием*) бардылар цақырып никахқа. Анан инде туй. Кыржуалар бәйлийдағаным. Миңә хадәрге сандық иде. Минем бабайымныкы сандығы әле анда утыра, теге йақта, менә күрсәтерем (*күрсәтермен*) әле. Сандық приданға бара иде.

*Сөйләүче: Гобәйдуллина Гашурә*
*Исмәгыйль кызы (1928).*
*Казан авылы*

### *Ураза гаете, Корбан гаете*

Скоро ураза бәйрәме була унйедесе. Ураза бәйрәмендә монда намазға барырлар мәцеткә. Бестә мәцет тә бар ғой (*бит*). Кем ни пешерә, шуны апара инде. Кем самса, бәрәңге, кем туғач (пәштит) инде апара. Мәшкә (*сарык*) суйдылар. Мәцетне ацқанда кеше күб иде. Мулла азан қыцқырды. Мулла қандый (*нинди/шундый*) инде: Әхтәм мулла қаладан килеп йөрит, анда торат. Бестә Черна Речканы (*Черная речканың*) мулла (*мулласы*) Ғали мулла йөрәй күбесенцә.

*Сөйләүчеләр:*
*Касанова Тәнзилә Сәрвәретдин кызы (1941 елгы)*
*һәм Курбаева Румәнә Әхмәтвәли кызы (1950 елгы).*
*Әүштә авылы*

Бездә қорбан бәйрәменә цығалар бала-цаға, тәғбир әйтеп зийаратқа қәдәр. Кереп цығайлар. Конфит әзерләп қуйасың инде бәйрәмегес котту (*котлы*) булсын дип, керәйләр бәләкәйе-бәләкәйе. Табун-табун киләләр. Бер оцтан бер оцқа йөрийләр. Бер-берсенә бәйрәм цәйен эцкәле йөрийләр.

*Сөйләүче: Әгъләмова Шәрфук*
*Рәҗәп кызы (1933 елгы).*
*Умавыл*

Қорбан бәйрәме, 19 ында ураза бәйрәме була. Мәүлет Ғашура бәйрәме бар. Үткәрә идек. Элек халық күп иде. Өц мәртәбә өстәлгә утырадаған. Перенце бабайлар. Аннан мамайлар. Аннан

йәшләр. Ә хәзер ике-үц (*ике-өч*) кеше өстәл артында. Мантый, цәкцәк хәзер йасыйлар. Икмәкне бетүдән бетүгә сала идем бик тәмнү (*тәмле*) итеп. Элек икмәк қамырыннан қалдыралар иде (әчетке итеп). Өйгә бәрәкәт керсен өцөн доғалык элдек. Элек доғалар күп иде.

*Сөйләүче: Гобәйдуллина Гашурә*
*Исмәгыйль кызы (1928).*
*Казан авылы*

Қөрән уқытқанда җиде партия уқытып чығаралар иде. Алдан бабайлар уқыйдаған иде. Элекке wақытта монда мөселман зираты булған. Қалтайга 385 йыл инде. Бақчаларны сөргәндә кешеләрнең баш сөйәкләрен таwып (*табып*) күмеп қуйдылар аны. Бездә бит монда бөтөнесе дә татарлар торалар иде бит. Аwылның мәчете булған. Анықы Мостафа (Сафа) бабай мулла булған.

*Сөйләүче: Фәхретдинова Рәйхана*
*Фәйзрахман кызы (1938 елгы).*
*Калтай авылы*

Хайраннарға мин қалам,
Бисмиллә әйтә белмәсәм дә
Қорән ашына мин барам.
Қорән ашына барып,
Битемне сыйбап утырамын.
Өйгә қайтып керү белән
Русца сөйләгәле тотынамын.

Бер әби цақыра-цақыра күршеләрен. «Wақыт йуқ, wақыт табалбайым», тиләр. Үлеп китте әби. Мал бүлешәләр балалар. Анан соң қалық йыйнаталар та, кеше ашаталар. Йылыйлар қорән ашында. Мин дә бардым инде. Чақырдылар аwылда. Миңә әйтә. Эх, минәйтәм (....) әби бу бананнарны ашаса иде.

Аналары аwырап йатса,
Рәнҗетәләр ананы.
Үлгәннән соң халық йыйып
Ашаталар бананны.

(.....) аба аwырап йатты
Туғаннары килмәде.
Үлгәннән соң халық йийылып
Рухы аның шатланды.

Эй, туғаннар, шуны әйтәм:
Көймәне кире борыйқ.
Аwырап йатқан туғаннарның
Барып хәлләрен белик.

Зур итеп йазып йебәрдем. Нийә кирәк мин әйтәм бананнар ашап утырабыс. Үсен сыйлыйлар, анағызны сыйлағыс тере цақта.

*Сөйләүче: Әгъләмова Шәрфүк*
*Рәҗәп кызы (1933 елгы).*
*Умавыл*

***Яңгыр теләү.*** Су буйында қойынғаннар. Киң йер. Су сибешәләр иде циләк менән. Йамғыр теләп.

*Сөйләүче: Гобәйдуллина Гашурә*
*Исмәгыйль кызы (1928).*
*Казан авылы*

***Догалыклар.*** Бай торғалы (*торырга*) ишек өстенә қуйалар монандый әйбер. Менә буны миңә (*миңа*) 1989 йылны бүләк иткәннәр иде. Ақчасы да, тары йармасы да бар анда. Ишек пашында доғалық.

Монда ***туйда суга бару йуқ***. Монда шишмә йуқ.

***Яшьләр көне.*** Монда йәшләр көне үткәзәләр иде. Хәзер йуқ инде. Клуб булмаған.

***Изге урын.*** Рәшит Измайлович килә изге урынға – су буйына. Томның шифа суы аға. Шуннан ирләрне фронтка җибәргәннәр. Ул шулай дип әйтә иде.

*Сөйләүче: Фәхретдинова Рәйхана*
*Фәйзрахман кызы (1938 елгы).*
*Калтай авылы*

**Кием-салым, бизәнү әйберләре**

Ойык кисәк инде, ойықты байбақ дийә иделәр. Бүректе тағыйа дийәйләр иде элеккеләр. Элекке хатыннар монда матур энҗеләр менән шапкалар кийәйләр иде. Оцон цуқлы ақ шәлләр йабыналар иде. Күкрәк күренмәцен өцөн күкрәкнәмә кийгәннәр. Цәцләренә үреп тәңгәләр тағалардаған. Түгәрәк кенә. Алар Сөләйкә (әд. *Зөләйха*) маманықы (*карчыкныкы*) буладаған иде. Алар йөзәр йәштә үлделәр. Ишеткәнем бар иде аның «Қайнинәмнеке (*кайнанамның*) тәңкәләре миндә әле һаман бар», дип сийләнгәнен.

*Сөйләүче: Юнысова Зөрия*
*Гали кызы (1931 елгы).*
*Абытай авылы*

Ашағалы да йуқ кебек кигәле дә булбаған. Мәрцән (әд. *мәрҗән*) әйтәдек. Тақыйа цәцәктән үргәннәрдәген, башқа кийәсең бит. Цуқлы зур шәлләр кигәннәр қышын. Внучқам цигәдәген төрлү, паласлар да. Элек әнийемнең сандығы қалған иде. Әйберләр, кийемнәрде саладаған.

*Сөйләүче: Мөхәммәтшина Фәүзия*
*Сәйфи кызы (1930 елгы).*
*Умавыл*

Бишмәт бар иде. Музейға бирдем ғуй. Минең йеңле. Муйынца тағадаған. Монда цигелгән. Әнийемнеңке бишмәте булған. Ул придан белән килгән. Анықы асты колонок, сары ул. Күлмәкләр бөдрә-бөдрә итеп. Халадай (әд. *халат кебек*) йеңнәре киң. Итәкләре кат-кат, қуштанлы (*бәбәй итәк*). Суғыш wақытында. Әбийемнең сандығыннан бишмәт алып, колонокларын сүттем. Ике қулны тығып йөрә (*йөри*) торған муфта тегеп утырайлар иде. Ә бу бархат. Монда мех белән. Собол′ йәнлегенеңке. Мин теккәле (*тегәргә*) өйрәнгән идем шапкалар. Башлары кала, мәрцәннәр қуйып ансамбл′ менән йырлағанда кийеп йөрә идем. Башларға мех менән эшләтелгән бүрекләр. Қалфақ, түбәтәй циктем. Оста цигәйдем. Қатыннар шәлләр, йаулықлар йабынадаған.

Шәлләр кәзә, сарык йөненнән (*йонынннан*). Кәзә тотучы булбады. Бер әбей генә оста тотто. Сез (*сезнең*) йақта кәзәләр тоталар. Шәлләр йахшы. Киндер утыртылған. Теге йақтан, Булгария йақтан килгәндә цигүцеләре килгән. Икеме-өцме сем′йа ғына килгән. Цуқындырғаннан қацып килгәннәр бестеке Умавылға. Бездә лапти кигән кеше булмады. Пима (*киез итек*), галош кигәннәр. Сестә тула ойоқ. Бестә йуқ тула ойоқ.

*Сөйләүче: Әгъләмова Шәрфүк*
*Рәҗәп кызы (1933 елгы).*
*Умавыл*

Инәмне (әд. *әниемне*) белмим, но мамам (*дәү әнием*) чәченә үреп тәңкә тағай иде. Безнең чәчебес осон (*озын*) буладаған. Хәзер қайчы алам да, қырц(ш)ыйм-кырц(ш)ыйм (*кисәм*) да атам. Қолаққа сырғалар кийәләр иде. Мәрцән (*мәрҗән*) бар иде. Батинкы, түфлә, үтек (*итек*) кийә идек. Үтекне йәй, йаз, көс кигәннәр, қыжын (*кышын*) – пима (*киез итек*). Ыштан кийәйләр иде. Ойық дийә идек. Мамайлар осон күлмәкләр кийәдаған ите. Башқа түбәтәй кийәдаған ителәр. Йаулық бәйләп. Қыш көнө ирләр тун кийәдағаннар, без – тиләгрейкә, бишмәт. Сарық йөнөнән үсем (*үзем*) эрли идем. Йөн наскиләр кидек. Орцық менән эштәп. Тәрәзәгә қорғалы фәрдә, түл′. Кыржуалар бәйлий идем. Минеңке инәм (*минем әнием*) пал′то тегә иде ул. Пал′то тегеп сатып, бесте ашатты.

*Сөйләүче: Гобәйдуллина Гашурә*
*Исмәгыйль кызы (1928 елгы).*
*Казан*

Иске чүпрәкләрне чигелгәнне орлағаннар (әд. *урлаганнар*). Безнең аwылда да чигәләр, шәл бәйлиләр иде. Үзем дә чиктем.

*Сөйләүче: Фәхретдинова Рәйхана*
*Фәйзрахман кызы (1938 елгы).*
*Калтай авылы*

Дорожкалар, чүпрәкләр бар иде. Бәйли, чигә идем: қамут өсләренә, тәрәсәләргә, караwат өстөнә, тәрәс фәрдәсе. Минеке

Бибинисабам чигә иде. Анан өрәндем (әд. *өйрәндем*). Чигү белән ун йәшләрне (*яшьләрдә*) булғандыр. Аннан инде алар кирәкмәс булдылар. Модада иде чигү. Хәсер бетеп китте. Кирәкмәс булдылар алар.

*Сөйләүче: Казакова Фәүзия*
*Фәхри кызы (1938 елгы).*
*Казан авылы*

## Аш-сулар

Бәйрәмнәрдә самса пешерелә. Уратылған. Зур пәлеш пешерәләр иттекен, бәрәмәц, пирошкилар. Йә цәк-цәк кемдер пешерә инде. Хәлвә қатыралар. Цәк-цәкне қандый (әд. *ничек*) пежерәсен (*пешерәсең*), хәлвәне дә. Хәлвәгә, например, пиш күкәйгә мондый кружоктар йасыйсың да, аны йәйәсең дә, әз генә қорытасын. Аннан кисеп-кисеп лапша кебек, майны жарит′ иттеләр. Хәлвә пер майда ғына пешерелә. Ә цәк-цәк өц майда пешерелә. Перенце ақ майға саласың, аннан суң әз эссүгә (*эссегә<кызуга*) саласың, аннан инде бик эссүгә саласың. Өц майда пешерелә. Ә хәлвә пер майда ғына. Пер майны жарит′ итеп алсаң, лапшасын да кисеп-кисеп әзерләп аласың да, сал да сал, сал да сал. Озонлықта тотбыйцы (*тотмыйча*) ғына. Палды (*балны*) қайнатасың да петерә пешереп алғац, палға бутыйсың, саwытқа саласың да, тапап-тапап қуйасың. Пер чәшкегә пер чәшке шикәр саласың икән, пер паллитрга пер паллитр шикәр саласың. Палны қайнатасың. Суwақ (*суык*) суға салып. Күрәсең, суwақ суда нителсә (оешса), өстенә паливат′ иткәле. Қайнамаған палны қойсаң, таралып торай. Йәбешбәй (*ябышмый*) пер-персенә. Палны қаладан алабыс. Алтайскины.

*Сөйләүчеләр:*
*Курбаева Руманә Әхмәтвәли кызы (1950 елгы),*
*Касанова Тәнзилә Сәрвәретдин кызы (1941 елгы).*
*Әүштә авылы*

Элек церек бәтер (әд. *черек бәрәңге күмәче*) ашағаннар. Көзөн қалған бәрәңгене йыwасын, әрчисен. Тосын-нийен саласын

да, менә сиңә (*сиңа*) бәтер. Аны табатанда (*табада*) бешерәсең. Бер өц бәрәңгене қырадаған, аннан икесен бергә басып, қаладаған. Балық каптит итәдаған. Бабайым балықцы иде. Аппарып сатасың. Қалаға да апарғаладым. Городокка да апарғалый даған. Қайа уңай сатқалы (*сатарга*). Анда бит тотайлар. Қацыпқотып сатайлар. Элек разрешенйы булмыйдаған. Сөт битонына тутырадаған да, көйәнтәләп барадаған, йәнәсе сөт апарадаған. Аны сатадаған. Қысларым бәләкәй буладаганнар. Икесен биктәп китәдәгән идем өйдә. Цәнецкене, пыцақны қалдырмыйдаған. Қурқыйдаған. Мин қайтқынцы көтеп утырайлар, тәрәс төбенә утырып. Бабай балық тотадаған, мин каптит итәдаған. Ул эштәгәц, берни эштәй албайдим (*берни эшли алмый идем*). Фермада скотник иде бабайым. Қайта да миңә қалдырай (балыкны), үзе эшкә китәй. Мин инде монда балықны йә тостыйм, йарит′ итәм, каптит′ итәм. Шундый йәшәдек инде. Ацтан үлмәстән (*үлмәс өчен/үлмәскә*).

Минем абам (*апам*) бар иде. Аның менән клюквага йөрөйдәгәнбес. Қышқыға әзерләйдәгәнбес азық. Мишкә (*гөмбә*) тоздыйдағанбыс. Ул wақытта кеше мишкәгә йөремийдәгән, бес икебес генә йөрейдәгәнбес. Лисичканы, груздасын йыштырма (*җыеп*) қайтып, тостап қышқыга әзерли дәгәнбес. Ә клюкваны сатқалы. Кәрәсин, сабын – андый ниләр алғалы. Ул бақытта бит бернимә (*бернәрсә*) йуғ иде. Шоморт бар, ләкин қортлар покой бирмәйләр. Күбәләкләре. Йәйнең уртасы йетсә, шомыртты ашап китәй. Шоморттан лүпсә (*киптереп төелгән шомырт* ) йасый идек. Сатқалы аны. Лүпсә қышқыға пешергәле. Хет пирошки йаса. Лүпсәгә элек суқма (*киле*) булалған. Элек суқма мынан лупсаны йасаған. Шомортты мисарубкадан крутит итә дәгәннәр сөйәкләре (*төшләре*) қалсын өцөн. Wақ булалған. Суғып ала торған. Шомортқа, қарлығанға йөрәдәгәннәр. Аларны қалаға саттық. Ә ақцасына рам йасатқалы, ике-бер тәңкәлек ашыйдағанбыс да.

*Сөйләүче: Сәйфетдинова Мөнирә*
*Мифтахетдин кызы (1925 елгы).*
*Әүштә авылы*

Гөбәдийә пешермиләр бестә. Туқмачлы аш төрлөчә иттереп пешерәләр. Қасыберсе тықмачлы ашқа таwық итене пешергән wақытны то кәбестә салалар, тәм керсен дип әйтеп. Пәрәмәч, урамалар йасайлар. Төчө қамырдан, әче қамырдан. Пәрәмәчләрне төрле начинкалар белән йасайлар. Төрлү (әд. *төрле*) бәлешләр пешергәннәр.

*Сөйләүче: Әбдрәшитова Зөмәрә*
*Минһаҗ кызы (1936 елгы).*
*Кызылкаш авылы*

Иттән аш, пәрәмәц пешерәләр. Хәзер өцпоцмақ. Әнийем цамца, цәкцәк пешерә иде. Зур пицтә бәлештәр пешерә торған идек. Мин дә пешерәдаған, минем дә зур пицем бар иде. Онны иләп, салып. Типшә – он иләр өцен ағачтан саwыт. Инәмнең бар иде андый.

*Сөйләүче: Мөхәммәтшина Фәүзия*
*Сәйфи кызы (1930 елгы).*
*Умавыл*

Йарлылық. Церек бәрәңге ашап үскән кешемен. Урамалар пешерәләр. Цәкцәк, пылаулар. Сез йақта (*сезнең якта*) қатық. Монда қатық пешергән кеше йуқ. Тәбикмәк, пәрәмәч, өчпочмақ.

Қыр суғаны, қандық җийалар. Қандық – теге пучка дийәләр. Аның нәзеге дә, зуры да бар. Айу қандығы да бар. Аның цачәге (*чәчәге*) ата. Ақ цачәк ата, сарырақ була башлана. Цачәге йарма кебек. Саласың сөттү (*сөтле*) ашқа. Умач диләр инде болай итеп галошка шикелле. Лапша галушкалар. Йәйен сөтле аш пешерәләр иде. Кишерне ботағы белән wақ қына турап. Цөгөндер, йаңы бәрәңгене турап. Аннан иде тосту (*тозлы*) ғына итеп пешереп алалар да қайнаған сөтне салалар. Йомырқаны салалар. Тәмнү овощной аш булып чыға. Дачада барсы да бар. Турадым турадым да. Тимер пиц анда. Утырттым. Сөт, күкәй, укроп, суған салып. Суғыш wақытында әбийем қандықны апқайта да, wақ қына турый да, күкәйне сөтне, аш булып чыға.

Галушкалар. Күкәйне он белән бутыйсың-бутыйсың да, тосту суны қамырны, аннан галушка итәсең.

Әнийем: «Киттеңме Мичуринга?! Қычытқан апқайт!» дийәй. Первым долгом қычытқан ашы иде. Шпарит′ итеп ала да wақ қына рубит итәй.

Аwгуст айында арыш китәй. Бирәләр бер умацлық. Умац диләр. Галушқалық. Бер тәринкә (*тәлинкә*) қала инде. Аны бескә бүлеп-бүлеп бирәй. Исе чығай. Көтеп ала идек инде шуны.

Суғанның исеме күбергән. Күбергән дийәбес қыр суғаны кебек. Аны апқатасың, ашыйсың-ашыйсың. Мамау (*дәү әнием*) аны творогка нитеп нәрсәдер пешерә иде.

*Сөйләүче: Әгъләмова Шәрфук*
*Рәҗәп кызы (1933 елгы).*
*Умавыл*

Урама пешерәләр. Аны майда пешерәләр. Ун күкәйгә 150 грамм май саласың. Қаймақ. Шикәр әз генә. Тозын, әчетке саласың әз генә, қабартасың. Бер қабарып чықтымы, аннан әwәләп, җәйеп-кисеп. Көрәк шикелле тайақ белән урыйсың. Шуның белән қайнап торған майға төшерәсең. Менә бес инде ураза бәйрәменә пешерәбес, алла бирса. Аны монда ғына пешерәләр. Пәрәмәч, пылау пешерәләр.

*Сөйләүче: Фәхретдинова Рәйхана*
*Фәйзрахман кызы (1938 елгы).*
*Калтай авылы*

Суғыш wақытында урманда үлән йыйып йөрдек. Ачқа. Қандық, сарғантай ашый идек. Сарғантай – тамыры чиснук шикелле. Қандық – үлән, зур үсә иде. Қандығы бик тәмнү (*тәмле*) иде. Йердән қазып, сөттә пешерәйдек. Прәме бек тәмнү иде. Йәйен үсә дә, үләннәрдән аш пешерәдаған. Бәрәңге қырып. Галубцилар, бәрәңге қоймағы. Он, икмәк йуқ. Тормош аwыр булды суғышта, күпме халық үлде ачтан. Инәм (*әнием*) бәрәңге пешерә иде. Өчәр-төртәр күстән мондый ғына. Совхоз булмаған. Ашлық

чәчкәннәр үстәре, мал тотқаннар үстәре. Шундый торғаннар. Шуннан калхуз йыйып вис. Даже сыйырларны да йыйдылар. Инәм пал′то тегеп сатып, бесте ашатты. Лапша йасыйбыз сәкәлүк (*уклау*) менән.

*Сөйләүче: Гобәйдуллина Гашурә*
*Исмәгыйль кызы (1928 елгы).*
*Казан авылы*

Тау җиләге менә бездә йырақ түгел. Аннан шоморт булса шоморт. Қарлыған, балан. Бәлешләр пешерәбес. Балан бәлеше. Шоморт булса, әйләндереп шоморт пирогы дийәбес. Қарлыған туже. Wақыт булғанда пешерәбес.

*Сөйләүче: Казакова Фәүзия*
*Фәхри кызы (1938 елгы).*
*Казан авылы*

Доғалықлар да белми идек. Үзебес инде монандый белгәнебесте, этийем өйрәтә иде. Бәләкәйемнән үк сәхәр ашап үстем эти-әнийемнәр менән. Қоймақтар, пәрәмәц, пилмән баребер йасап. Ит (мал) суйғаннар. Базарға барасың сату йасап. Аннан инде икмәк алып қайтайлар иде. Тигермәнгә йөрә идек, онны тигермәнгә тартып ақайта идек. Кисил йасый идек. Солоны тарттырасың да, аны цығып кисел йасыйсың. Ул ап-ақ сөттий (*сөттәй*) була инде. Әнийләр эшлидаған, бес ашый идек. Мат′ мачеха йыштыра (*җыя*) идем. Зверобой. Матрүшкә урманда болотада ул. Анда йеләккә барғанда, әнийем сындырып-сындырып апқайтып, себеркене сындыра иде дә, мәтрүшкәне бәйләй иде. Мунца керсәләр, мунцада цабыналар мине йуыша (*юындыра*) торғаннар иде. Себерке (*миллек*) дийә идек. Қайын себеркесе. Салқын мунцаға ғына кереп йуыша (*юына*) идем. Шундый хәлдәр. Пицтә пешертек. Пицләрне йасауцылар бар.

*Сөйләүче: Юнысова Зөрия*
*Гали кызы (1931 елгы).*
*Абытай авылы*

Шәңкәләр (*рус. шаньга*) пешерәбес. Эремцектән дә пешерәсең. Пәрәмәц кебек ацық була. Цәкцәк тә пешерәбес. Анан «Нигә қорыға эцәңнәр (*эчәсез*)? Йетешегес, йетешегес. Ашаңнар (*ашагыз*). Эцеңнәр (*эчегез*)» тип қыстайбыс қунақтарды.

*Сөйләүче: Үтәгәнова Мәрзия*
*Хөсәен кызы (1937 елгы).*
*Умавыл*

Қарлыған, қара қарлыған, қызыл қарағат үсәй иде бестә. Қара қарағат миндә үсәй. Күренәйбә (*күренәме*) тәрәстән? Урманда күк йеләк, күгемәй, малан, малина үсәй. Йеләкләр үсәй. Алардан төрлүсен пешерәдаған. Бақцаны да қарый алмайым – йәш зурайды (*олыгайдым*). Мәтрүшкә йыйып қайтайдек.

*Сөйләүче: Мөхәммәтшина Фәүзия*
*Сәйфи кызы (1930 елгы).*
*Умавыл*

## Туганлык атамалары

Иремә исеме менән әйтәй идем. Кечерәкләргә дә исеме белән әйтәм. Фәүзийә – ул минеке иремнеке сеңлесе. Хәмиттән бәләкәй булғац, Фәүзия генә дийәм. Олорақ булса, абам, әкәм дийәм. Ирнеке абый-апасы – аба-әкә, кеце булса, исеме белән әйтәсең. Ирнең эти-әнисен – инә-ата. Без йақта күкәм, күкәләр дип тә әйтәләр энем-сеңлемне.

Минем этийем Қазаннықы кешеләр. Әнийем себерәк. Сибирский областныкы булған. Әнием себерәкцә сөйләшә иде. Ә этийем үз ницек, қазанца сөләште.

Тумавыллар (*авыл исеме*) бик қату сөлийләр. Себерәкцә дә төгел. Йөзләре инде хәзер қушылды инде. Йәүштәләр (*авыл исеме*) булалар иде бүтән төстә. Күзләре қысық, битләре зур була иде. Ә хәзер қушылып, йәшәрде бит халық. Халық матурайды хәзер. Урыс белән дә қушылып. Элекке Йәүештәләр бик йәмсезләр иде, матурайдылар. Қушылып-қушылып беттеләр.

Күбрәге монда Хөснетдиновлар, Фәйрутдиновлар. Мамай тип әбийләргә әйтәләр. Мамау – казанца була дәү әни. Бабау –

бабай. Балдыз, энекәш дип әйтү бик йуқ. Исеме белән әйтәйләр. Шундый исемнәр бестә: Рәмил, Рәхимулла, Маһинур, Маһира, Зәйнәп, Зөхрә, Маһиқамал, Минзифа, Әминә һ.б. Элек кушаматлар булган, хәзер әйтбәйләр (*әйтмиләр*).

*Сөйләүчеләр:*
*Үтәгәнова Мәрзия Хөсәен кызы (1937 елгы).*
*Умавыл.*
*Фәхретдинова Рәйхана Фәйзрахман кызы (1938 елгы).*
*Калтай авылы*

## Ышанулар

***Адаштыру.*** Бер бабай әйткән иде: «Кисловка (*авыл исеме*) таба барғанда адаштыра», дийәй. Усақлық, усақ йафрақлар үсләре шаулап тора. «Аларныңқы йафрақлары әйләнгән wақытта, йафрақлары башларны әйләндерә дип әйтәләр. Ул йаққа йөрмәңнәр, балалар», дип әйтәләр иде. Wақ-wақ усақлар иде. Адашқанбыс инде.

*Сөйләүче: Әбдрәшитова Зөмәрә*
*Минһаҗ кызы (1936 елгы).*
*Кызылкаш авылы*

***Суныңқы ийәләре*** йәшәй. Әйтәләр иде, ышанбай идем. Берwақыт Е(и)патоwаға шышкаға киттек. Безнең каблацок бар иде, утырдық өцебес киттек тә. Калароwаға йетеп утырғанда, суда безнең көймәне бер нәрсә йебәрми. Мин ишетә идем элек су анасы бар дигәнне. Настоящий белдем су анасы барын. Без килеп йеттек Калороwоға. Қазанаулға безгә төшкәле кирәк. Йебәрми. Фәхри әйтә: «Менә монда йегерме тийенгә йөзөк йасаған идем», дийә. Алды да мондый терп (*иттереп*) төшөргән иде, киттек тә қалдық – су анасы бесне йебәрде. Ату әйтәй иделәр, мин ышанбай идем. Су инәсе бар. Менә анандый будық, орехка бардық. Ипатоwо йырақ бит. Өц цақрым тау пашына мендек. Көймәне қуйдық та Нуриман безне апкитте. Йәйәү апкитте, анда мендек. Быйақтан анда безне бәйрәмгә дә апарғаннар иде. Савхузлар қушылышқанда. 1953 йылда Иптоwада булдық

бәйрәмдә. Менә Линнур күрде микән су анасын. Аннан телсез булып қайтты, су анасы тотты дип қайтты берwақытны. Аннан суң аны мат′ воды дийә атый башладылар. Тотқан. Ул анда йатып сөйләшәлмичә. Анандый қайтты. Анда сәннәр қарады. Барған булған. Су анасы тотып, нишләгән. Андый қайтты бит.

ских татар применяется так же и в значении «счастье»[1]. Личные имена *Котогулу* < кот «счастье» + огулу <огыл< улы «сын», *Коттугач* <кот «счастье» + тугач «родиться» связаны с понятием счастья. Компонент *уруз* употребляется во многих тюркских языках в форме *ырыс < ирыс < рыс < ураз < урас* имеет несколько значений 1) примета, предзнаменование; счастливое предзнаменование; 2) доля; счастливая доля 3) счастье; благосостояние; состояние[2]. Синонимичным именам *Котлы, Коттуды* являются имена с компонентами *ходай<кодай* п. «бог»: *Кодай, Кодайбирде* и др. Персидский термин *ходай*, по мнению ученых, является пережитком далекого алтайского периода[3]. Согласно мировоззрению хакасов, Ак худай олицетворяет мужское и вообще всякое доброе начало.

В антропонимиконе томских татар зафиксированы имена, оброзначающие месяц, время рождения ребенка: личное имя *Нәүрүз* образовано от персидского слова *нәүрүз* «новый день», от названия праздника нового года по астрономическому солнечному календарю у иранских и тюркских народов. Различные варианты имен *Гурбан < Курбан< Корман < Корбан* образованы от арабского слова курбан «жертвоприношение», связанного с исламским праздником окончания хаджа, отмечаемым через 70 дней после праздника Ураза-байрам, в 10-й день месяца Зульхиджа в память жертвоприношения пророка Ибрахима. Личным именем *Сафар* нарекали детей, рожденных во втором месяце мусульманского календаря.

Среди исследуемых антропонимов томских татар особое место занимают простые производные (аффиксальные) антропонимы, образованные с помощью уменьшительно-

---

[1] *Валеев Ф.Т.* Западносибирские татары во второй половине XIX – в начале XX в. С. 180

[2] *Севортян Э.В.* Этимологический словарь тюркских языков. М.: Наука, 1974. С. 666.

[3] *Садекова А.Х.* Идеология ислама и татарское народное творчество. Казань: Фикер, 2001. С. 199.

ласкательных суффиксов, передающих значение сочувствия, уважения:

-кәй: *Илчикей илчи* 1) посол, посланник, посланец; 2) вестник; 3) сваха; 4) правитель[1] + -*кәй* уменьшительно-ласкательная форма. С помощью суффикса -*кәй* образованы преимущественно мужские имена.

-тай*: Арыктай, Боротай, Конотай, Отроштай.* Аффикс приналежности 1-го лица единственного лица -*тай (тайым)* используется при ласковом обращении к детям или лицам младше себя в различных диалектах татарского языка.

-чык: *Тулголчык, Набучак, Сепечек, Топачак, Кулчак, Балтачак*, Анжечак и др. В данных имена -*чык/-чек* является высокопродуктивным стилистическим суффиксом[2].

-мән: *Ишмән, Үрсәмән*. В указанных именах суффикс -ман/ -мән обозначает объект, характеризующийся признаком, указанным в основе.

-ба: *Кочекба, Арыба, Туксыба.* Данные имена являются средневековыми кыпчакскими именами. Имя *Көчекба* < *көчек* «щенок» + *ба* < *оба* «род»[3]. В практике наречения именами такого типа существовал обычай использовать в качестве имени человека название родоплеменного объединения, и напротив, для названия родоплеменного объединения – собсвенное имя. По мнению Д.Г. Тумашевой, *Туксыба – Токсоба* – раннесредневековое кыпчакское племя[4]. Оно упоминается в числе 11 кыпчакских племен арабоязычными авторами XIII–XIV веков. Н.А. Баскаы ков отмечает, что в практике именования всех этих типов имен существовал обычай использовать для присвоения человеку на-

---

[1] *Севортян Э.В.* Этимологический словарь тюркских языков. М.: Наука, 1974. С. 351.

[2] *Ганиев Ф.А.* Современный татарский литературный язык: суффиксальное и фонетическое словообразование. Казань: Дом Печати, 2005. С. 90 .

[3] *Баскаков Н.А.* Имена половцев и названия половецких племен в русских летописях // Тюркская ономастика. Алма-Ата, 1984. С. 75.

[4] *Тумашева Д.Г.* Этнические связи западно-сибирских татар (по материалам топонимии и антропонимии) // Советская тюркология. 1987. № 2. С. 51.

звания родоплеменных объединений и, напротив, для названия родоплеменного объединения – собственное имя человека[1]. Он возводит этимологию имени *Токсоба* к компонентам *токус* «девять» + *оба* «род». Однако Д.Г. Тумашева предполагает этимологию личного имени *Токсоба*, восходящего от собственного имени *Туксыбай: туксы* (-тохсы) + *бай* > туксыба[2] .

-анак: *Суманак, Кутанак, Бектенек Аганак, Еманак, Тохтанак*; -анак/-энэк/-ынак встречается во многих тюркских языках в значении 1) друг; 2) надежда, вера; 3) приют, убежище; 4) верный; 5) правитель, доверенное лицо, министр; 6) симпатия, любовь; 7) чистый, без примеси; 8) красивый, прекрасный[3]. По-мнению Ф.А. Ганиева, *-анак/-әнәк* генетически связан с суффиксом *-ганак.* Существительные с суффиксом -анак обозначают лицо или предмет, характеризующиеся с какой-то стороны признаками, указанными в основе: диал. көйәләк «человек, склонный к печали»[4]. Личное имя *Еманак* образовано из двух компонентов: *ем* + *анак*; 1. слово *ем* встречается в древнейших памятниках и сохранившиеся в своих прямых или синонимических значениях в отдельных диалектах татарского и башкирского языков: «целительное средство», «лечебное средство». Данное личное имя имеет значение прекрасное целительное средство».

*-мәт: Аймәт, Акмәт.*

*-әш* аффикс обращения: *Юкәш, Мамаш, Сәйдәш, Имаш, Камаш*. Личное имя *Сәйдәш* образовано из двух компонетов: первый компонент «сәет» обозначает титул + *-әш.*

Некоторые антропонимы образованы от именных основ и аффиксов *-чы/-че,* обозначающие деятеля или носителя какой-

---

[1] *Баскаков Н.А.* Имена половцев и названия половецких племен в русских летописях. С. 75.

[2] *Тумашева Д.Г.* Этнические связи западно-сибирских татар (по материалам топонимии и антропонимии). С. 45.

3 *Севортян Э.В.* Этимологический словарь тюркских языков. М.: Наука, 1974. С. 655.

[4] *Баскаков Н.А.* Имена половцев и названия половецких племен в русских летописях. С. 180.

либо профессии: *Чиричи* < *чири* < *čerig* войско + *-че:* «предводитель войск»; *Тайчи* < тай 1) жеребенок; 2) молодой конь[1] + *чи* < *чы:* «конюх».

Антропонимическая система томских татар начала XVIII века характеризуется устойчивостью древнетюркского ядра личных имен. В материалах антропонимии отложилось значительное количество данных, свидетельствующих об этнических и исторических связях томских татар с кыпчакскими племенами, сыгравшими решающую роль в формировании сибирских татар. Рассмотренный материал в совокупности позволяет сделать вывод о том, что антропонимикон томских татар начала XVIII века является живым памятником для изучения исторической антропонимики.

---

[1] ДТС. С. 527.

# ТОМСК ТАТАРЛАРЫ ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Илсөяр Закирова*

Себер татарлары фольклоры шактый ук өйрәнелгән булса да, Томск өлкәсендә яшәгән татарларның авыз иҗаты тикшерүчеләр игътибарыннан читтәрәк калып килә иде. Бу, беренче чиратта, Томск өлкәсенең ераклыгы белән аңлатыла торгандыр. Икенче сәбәбе – Томск өлкәсе татарлары фольклоры В.В. Радловның «Халык әдәбияты үрнәкләре» күптомлыгының Себер татарларының халык иҗатын һәм тел үзенчәлекләрен туплаган дүртенче томында чагылмавында түгел микән?.. Себер татарлары фольклоры антологиясе ролен үтәүче бу хезмәт инде гасырдан артык фольклорчы галимнәр өчен гаять әһәмиятле материал гына түгел, алга таба материал туплау өчен юл күрсәткеч ролен дә уйный.

Шул ук вакытта, тирәнрәк тикшерә башласаң, Томск өлкәсендә яшәүче татарларның фольклорын тупланмаган һәм өйрәнелмәгән дип тә әйтеп булмый.

Томск татарларының этногенезы шактый катлаулы. Алар формалашуда телеутлар яки теленгитлар, чатлар, чулым татарлары, Күчем татарлары, Урта Азиядән килгән бохаралылар, Россиянең төрле төбәкләреннән килгән татарлар катнашкан. Һәм, әлбәттә, бу төрлелек күпмедер дәрәҗәдә фольклорда да чагылыш таба.

Информантлар үз бабаларының калмаклар (телеутлар), чатлар, чулым татарлары булуларын, яисә (читтән күчеп килгән

очракта) Пенза, Пермь, Түбән Новгород яки Татарстанның кайсы районыннан, авылыннан килүләренә кадәр җентекләп сөйләп бирә алалар.

Күп халыкларның синтезын хасил иткән Томск татарлары бүгенге көндә әдәби татар телендә сөйләшә. Җирле татарларның икенче бер өлеше тулысынча руслашкан.

Томск татарлары бүгенге көндә князь Тоян вакытында XVII йөз урталарында нигез салынган Томск шәһәрендә һәм аның тирәсендә урнашкан авылларда яшиләр. Томск каласын ике өлешкә бүләргә мөмкин – иске һәм яңа кала.

Шәһәрнең борынгы өлешендә ике катлы агач йортлар тезелеп киткән. Аларның агач челтәр тәрәзә йөзлекләре, йорт кәрнизләре үзләренең нәфислеге һәм купшылыгы белән таң калдыра. Йортлар, кагыйдә буларак, буялмаган. Сирәк кенә бары тәрәзә челтәрләре генә буялган йортлар да очрый. Шунысы да игътибарга лаек, тәрәзәләр бик биек, зур. Ике ягында сирень, балан куаклары, чия, юкә, миләш агачлары утыртылган, чәчәккә күмелгән бу урамнарда йөргәндә ерак Себердә булуыңны да онытасың. Чөнки мондый зур тәрәзәле йортларны җылырак өлкәләрдә күрергә гадәтләнгәнбез.

Шәһәрнең агач корылмаларга бай иске үзәгенең сакланып калуын информантларыбыз җирле администрациянең бер карары белән бәйләп аңлаттылар. Архитектура истәлеге булып торган бу йортларны сүтү, алар урынына бина төзү тыелган. Берәр сәбәп белән юкка чыккан очракта йорт урыны буш калырга тиеш икән. Карар чыккан көннән бу тирәдә янгын чыгулар да туктаган, башка табигый бәла-казалар да йортларны җимермәгән. Чынлап та мондый карар булганмы, әллә бу чорыбыз фольклоры гынамы, билгесез. Әмма Томск урамнары шул кадәр гүзәл, бер поезддан икенчесенә күчә-күчә, аларны күрер өчен генә дә килергә була бирегә.

Томск каласы тирәсендә аның кырыена сыенып сакланып калган татар авыллары урнашкан. Томскида татар мәчетләре, мәдрәсәләре булу, Бөек Ватан сугышына кадәр Татар педагогия училищесы эшләү, милләтен һәм шәһәрен кайгыртып яшәгән та-

тар меценатлары – болар барысы да берничә гасыр дәвамында әлеге шәһәрнең татарның ерак Себердәге бер мәдәни мәркәзе булып торуына китергән. Хәзерге вакытта да Томск татарлары үзләрен татар халкы гына түгел, Татарстан халкы итеп тә саныйлар. Татарстанның һәр уңышы өчен сөенеп яшиләр алар. «Татарстан көчле булганда, без көчле! Татарстанга булган хөрмәт безгә карата, Томск татарларына карата да хөрмәт бит ул», – диләр. Шулай да, Томск белән Казан спорт командалары очрашканда хәлләре мөшкелләнә икән. Кем өчен җан атканнарын сораучыларга «үзебезнекеләр өчен!» дип җавап бирсәләр дә, үзләре кем өчен күбрәк җан атуларын төгәл генә аңлатып бирә алмаслар иде.

Экспедиция Томск татарлары яши торган Әүштә (Эушта), Абытай (Черная Речка), Тахтамыш яки икенче исеме Кызылкаш (Тахтамышево), Умавыл (Барабинка), Казан авыл (Казанка), Калтай авылларында һәм Томск шәһәрендә эшләде. Аталып киткән авыллардан тыш, Кирек, Исламгөл авылларында туып-үскән информантлардан да материал тупланды.

Совет дәверендә миллионер булган колхозлар таралган, халык, нигездә, калага йөреп эшли. Шәһәрнең якын булуы, автобуслар сәгать саен йөреп тору нәтиҗәсендә, анда барып эшләү мөмкинлеге бу авылларның сакланып калуына ярдәм иткән. Авыллар төзек, чиста, йортлар зур. Юллар яхшы. Авылларның күпчелеге Том елгасы буенда урнашкан. Капка төбенә чыгуга Том ярына чыгасың. Аның утраулар ясый-ясый боргалануы гаҗәеп манзара тудыра. Биредә чит галәмнәргә үтә торган капка – «инопланетный портал» урыны булуын сөйлиләр. Башка дөньяларга яки параллель вакытка эләккән кешене очратмадым, әмма кеше, бу матурлыкта сокланып беразга фани дөнья мәшәкатьләрен онытып торса да, начар түгел.

Томскиның татарлар яшәгән урыны Заисток дип аталган. Биредә вакыт туктап калган кебек. Тып-тыныч урамнарның берсендә Кәрим бай йорты урнашкан. Ачык зәңгәр төскә буялган бу йорт хәзерге вакытта да шәһәрнең иң матур биналарының

берсе. Шәһәр астында әйләнеп-йөреп чыкмаслык җир асты юллары булган. Кәрим байның пар атларда шул юллардан чыгып киткәнен легенда итеп сөйлиләр. Кәрим бай да, башка татар байлары да атлар үстерү белән шөгыльләнгәннәр, ул атларда кешеләр һәм товар ташытканнар. Патша армиясен атлар белән тәэмин итеп тә торганнар.

Яңадан В.В. Радловка әйләнеп кайтабыз. Галим Том елгасы буенда төрки халыклар – телеутлар, шорлар, карагаслар, саян төркиләре һ.б. яшәгән бик күп авылларны йөреп чыга. Кызганычка каршы, ул Томск янында ук урнашкан татар авылларын игътибарсыз калдыра. «Образцы народной литературы»ның Алтай халыклары иҗатын һәм тел үзенчәлекләрен өйрәнүгә багышланган беренче томында В.В. Радловның Кузнецк (Новокузнецк) шәһәреннән ерак түгел урнашкан телеут авылларында язып алган берничә тексты бар. Шуларның икесе игътибарны җәлеп итә. Беренчесе «Идегәй» дастаныннан өзек. Татар халкының иң күренекле дастаны телеутларда да билгеле булганмы икән? Бу күренешкә артык гаҗәпләнеп тә булмый. «Идегәй» дастаны күпчелек төркиләрнең уртак мирасы санала. Ул телеутларга татарлардан да, казак халкыннан да күчәргә мөмкин. Себер татарлары белән телеутлар бик якын аралашып яши. «Кузы Көрпә белән Баян-сылу» дастанының телеут версиясе белән татар версиясе дә бер үк әсәрнең вариантларын тәшкил итәләр. Әмма шушы ук томда икенче бер текст бар. Сүз телеут халкының беренче галиме М. Чибалков язып алып В.В. Радловка җибәргән өзек турында. М. Чибалков аны «Осип җыры» дип атый – «Мән Осиптың җүрүмин сарынга кидиргәним, паштапкы сөстөр пу туру»[1]. Ягъни «Мин Йосыфның җырын ... китергән идем, баштагы сүзләре бу булыр». Сүз «Йосыф кыйссасы» турында бара. В.В. Радловта бу әсәрнең халыклашкан бер өзеге басылган.

---

[1] *Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи., Ч. I. СПб., 1866. С. 190.

Якоп тәгән кижи полгон,
Яткан җәри Канаган полгон.
Аның улдары ун әки полгон,
Артык сүгәни Осип полгон[1].

*Якуп дигән кеше булган,*
*Яшәгән җире Кәнган булган.*
*Аның уллары унике булган,*
*Артык сөйгәне Йосыф булган.*

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы, нигездә, Идел буенда таралган. Әсәр, басма китап буларак та, йөзләгән кулъязмаларда да, татар халкында бик популяр була. Аның халыклашып, телдән башкарыла торган күпсанлы вариантлары да билгеле. Әлбәттә, бу өзек телеутларга бары татарлардан гына керә алган. Ул Идел буе татарлары белән Том ягына килгән, биредә дә башка халыклар өйрәнеп-отып алырлык популярлык казанган. Икенче фаразыбыз да бар. М. Чибалков бу әсәрне телеутлардан түгел, нәкъ менә Томск тирәсендә яшәгән татарлардан язып алган булырга да мөмкин. Чөнки телеутларның теле себер татарлары теленә никадәр генә якын булса да, гарәп-фарсы алынмалары белән баетылган Идел буе татарларының теле һәм ислам идеологиясе белән сугарылган язма әдәбияты алар өчен җиңел була алмый.

Бу әсәрләр, Томск татарлары этногенезында урын токкан телеутларның татарлар белән тыгыз мөнәсәбәтен күрсәтәме, яки телеутларның татар халкына кушылып бетмәгән этабына ишарәләүче бер ядкәрме, бу киләчәктә галимнәргә тикшерү өчен бер ачык мәсьәлә булып кала. Әмма бу өзекләр, иң беренче язып алынган фольклор үрнәкләре буларак, Томск ягы татарларының фольклор мирасы булырга дәгъва кыла ала дип уйлыйбыз. В.В. Радлов «Томские губернские ведомости»дан алган космогоник легенда да Томск татарлары фольклоры үрнәге түгелме икән әле?

---

[1] *Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи., Ч. I. СПб., 1866. С. 190.

Бүгенге фольклорга әйләнеп кайтабыз. Биредә татар фольклорының күпчелек жанрларына караган әсәрләр бар. Әкиятләр, дастаннар кебек күләмле әсәрләрне хәтерләгән информантлар очрамаса да, топонимик һәм тарихи риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, кыска җырлар, бәетләр, мөнәҗәтләр, ышанулар һәм йола фольклоры үрнәкләре шактый тупланды.

Бәетләр һәм мөнәҗәтләр бу якка Казан татарлары белән килгән булырга тиеш. Шулай ук информантларның әбиләреннән калган дәфтәрләрдә сакланган бәетләр дә язып алынды. Биредә язма әдәбиятның халыклашу күренеше дә очрады. Умавыл авылында туып-үскән Әгъләмова Шәрфүк ападан язып алынган «Мужик бәете» һәм «Теләнче бәете» язма әдәбиятның халыклашкан үрнәкләре. Информант бу әсәрләрне көйләп башкара, аларны борынгы бәетләр дип аңлата. Шәрфүк апа үзе дә шигырьләр яза, бик күп җырлар белә, бүгенгә кадәр «Халык моңнары» татар хорында җырлый.

Әлеге хорга йөргән апалар башкаруында «Сак-Сок» бәетен язып алдык. Татар халкының иң киң таралган бәетен биредә дә яратып башкаралар. «Ялгыз ана», «Әфган бәете» кебек бәетләрне дә яхшы беләләр.

«Халык моңнары» хоры Томск шәһәрендә яшәүче татарларны берләштергән үзәк тә. Биредә озак еллар җырлаган Надия апа Сәмитова, Эльза апа Анненкова, Хаҗиморат абый Алимов, Нурия апа Ибраһимова, Флүрә апа Урманчеева, Майямал апа Мөрсалимова башкаруында күп җырлар язып алдык. Алар татар халык җырларын да, татар композиторлары әсәрләрен дә яхшы беләләр. Әлбәттә, иң популяр жанр – ул кыска җырлар. Аларны һәр информант белә. Алар үз чорының җырларын гына түгел, әниләре яки әби-бабалары җырларын да хәтерләргә мөмкин. Шул ук вакытта, нәкъ менә кыска җырларны төрле регионнарда яшәгән татар халкын берләштереп торган жанр дияргә була. Татар халкының популяр «Ал, Зәйнәбем», «Сарман» җырлары белән бергә бу якларда гына җырлана торган җырлар да очрады. Мәсәлән, туйларда җырлана торган «Городок» җырын

мин башка җирдә очратканым булмады. Информантлар: «Бу “Городок” җырын туйларда җырлыйлар. Туйга килгән халык авыл буенча шушы көйне җырлап килә. Кыз ягы җырлый. Егет ягы каршы җырлый. Кодаларны мактап җырлыйлар» дип аңлаттылар.

1927 елда П.Г. Иванов «Труды Общества изучения Томского края»[1] җыентыгында Томск татарларына багышланган мәкалә бастыра. Бу мәкаләдә Томск татарларының бер җыр үрнәге дә китерелә. «Нам рассказывали, что некоторые из стариков, когда выпивали, пели непонятные приезжим татарам песни. Вот одна из них», – дип яза П.Г. Иванов:

И Полатбе, Полатбей,
Кайда киттең, Полатбей?
Ун эшн бар ашказар улым бар,
Алтын чачле кызм бар.

Бу мисалдан күренгәнчә, бу юллар хәзерге татар теленә бик якын телдә һәм анда аңлашылып бетмәгән юллар бары язып алучының татар телен белмәвен генә күрсәтә булса кирәк:

И Полат (Булат) би, Полат би,
Кайда киттең, Полат би?
Ун эшем бар (яки ни эшең бар)
Ашказар улым бар,
Алтын чәчле кызым бар.

Шулай да, бу юллар кыска җыр булмыйча, берәр дастан кыйпылчыгы түгелме икән дигән сорау да туа. Борынгы дастаннарның аерым юллары кыска җыр булып йөрү күренеше фольклорда билгеле.

Хәзерге вакытта Томск татарларында, халык җырлары белән бергә, татар композиторларының җырлары да бик популяр.

---

[1] *Иванов П.Г.* Труды Общества изучения Томского края. Вып. 1. Томск, 1927. 104 с.

Гомумән, халык татар җырларын да җырларга да бик ярата. Биредә булган вакытта бер күңелле күренешнең шаһитлары булдык. Кич белән кафеда ял итеп утырган яшьләрнең популяр татар җырлары җырлаганын күреп шаккаттык. Нәкъ шушы җыр аркасында танышып китеп, алардан Себер һәм Россия символы – Аю турында күп кенә хикәятләр дә ишеттек. Аю – гаять акыллы, искиткеч җитез, бернәрсәдән курыкмый торган куркыныч ерткыч. Аңардан йөгереп тә, агачка менеп тә качып котылып булмый. Баскач дүрт метрга җитә торган аюлар бер сугуда үгезне үтерә, дип сөйлиләр. Шуңа күрә аю белән очрашу күпчелек очракта фаҗига белән тәмамлана икән. Берәр җирдә аю күргән очракта тизрәк ул җирдән китәргә ашыгалар. Озак вакыт ул җиргә бармый торалар. Шул ук вакытта хәзерге вакытта аю атуның бары вәхшилек булуына, ау булмыйча, күңел ачу өчен үтерү булуына да ачына яшьләр. Элек заманда, аучылык төп шөгыльләренең берсе булган халык та аюны сирәк үтергән. Хәзерге вакытта Себер аюлары турындагы аучы хикәяләрендә аны хөрмәтләү, олылау, аңардан курку гына түгел, яңа бер мотив өстәлгән. Бу – аучылар һәлак иткән аюларны кызгану, табигатьне сакларга өндәү.

Дөресен әйткәндә, җирле халык, чын Себер халкы бервакытта да табигатьне кыерсытып яшәмәгән. Һәр гамәлендә табигать белән гармониягә омтылган. Бу Томск татарларының ышану һәм табуларында да ачык чагылыш тапкан. Ышанулар җирне һәм табигатьне җанландыруга корылган. Табигатьтә, агач-үсемлекләрдә, туфракта җан һәм акыл, тою сәләте күрү аларны сакларга, алар дөньясының чикләрен бозмаска тырышуга китергән. Агачлар да, үләннәр дә, җир-туфрак та кояш баю белән йокыга тала, шуңа күрә аларга кояш баеганнан алып кояш чыккан вакытка кадәр тияргә ярамый. Агач кисәргә бары көндез генә рөхсәт ителә. Кышын, алар йокыга талган вакытта да агачларга кагылырга ярамый. Урманнарга кергәндә исәнләшеп, рөхсәт сорап керәләр. Агачларны кисәр алдыннан, алардан гафу сорыйлар, ихтыяҗны аңлаталар.

Гомумән алганда, бередә тыюлар шактый күп. Аларның беренчеләре ышанулар белән бәйле рәвештә формалашса, икенчеләрендә тәрбия мәсьәләсе алга чыга. Мәсәлән, «урам уртасында басып сөйләшеп торырга ярамый» дигәнне бүгенге көндә тәрбиялелек, этикет нормалары белән аңлатып булыр иде. Әлбәттә, бу төр тыюларның да мифологик ышанулар белән бәйле нигезе булган. Урам уртасында һәрвакыт юл үтә, юл икенче дөнья белән бәйли торган урын. Аннан икенче дөнья вәкилләре дә узып йөри, ваемсызланып юлда сөйләшеп торган кешегә аларның зыяны тияргә дә мөмкин.

«Кояш баткач су керергә ярамый», «кояш баткач агач кисәргә ярамый» кебек табулар бер яктан, урман, су ияләреннән курку, аларның тынычлыкларын саклау белән бәйле булса, шул ук вакытта, үзләренең тынычлыгын саклауга да юнәлтелгән.

Җирнең тынычлыгын бозу да тыела. Кояш баеганнан соң җиргә көрәк тыгарга да рөхсәт ителми. Томск татарларының төп шөгыле балыкчылык, аучылык һәм терлекчелек булып, күпчелек авыллар XIX йөз ахырына гына игенчелек белән шөгыльләнә башлый. Икенче яктан, бу тыю Тибет, Монголия халыкларының җиргә казык кагу да гөнаһ дигән ышанулары белән бәйле булырга да мөмкин. Җир эшләренә караган табуны өлешчә саклап булса да, халык ата-бабаларыннан традицияне сакларга омтылган.

Мифологик хикәятләрдә Хозыр Ильяс, Су анасы, Шүрәле, Урман иясе, җеннәр, ияләр турында сүз бара. Информантлар бөтен вакыйгаларны да чынбарлыкта булган хәл итеп тасвирлый. Бу, гомумән, мифологик хикәятләргә хас алым. Мифологик әсәрләрдә вакыйга, чынбарлыктан никадәр ерак булмасын, һәрвакыт реалистик тонда сурәтләнә һәм сөйләүче тарафыннан да, тыңлаучы тарафыннан да булган хәл дип кабул ителә. Монда ярдәмгә «шаһит» күрсәтмәсе килә. Сөйләүче исә «үзем күрдем» ди, яки икенче бер кешенең авторитетына таяна.

Хозыр Ильясны ак сакаллы, ак киемле карт буларак тасвирлыйлар. Ул хәер сорап, кунар урын сорап керергә мөмкин

булган. Шуңа күрә, риваятьләр хәер эстәп килгән картларга шәфкатьле булырга чакыра.

Татар халкының иң популяр мифологик образы, әлбәттә, Су анасы. Татарлар яшәгән бөтен регионнарда Су анасы яки су ияләре турындагы мифологик хикәятләр еш очрый. «Су иясез булмый» дигән ышану да бар. Бу хикәятләр, Су анасын күргән кешеләргә сылтама белән, чынбарлыкка дәгъва белдерәләр.

Су анасы турында мифологик хикәятләр биредә дә күп. Ул елга-күлләрдә яши. Габдулла Тукайның шул ук исемдәге поэмасындагы кебек үк сурәтләнә, ул еш кына басмага чыгып алтын тарагы белән чәчен тарый. Кайбер сулыкларда ак киемле Су иясе дә күренә. Кагыйдә буларак, алар вакытсыз йөргән кешеләргә очрый. Вакытсыз ара – кояш баеганнан алып кояш чыкканга кадәр вакыт. Кояш чыгып иң беренче нурлары су өстенә төшкән вакытта күз тиюдән, төрле авырулардан дәвалау һәм өшкерер өчен таң суы алалар. Су иясен таң суы алырга баручылар да күрә торган булган. Су иясенең корбан сорап көймәне тотуы турында да хикәятләр бар. Анда, суга йөзек салгач, Су иясе көймәне тотып торган җиреннән җибәрә.

Яңгырсыз коры елларда су буенда авыл картлары Коръән сурәләре укыганнар. Элегрәк елларда яңгыр сорарга хатын-кызлар да кушылган. Хатын-кызлар төнлә суның аргы ягына чыгып коенганнар. Алар суны алып өскә – күккә чөйгәннәр, яңгыр сораганнар. Информантлар бу йоланың бөтен элементларын да белмиләр. Нык коры елларда су буенда корбан чалынган. Хәзерге вакытта бу йолалар онытылган.

Икенче популяр персонаж – Урман иясе яки Шүрәле. Урман иясе урманның иминлеген-тынычлыгын саклый торган зат. Урманга кергәндә Урман иясе белән исәнләшәләр: «Сәлам, Хуҗа, сәлам!» дип керәләр. Урманга баручылар Урман иясенә икмәк алып бара, аны урманга кергәндә агачларга элеп калдыралар. Урманга керүләре турында аны кисәтеп керәләр, урманда йөрергә рөхсәт сорыйлар. Урман иясе, кеше начар ният белән килсә, аны адаштыра.

Йорт иясе, абзар иясе турындагы сюжетлар да башка регионнарда яшәүче татарларныкы белән аваздаш. Биредә дә Абзар иясенең яраткан атының ялын үрүен бәян итәләр, ул яратмаган малына каныга, аңа көн күрсәтми, ялын-койрыгын кисә дип сөйлиләр.

Биредә Идел буе татарларында онытылган Тау ияләре образлары да сакланган. Аерым тауларның ияләре һәр юлаучыга бүре булып, сакаллы карт булып күренгән, куркып юлларыннан кире кайтучылар да булган имеш. Тау иясе – тауларны җанландыру һәм изгеләштерү белән бәйле борынгы ышануларның эзен саклаган образ. Борынгы төркиләр тауларны изге санаган, аларга табынган. Таулар илне саклаучы рух буларак күзалланган. Бу Алтай төркиләреннән килгән ышану булырга мөмкин. Татар халкының иң үзенчәлекле дастаннарының берсе булган «Түләк» дастанында да тауларга табыну эзләре саклана. Шулай ук, тауларны җанландыруның бер эзе булып, тауларга мөнәсәбәттә соматизмнар куллануны күрсәтеп була. Тауларның кеше кебек башы, кашы, бите, сырты һ.б. бар.

Томск татарларының календарь йола иҗатында яңа ел бәйрәме Әмәл дип атала. Ул Иран-фарсы халкының Нәүруз бәйрәменең варианты, язгы көн белән төн тигезләшкән 21 мартка туры килә. Әмәл бик таралган бәйрәм булып, аны бөтен кеше көтеп алган. Бәйрәмнең үз такмаклары да булган. Әмәлгә бодай бүрттереп, аның ярмасыннан ботка пешергәннәр.

Боз озату йоласы бу якларда бәйрәм төсен алмаса да, боз озатканда бөтен кеше «Яманлык китсен, яхшылык булсын!» дип теләк теләгән, догалар укыганнар.

Язын «Каргатуй» ягъни «Карга туен» бәйрәм иткәннәр. «Карга боткасы» бәйрәме бөтен авыл белән бәйрәм ителгән. Карга туе башка бик күп мәҗүси йолалардан аермалы буларак, егерменче йөзгә кадәр яхшы сакланып, йола элементларын да күпләп саклавы белән үзенчәлекле.

Каргалар килгәч, җир кардан ачыла төшкәч, сукмак төшә башлагач, карга туеның көне билгеләнгән. Язгы бәйрәмнәрнең барысына да хас булганча, бу көнне яшьләр, үсмерләр йорттан

йортка кереп ботка пешерер өчен азык – төрле ярмалар, май, йомырка җыйган.

Бу яшьләр, беренчедән, бәйрәм җитүен бөтен кешегә хәбәр итсә, икенчедән, берәү дә бәйрәмнән читтә калырга тиеш булмаган. Шулай бәйрәм турында бөтен халыкка белдергәннән соң, авылдан ерак түгел, тау бите, су-елга буе кебек җиргә юнәлгәннәр. Һәр йорттан җыелган ярма, ит-май, йомыркалардан зур казанда ботка пешергәннәр. Ботка пешеп өлгергәч, иң беренче өлешне җиргә сибәләр, чишмә яки елга суына салалар. Бу җир-су ияләренә корбан бирү, аларның күңелен күрү булган. Елның уңышлы килүен, вакытында яңгыр явуны, җир-су ияләренең мәрхәмәтле булуын сораганнар.

Ботканы илгә-көнгә иминлек теләп бөтен кеше авыз иткән. Бер өлешен авылга алып кайту мәҗбүри булган. Авылда калган өлкән яшьтәгеләргә, килә алмаучыларга да ботканы авыз иттергәннәр. Халык карга боткасы ашаган кешегә хаста-авырулар килми, ул ел буе сау-сәламәт була дип ышанган. Бәйрәмнең асылында кара каргаларның җиргә яз, җылы алып кайтуларына ышану ята. Борынгылар җирнең салкын кардан арынуын, кыш бетеп яз башлануын кара каргалар белән бәйләнештә караган. Көзен кара каргалар иң соңгы кошлар булып җылы якларга китәләр. Алар җирнең җанын да үзләре белән алып китә, каргалар китү белән җир «йокыга тала». Халык каргалар кайтуын көтеп яшәгән. Кара каргалар яз көне җирнең җанын кире алып кайта, алар кайткач җир «уяна».

Шул рәвешле кара каргалар кыш белән җәй арасында, ә мифология буенча – яшәү белән үлем арасында медиатор ролен үтиләр. Томск татарлары этногенезында селькуплар да бар. Ә селькупларда карга изге кош санала. Алар, кеше үлгәч, аның җаны карга булып очып китә, дип ышанганнар. Шуңа күрә «Каргатуй» бу якларда ике халыкның да ышануларын искә алып үткәрелгән булырга мөмкин.

Гаилә-көнкүреш йолаларының иң күңеллесе, әлбәттә, туй йолалары. Никахлар ике төрле булган. Беренче очракта, алдан кызны сорап, никахлашканнар. Бу очракта, бөтенесе алдан

сөйләшенгән. Икенчесендә исә туй йолалары, кызны «урлап китү» белән башланып киткән. Дөресрәге, егет белән кыз бер-берсен яратканга алдан ук урлау турында сөйләшеп куя торган булганнар. Кызларны атта урлаганнар. Мәсәлән, Әүштә яшьләре урланган кызны Нижний Айылга алып барып, анда танышларында яки туганнарында калдырган. Шул ук көнне кызның ата-анасына кызларын урлау турында хәбәр ителгән. Икенче көнне кызны атлар белән барып алып, шул көнне никах укытканнар. Туй көнне атларга кыңгыраулар такканнар, туй арбалары төрле төстәге тасмалар белән бизәлгән. Туй мәҗлесе мул табынлы сый-хөрмәт, җыр-бию белән аралашып барган. Туйга килүче кунаклар (туй егет ягында булса, кыз ягы һәм, киресенчә, кыз ягында булса, егет ягы) авыл буенча җырлап килгәннәр. Гадәттә, кода-кодагыйларны, кияү-кәләшне, кунакларны мактап «Городок» җырын җырлаганнар.

Егетләр белән кызлар ачыктан-ачык очрашып йөрмәсә дә, аралашып, бер-берсен ошатып өйләнешкән. Егет һәм кызларның бер-берсенә хат язу йоласы булган. Бу хатларны, арадашчы булуларын үзләре дә белмәгән килеш, әбиләр «йөрткән». Яшьләр үзләренең хатларын, авыл буйлап кунактан кунакка йөрергә ярата торган әбиләрнең аяк киемнәренә куеп җибәрә торган булганнар икән. Шул рәвешле хат тиешле адресатка барып ирешкән.

Экспедиция вакытында шактый гына риваятьләр һәм легендалар да язып алдык. Риваятьләрдә Томск татарларының тарихы, авыллар тарихы бәян ителә. Һәрбер информант ата-бабаларының кайдан килеп урнашуын, алар тормышына бәйле төрле вакыйгаларны белә. Кайбер риваятьләрдә чынбарлык белән фантазия яки халыкның хыялы, тормышны күзаллавы кушылып китәргә дә мөмкин. Мәсәлән, Тахтамыш авылы исеменең килеп чыгуын Алтын Урданың соңгы ханы Туктамыш хан исеме белән бәйләү, әлбәттә, чынбарлыктан ерак. Шулай да, Туктамыш исеме бу якларда XX йөзгә кадәр шактый таралган исем булуын искә алсак, авыл аңа нигез салган Туктамыш исемле башка кеше хөрмәтенә аталуы дөреслеккә туры килә. Бу якларда

яшәгән ат караклары да риваятьләргә кергән. Татар халкында ат каракларына карата ниндидер аңлатып булмый торган хөрмәт бар. Бу риваятьләрдә дә ат каракларының хәйләләре бәян ителә.

Элегрәк бу якларда өчәр метрлы кешеләр – Алыплар күрүләре турында да легендалар сакланган. Аларда Алыпларның елганы атлап кына чыгулары, ике ярында торып туп уйнаулары, елганың бер ярыннан икенчесенә балта атып күңел ачулары бәян ителә. Олы гәүдәле кешеләр турындагы риваятьләр һәм легендалар дөньяның күп халыкларында таралган. Кешеләр соңгы гасырга кадәр, чынлап та, җирдә кайчандыр шундый кешеләр яшәгән дип ышанганнар. Биредә Алыплар турындагы легендалар соңгы елларда күпмедер дәрәҗәдә трансформация дә кичергән. Аларны кар кешесе турындагы легендалар белән кушып сөйлиләр. Аның кеше янынннан бер тавышсыз үтеп китеп күздән югалуы, зур эзләр калдыруы әйтелә.

Космогоник характердагы легендаларда җир, күкләр, дөнья төзелеше бәян ителә. Тахтамыш авылында язып алган легендаларда Айда яши торган Зөһрә кыз турында сүз бара. Бу легенда бөтен татарларга да яхшы таныш. Биредә аның селькупларда да популяр булуына инандык. Икенче космогоник легендада җир белән болытларның бер-берсенә бик якын торулары турында сүз бара. Космогоник легендалар буенча борын заманда җир белән күк бер-берсенә бик якын булган. Кешеләрнең берәр тиешсез эшенә үпкәләп күк җирне ташлап киткән. Бу легенданың күп санлы вариантлары бар. Томск татарлары вариантында бер хатын юган керен кая эләргә белмичә, болытларга элеп куя. Болытлар бик үпкәләп һәм ачуланып өскә менеп китәләр. Җир ялангач кала. Шунда этләр өрә башлый. Аллаһы Тәгалә этләрне кызганып болытларны бераз кире төшерә. Шуңа күрә, биредә яшәүчеләр үзләре ашаганчы этләргә ризык бирә торган булалар.

Дөнья бетү турындагы легендалар эсхатологик легендалар дип атала. Алар һәрбер халыкта бар. Алдарак В.В. Радлов «Томские губернские ведомости»дан алып үзенең I томына

керткән легенданы искә алган идек. Ул дөнья яратылуны һәм дөнья бетүне тасвирлаган космогоник әсәр. Безгә дә ахырзаман турында легендалар очрады. Ул татар халкында «Ахырзаман китабы» дип аталган әсәрнең халыклашкан версиясе. «Ахырзаман китабы» «Тәкый гаҗәб китабы» исеме белән дә мәгълүм. Аны Сөләйман Бакыргани язган дип санала. Китап урта гасырлар суфичылык әдәбияты традицияләрендә, башлыча, Ә. Ясәви хикмәтләре тәэсирендә язылган. Әсәрдә Ахырзаман көне (Кыямәт), бакый дөньядагы тормыш тасвирлана.

Бу легенда буенча, Төньяк боз океаны эреп, дөньяны су басачак дип ышаналар. Бу ышануның бер чагылышы белән Омск өлкәсендә узган экспедиция вакытында очрашкан идек. Төньяк боз океанын алар Мәңге (Мәңке) бабай, Мәңгелек дип атадылар. Ягъни бөтен дөнья беткәндә дә Мәңгелек калачак. Омск өлкәсе информантлары язын боз киткәндә «Мәңге (Мәңке) бабайга (яки Мәңгелеккә) сәлам!» дип калалар.

Томск өлкәсендә язып алынган материал да бу ышануны тулыландыра. Шул ук вакытта бик борынгы йоланың эзе түгел микән ул?... Информант әбисенең, мәчесе үлгәч, аны чүпрәккә төреп, эчкәрәк кереп боз өстендә калдырырга кушуын сөйләде. Әби «боз кирәк җиргә илтер» дигән. Бу да җаннарны Мәңгелеккә озатуның эзләрен күрсәткән йола булырга мөмкин.

Томск татарлары ислам динен шактый соң кабул иткән. Аңа кадәр алар потларга табынган. Агачтан ясалган потлар урманда торган. Һәр өйдә гаиләне саклаучы пот – курчак булган. Курчакларны чүпрәктән ясаганнар. Үзенең вазыйфаларын үтәмәгән курчаклар юк ителгән, алар урынына яңаларын ясаганнар. Курчакларга табыну хәзерге вакытта риваятьләрдә сакланган. Риваятьләрдә курчакларның сөйләшүе, кешеләр белән аралашуы бәян ителә.

Йомгак ясап әйткәндә, Томск өлкәсендә яши торган татарларда халык иҗатының матур үрнәкләрен язып алып кайттык. Бу әсәрләр безнең бер халык булуыбызны тагын да тирәнрәк раслый.

## ТОМСК ӨЛКӘСЕНДӘ ЯЗЫП АЛЫНГАН ФОЛЬКЛОР ҮРНӘКЛӘРЕ

### Кыска җырлар

Әүштә урамнары,
Уйный җил бураннары.
Сагынганда сөйләшергә
Юк телег(ы)рамнары.

Әүштәгә килгән чакта
Күтәрелде томаннар.
Дөнья хәлен белеп булмый
Сау булыгыз, туганнар.

Туганнарга кердегез,
Исәнләшә белдегез.
Мәкнең ак сачкәсе кебек
Күземә күрендегез.

Болар кемнәр килгәннәр,
Җиңсез камзол кигәннәр.
Болар безнең ятлар түгел,
Үзебезнең туганнар.

Ал булам сезнең өчен,
Гөл булам сезнең өчен.
Лагерь тауларына менеп,
Югалам сезнең өчен.

Басмыйм дисәң дә, басарсың,
Баскычлары сынмагач.
Төшмим дисәң дә, төшәрсең,
Туганкаең сыйлагач.

Тәрәзә дип, тәрәзәгә
Исле гөлләр күчерәм.
Сагынам сезне, бик сагынам,
Сагынып гомер кичерәм.

Сандугачлар су дип эчә
Урмандагы чыкларны.
Сагынганда биш уйларсың
Бергә булган чакларны.

Су буенда үсә торган
Яшел тирәк булсагыз шул,
Яшел тирәк булсагыз.
Кайлар дип эзләп табармын
Әгәр кирәк булсагыз.

Уйна, туган, гармуныңны,
Без җырлаган көйләргә.
Шул без җырлаган көйләргә
Сез уйнаган, без җырлаган
Калсын саг(ы)нып сөйләргә.

Сандугачым да сайрамый,
Сандугачым да сабыр.
Уртаклашыгыз кайгымны.
Берүземә бик авыр.

Кайгыра белми кайгырдым,
Кайгыларым юк чакта.
Хәзер инде тарата алмыйм
Төрлесен төрле якка.

Әүштәнең капкасы
Ачыла да ябыла.
Төннә йөргән егетләргә
Матур кызлар табылыр.

## Кыз урлау йоласы

Кыз белән егет бер-берсен белгәннәр, яратышканнар. Кызны атта урлаганнар. Урлау турында кыз белән сөйләшенгән була. Кызны Нижний аелга алып барып татарларда (туганнар танышлар булган) калдыра. Шул ук көнне кызның әти-әниләренә барып әйтәләр. Икенче көнне инде кызны атлар белән алырга киләләр. Шул көнне никах укыйлар.

## Бала багу

*Баланы мунча керткәндә мондый сүзләр әйткәннәр*:

Куяндай йөгерек бул,
Аюдай таза бул,
Картны күрсәң – каткырма (көлмә),
Яшьне күрсәң – чакырма!

*Баланы мунчада чабындырганда мондый сүзләр әйткәннәр:*

Истый, бристый,
Куяндай йөгерек бул,
Аюдай таза бул!

Әгәр урманда адашсаң аяк киемен алыштырып уңын сулга, сулын уңга кигәннәр. Аннары Аллаһы Тәгалә алып чыккан.

*Әүштә авылында*
*Корбанбаева Нурҗиян Бәдретдин кызыннан (1940 елгы),*
*Низаметдинова Фәния Бәдретдин кызыннан (1948 елгы)*
*язып алынды*

## Су иясе

Черная Речкада су иясе булган. Иртән дә баргач, кич тә баргач, күргәннәр. Бу су иясе ак киемле булган. Малик һәм Мингач күлендә күренгән булган.

Мингач күленең исемен Мингач исемле бабай (мулла) исеменә багышлап атаганнар. Ул мулла бик итагатьле булган, барысы да аны ятратканнар. Аңа хәер биргәннәр һәм ул хәерләрне

балаларга тараткан. Мингач картның йорты күл янында булган, шунда балык тоткан.

Иртән Мингач күленә таң суын авырганнарны өшкерергә дип алырга барганнар. Шул вакыт су иясе күренгән.

### Таң суы алу

Таң суын күз тиюдән, авырудан коткару өчен алынган, яки өшкерергә дип. Таң суын таңга керүгә 1–2 сәгать калгач алган булганнар.

### Курчаклар

Кызылкаш авылында бер әби булган. Алар чүпрәктән курчаклар ясаганнар. Аларны уйнатканнар. Аларны уйнатып, сикертеп, сөйләтеп уйнатканнар. Аларны ашатканнар да. Курчакларны бала дип йөреткәннәр.

### Боз озату

Боз киткән вакытта укынганнар. Яманлык китсен, яхшылык булсын, дип.

### Кыска җырлар

Абытай урамнары,
Уйный телег(ы)раммнары.
Сагынганда сөйләшергә
Юк телег(ы)раммнары.

Йөгертеп җитәлмәдем,
Сикертеп җитәлмәдем.
Ни булды икән телләремә
Сау бул, дип әйтә алмадым.

Болар кемнәр килгәннәр
Җиңсез камзол кигәннәр.
Болар безгә ятлар түгел,
Үзебезнең туганнар.

И туганым, китәм дисең,
Киткән юлың еракмы?
Киткән юлларың еракмы,
Әллә Ленинг(ы)радмы?

Кругларга кергән чакта
Салып кер галушыңны.
Кычкырып җырлап җибәр,
Яратам тавышыңны.

*Абытай авылында*
*Тактабаева (Әминева) Саҗидә Ибраһим кызыннан (1927 елгы),*
*Әминова Сәрвәр Гыйззәт кызыннан (1948 елгы)*
*язып алынды*

## Кызылкаш

Ни өчен авыл Кызылкаш дип аталган? Чөнки Том буенда урнашкан. Комак тукаш дип әйтә идек бит, анда комлык, төбе дә ком, яры да комлык, шуңа күрә шулай атаганнар.

Ни өчен Тахтамыш дигәннәр? Чөнки монда Алтын Урданың соңгы ханы – Туктамыш хан күмелгән дип сөйлиләр. Аны Тамерлан үтергән. Мең сигез йөз ничәнчедер елда казыганнар бу җирләрне. Картлар белгәннәр, әйтмәгәннәр кайда икәнен. Таба алмаганнар. Зират буенда, революция булган вакытта, Коръән китапларын яшергән булганнар.

Авылга 1636 елны нигез салганнар.

Авыл исеменең килеп чыгуының ике версиясе бар: хан Тахтамышны монда күмелгән дип әйтәләр. Һәм тагын бер версия бар, урын эзләп йөрегәннәр дә, монда килеп туктаганнар. Тукталган урын. Бәләкәй чакта ишеткән бар, Тахтамыш хан Туктамыш исеменнән түгел, а туктау (место стоянки) сүзеннән.

Кызылкашта бүгенге көндә 600–700 кеше яши. Җирле халык – чатлар. Шулай ук бараба якларыннан килгәннәр дигән версия дә бар.

*Кызылкаш авылында*
*Абзалимов Гарифулла Габделгани улыннан (1952 елгы),*
*Абанеев Мансур Хәсән улыннан (1947 елгы),*
*Казакова Рәмилә Шәүкәт кызыннан язып алынды*

Курчакларны төрле чүпрәк кисәкләреннән ясаганнар. Төрле размерда ясаганнар. Нинди максат белән ясалганына карап. Балаларга уйнар өчен дә ясаганнар.

Бер апа сөйләвеннән: бер хатын үзенең базына төшәргә кушмый икән. Аш уздырганда беренче ашны шул курчакларга төшереп куя торган булганнар.

– Без сорый идек, – ди. – Алар зурмы соң, – дип.

– Менә теземә хәтле булдылар инде, – дигән.

Балаларга уйнар өчен бәләкәй курчакларны балалар әниләре белән бергә ясаганнар. Төрле киемнәр киерткәннәр, яулыклар бәйләткәннәр.

Ул курчакларны урманда да куя торган булганнар икән. Өйдә түгәрәк урынга утыртканнар.

*Кызылкаш авылында*
*Әбдрәшитова Зөмәрә Минһаҗ кызыннан (1936 елгы)*
*язып алынды*

## Легенда

Элек заманда болытлар җиргә якын булган. Бер хатын юган керен алып чыккан да, эләргә башка урын тапмагач, болытка элеп куйган. Болытлар бу эшкә бик ачуланып өскә менеп киткәннәр. Шуннан соң этләр эрә башлаган. Аллаһы Тәгалә этләрне жәлләп, болытларны кире төшергән. Шуңа күрә, үзебез ашаганчы этләргә ризык бирәбез.

*Вәлиев Шәйхулла Габдулла улыннан (1948 елгы)*
*язып алынды*

## Су иясе

Су иясе көймәне тота. Шулай корбан сорый. Корбан биргәч көймәне җибәрә. Йөзек салгач җибәрә.

*Кызылкаш авылында*
*Әмирханова Гафифә Галиәскәр кызыннан (1928 елгы)*
*язып алынды*

## Круг уены

Круг уены уйнаганнар. Яшьләр җыелып круг буенча әйләнеп йөрегән, круг эчендә ике кеше кулга-кул тотынышып йөри, кругны әйләнгән яшьләр бу ике кешене җырлата, круг үзенә җырлап йөри.

*Круг эчендәге җыр:*

Кругларда йөрегән чакта
Әйләнмиме башларың?
Яза торган каләм кебек
Күз өстеңдә кашларың.

## Су анасы

Кояш баткач су керергә ярамаган. Су анасыннан курыкканнар. Бер көтүче малай сөйләгән, йоклап киткәч судан бер озын чәчле кыз чыккан. Алтын тарагы да булган.

## Курчаклар турында

Курчак уйнатканнар. Бәләкәй чагымда, күршедә бер ялгыз гына әби яши иде. Олы апа күршесенә куна кергән. Бераз торгач, кунмыйча өенә кайткан. Аңарда курчаклар бар, карчык курчак уйный, дигән. Карчык өендәге тавык кетәгенә килеп: – Шик булыгыз, бездә кунак бар, – дигән. Апа, кемгә әйтә икән, карчыкның тавыгы да юк, дигән. Аннан караса, анда әллә нәрсәдер селкенә икән.

Золовкам кияүгә барган икән Тахтамыш авылына. Аннан куркып кайткан. Анда да курчак уйнатканнар. Мин:

– Суфия, ник кайттың соң? – дидем.

– Мин курыктым, – диде.

Бабайлары исән булган. Ул бабайның исеме дә Курчак бабай булган. Караватта утырганда бабай, тәрәзә чыбылдыгын тарта икән. Курчак селкенеп тора икән. Суфия моны күреп курыккан. Бабай курчакка:

– Әнә, җиңгәң чыгып китте, – дигән.

Чыгып барганда өй башыннан берәү:

– Җиңгәй, кайда киттең, кайда барасың? – дигән. Беркем юк ди, курчаклар сөйләшә икән.

Ул курчакарны агач төпләрендә яшереп тотканнар. Аларны ашатканнар.

Бер кеше карчыкка куна кергән булган. Чәчен тарап утырганда кулыннан тарагы төшкән.

– Әй, тарагым кая, – дигән.

Бу әби әйтә икән:

– Мин сиңа әйттем, бездә бүген кунак куна, дип, тимә кешегә, дип.

Бу кеше әбидән куркып чыгып киткән. Әби бу курчакны сүгеп өй башына ыргыткан.

Бу курчакларны кешеләр үзләре чүпрәктән ясаган. Өйдә тавык кәтәгендә биктә тотканнар. Әгәр курчакларны ашатмасаң, эчермәсәң, алар ачуланган. Кеше кунганны да яратмаганнар.

**Кендегәч әби**

Балаларны кендегәч әби таптырган. Кендегәч әбиләрне пәри балаларын таптырырга да чакырганнар.

Берзаман кендегәч әбине бала таптырырга чакырганнар. Әби барган, ди. Өйдә бер хатын бәбәйләргә, ята ди. Бу бер таныш булмаган кеше булган. Кендегәч әби бала таптыргач, хуҗа:

– Әби чәй эчеп ал, әби, чәй эчеп ал, – дип, өстәл янына чакырган.

Әби:

– Юююк, чәй эчмим, өйдә үзем генә, кайтам, – дигән.

Бу җеннәр булган икән. Әбине җеннәр алып киткән булган.

Җеннең ире:

– Әби, алып кайтып куям, әби, алып кайтып куям, – дигән.

Әби:

– Үзем генә кайтам, – дигән дә, һәм укынып кайтып киткән.

Элек әбиләрне җеннәр еш кына алдаштырып алып киткән булганнар.

*Умавылда*
*Мөхәммәтшина Фәүзия Сафи кызыннан (1930 елгы)*
*язып алынды*

## Риваять

Кафтан татарлар авылы булган, Понамарев һәм безнең бабаларыбызның бабалалары авылга җирле татарлар янына яшәргә килгәннәр. Ә монда даими авыл булмаган. Утлау гына булган. Авыл булган Кафтанда. Текә һәм комлы тау булган. Шуңа күрә анда авыл урнашкан. Шундый тарих булган. Бу урында Понамаревлар килгән (аларның үз фамилияләре Понамарев булмаган, алар үзләренең исемнәрен яшергән), алар татарлар белән сыешмаганнар. Кем сез? Кайдан килдегез? дип сораганнар. Соңыннан инде, Понамаревларның һәм безнең бабаларыбыз монда килеп авылга нигез салганнар. Шушы вакыттан инде Барабинка авылы килеп чыккан.

1575 елда чатлар торган, һәм шушындый версия бар: Томск шәһәренең университетының бер белгече Галина Ивановна Перех ошбу гипотезаның авторы: Себер авылларының татарлары ул селькуплар һәм чатлардан килеп чыккан, дип әйтә.

Селькуплар, татарлар, алар исламга кергән. Бу күренеш хан Кучум белән бәйле булган. Шулай Себер татарлары барлыкка килгән.

Безнең авылның исеме Калтай. Колта авыл. Селькуплар үзләрен Колта дип атыйлар, урман кешесе дигән сүз. Колта авыл дигән сүз. Кәнскәй айыл Канский татарлары, Канско-Качинский татарлары белән бәйләнештә булган. Безнең бер бабабызның беренче хатыны Качинский татарлардан була, Качи мама дип йөрткәннәр. Касыйм бабай Казанга барып икенче хатын китерә – казанлык. Ак тәнле, зәңгәр күзле була. Казан кызы монда килгәч бабайның хатынын, балаларын күргән дә хушы китеп егылган. Иләшкән, нишләсен – татар кызы бит ул!

Татарлар ике төрле халык биредә. Бер ишләре – ак тәнле, икенчеләре – кара-кучкыл, кара күзле.

Кафтанда татарлар да, урыслар да яшәгән. Урыслар татарларны окончательно куар өчен бөтен җиргә дуңгыз башлары элеп куйганнар. Шуннан татарлар бирегә күчкән.

## Курчаклар

Курчаклар булган. Размерлары зур һәм кечкенә булырга мөмкин. Агачтан һәм чүпрәктән ясалган. Йөзен күмер белән төшергәннәр.

Бу курчакларны ясау һәм уйнату хатын-кызлар эше булган. Аларны сандыкта тотканнар.

Кыш көнне өй башында бер беглый (беженец из каторги) яшеренгән булган. Анда сандык эчендә курчак яшәгән һәм ул ашый башлаган, яшеренеп кенә. Һәм ул кеше (исеме булган) өй хуҗасына килеп:

– Курчаклар пәтер[1] ашый башладылар, курчаклар пәтер ашый башладылар, – дип әйтә.

Аларның ашый башлавы ул яхшы примета булган. Сандыкка, өй башына куйганнар ул пәтерне.

Елына бер-ике тапкыр ул курчакларны яңартканнар, җилләткәннәр. Ул курчакларны урманга алып барып түгәрәк түкмәч[2]кә утыртканнар. Ул түкмәч түп-түгәрәк булырга тиеш булган. Бөтен яклап түгәрәк ясап ул курчакларны утыртканнар.

Ул вакытта курчаклар нәрсә эшләгәннәр? Көч алганнармы?

Элек балалар бик үлгән. Балаларны саклауны, үзләрен саклауны, исәнлек-саулык алардан сораганнар.

Хатын-кызларның урманга баруын беркем дә күрергә тиеш булмаган. Ул курчакларга урманда әкрен генә, беркемгә дә ишетерлек булмасык итеп җырлар җырлаганнар. Кояш буенча түгәрәкләп йөрегәннәр. Аннары курчакларны алып кайтып кире сандыкка салганнар.

Әгәр курчак кешенең үтенечен эшләмәсә, аны утка якканнар, яндырганнар.

## Өй хуҗасы

Әгәр ашаганда азык идәнгә төшсә, аны кире күтәрергә ярамаган, ул өй хуҗасының өлеше булган.

---

[1] *Пәтер* (бәтер) – лепешка.

[2] *Түкмәч* – агач төбе – пень.

## Яңгыр сорау

Яңгыр булмаганда бабайлар яланга җыелып Коръән китабыннан сүрәләр укыганнар. Ә аннары мәҗүси йолалар башлаганнар. Ә төннә хатын-кызлар суны аргы яктан чыгып нәрсәдер эшләгәннәр. Суны алып өскә, күккә таба бәргәннәр. Яңгыр теләгәннәр.

Әгәр нык корылык булса корбан суйганнар. Итен кешеләр ашаганнар, ә сөяген суга бәргәннәр. Хәзерге вакытта да корбанлыкның сөяген суга ташлыйлар.

## Каргатуй

Карга туен сукмак төшә башлагач үткәргәннәр. Кошлар кайтсын өчен үткәргәннәр. Ботка пешергәннәр, үзләре ашаганнар, балалар уйнашып, сикерешеп, җырлап калган ботканы үләнгә сипкәннәр. Өйдән өйгә йөрегәннәр.

Селькупларда карга изге кош булган. Чөнки кешенең душасы, кеше үлгәннән соң, селькуплар уйлавынча, карга булып очып йөрегән.

## Әмәл

Әмәл бәйрәмен бөтен халык бәйрәм иткән. Хәзерге вакытта онытылган. Әмәлгә башта зерно проращивали, затем высушивали, перемалывали, һәм казанда озак итеп болгатканнар, һәм ул ак төстәге сыек боткага әйләнгән. Аны бөтен кеше ашый алган. Шушындый сүзләр әйткәннәр:

Әмәл, әмәл,  
бер аягыңа бер кәлцә,  
икенче аягыңа ике кәлцә.  
(переход от кольца зимы к кольцу весны и лета).

## Сабантуй

Сабантуйлар булган байлар булганда гына. Чөнки бәйрәмне үткәрергә акча кирәк булган.

## Риваять

Борынгы заманда авылга килгән бер ком гарәбе. Ул ком гарәбе бу җирне белгән һәм аларга әйткән: – Мин монда үләргә килдем, мине монда җирләрсез, – дигән. Бу егет әллә җылы яклардан килгән, тәне кап-кара булган. Ул бөтен кешене дингә өйрәткән. Бу авылны ул изге урында урнашкан, место медитаций дигән. Так как примета есть: река должна плыть на север, и в эту реку попадает другая речка, и между ними появлялась излучина, т.е. место медитации. Ул бөтен кешене дингә өйрәткән, южные страны турында тарих сөйләгән. Үлгәннән соң аны авыл зиратында күмгәннәр. Кабер ташы ярым түгәрәк булган һәм анда XVII саны язылган, бәлки XVII гасырда туганы, үлгәне язылгандыр. Андый ярым түгәрәк ташларны гарәпләр ясаган. Хәзерге көндә ул таш югалган.

Авыл халкы башка кабергә барып йөри. Бездә Астана бар. Анда мулла күмелгән. Зур кеше. Бу урынга табыналар. Икенче җирдә бродящий мулла күмелгән. Ул каберне бабайлар чыбыклар белән киртәләгәннәр. Хәзерге көндә караучысы юк.

## Тыю, ышанулар

Әнә, кара атка утырган кара егет сине килеп үзе белән алып китәр. Баланы караңгы төшкәч урамда йөремәсен дип куркытканнар. (Кояш баеган вакытта куркытканнар.)

Әгәр китеп барган җирдә егыласың икән: зәхмәт кит, зәхмәт кит, зәхмәт кит (3 тапкыр) дип әйтергә кушканнар. Аягың авыртмас, сызлаулар бетәр.

## Риваять

Асия исемле кызга Барабинка авылында бер егет ошаган. Ул кызга бу егеткә кияүгә чыгарга ризалык булмаган. Асия Средний Азияга китеп шунда кияүгә чыккан. Бервакыт авылга кайткан. Кайтыр вакыт җиткәч, урамда дөм караңгы икән. Умайылдан Калтайга чаклы юллар сикәлтәле булган. Шушы ике авыл арасында тирәнцәт булган. (Ул тирәнцәтнең кайсы урында урнаш-

канын белмәгәннәр). Тирәнцәттә һәрвакыт странные вакыйгалар булган. Йә бу урында странные люди, существа килеп чыккан, йә югалган. Тирәнцәт янына житкәч Асия курка башлаган, калтыранган, бисмиллаларын укынган. – Инде өемә исән-сау кайтыйм дигәндә, алдында бер ирнең басып торганын күрә. Кыз бераз тынычланып бу егет артыннан китә. Карый, үз авылларыныкы түгел икәнен күрә. Приглядеться итеп караса, егет Средний Азия киемнәренә киенгән. Өстендә чапан, йомшак аяк киеме. Бу егетнең йөзен ничек карарга тырышса да, карап булмаган. Калтайга барып җиткәч бу егет юкка чыкты ди. Бу кыз әйбәт кенә өенә кайтып җиткән. Аннары Асия бу егетне Хызыр Ильясы булгандыр дип уйлаган.

Нәнәм белән тәтәм арбага утырып Калтайдан Умайылга кайтып барганнар. Аннары нәнәсе: – Зәки, Зәки кара, артыбыздан кара эт йөгерә, дигән. Тәтәсе карый икән, ул эт күренми һәм юлларын дәвам итәләр. Нәнәсе тагын артка борылып карый икән, бу эт артларыннан йөгерә икән, һәм бу тирәнцәтне үткәнче бу эт артларыннан йөгергән. Авылларында берсендә дә мондый эт булмаган.

*Умавылда*
*Абанеева Әминә Закир кызыннан (1948 нче елгы)*
*язып алынды*

## Җир асты юллары

Томск астында шәһәр булган. Бик күп тоннельләр булган анда. Алар хәзер дә сакланганнар да. Купецлар бу юлларны бик яхшы белгән. Кәрим бай үз өеннән чыгып, өч ат җиккән карета белән, полноводье вакытында да, коры, булмаган килеш башка авылларга барып чыккан.

Абытайда роща булган. Анда табынганнар курчакларга. Изге роща булган.

## Тыю һәм ышанулар

Өстәл астында аякны селкергә ярамый, җеннәр чакырасың.
Утка төкерергә ярамый, авызыңа кутыр чыга.

Тәрәзә аша чыгарга ярамый.

Тәрәзә аша авырган баланы кире кайтаралар.

Бусагадан башлап идән юарга ярамый, алдагы юлыңны бетерәсең.

Кеше үлгәч, янына килеп, өч тапкыр «Без ач, без ач, без ач» дип әйтәләр.

Урман иясе, кеше начар ният белән килсә, адаштыра.

Агач йоклаганда, аны кисәргә ярамый. Ул кичен йоклый. Кисәргә туры килсә, агачка мөрәҗәгать итә, кисәргә туры килә, дип.

Юкә агачы авыруларны ала. Артыш куагы чистарта. Каенны өй каршына утыртмыйлар.

*Томск шәһәрендә*
*Сафиуллина Елена Шәүкәт кызыннан*
*(Татарстанның Саба районында туып-үскән, 1961 елгы)*
*язып алынды*

Экспедиция барышында шактый гына җыр, бәет текстлары язып алынды. Аларны безгә Томск шәһәренең «Халык моңнары» ансамбленә йөрүче милләттәшләребез җиткерде. Әлеге ансамбльдә җырлаучылар: Сәмитова Надия Габдулла кызы (1938 елгы, Томск шәһәре), Анненкова Эльза Фәттах кызы, Әгъләмова (Понамарева) Шәрфүк Рәҗәп кызы (1933 елгы), Алимов Хаҗиморат Әхмәдулла улы (1935 елда Умавылда туган), Ибраһимова Нурия Шәйхетдин кызы (1942 елгы), Урманчеева Флүрә Габделгани кызы (1933 елда Яңа Исламгөл авылында туган), Мөрсәлимова Майямал Шәйхулла кызы. Бу җырларны матур итеп башкарып та күрсәттеләр.

## Кыска җырлар

Биек икән тавыгыз да,
Каршы тауга карагыз.
Без килдек тә
Кунак булдык,
Инде үзегез барыгыз.

* * *

Бөрлегәннәр, төрле үләннәр
Юл буйларында гына.
Матур сүзләр, якты йөзләр
Сез дусларымда гына.

* * *

Өстәлләрдә тальян-гармун,
Уйныйлар тартып-тартып.
Сандугачым беренче кош,
Сез алардан да артык.

* * *

Салкыннарда сөйгән ярның
Ике бите кызара.
Иреннәре кызыл миләш,
Шомырт күзләр чакыра.

* * *

Җилләргә без карамыйбыз,
Салкынга карамыйбыз,
Салкын, иркен Себер(е)бездә
Рәхәтләнеп яшибез.

* * *

Безнең авыл түгәрәк,
Чорнап алган кубәләк.
Чорнап алган кубәләктәй
Яшик, дуслар, бергәләп.

* * *

Без үскәндә үскән идек,
Гөл тамырлары кебек.
Үсеп җиткәч таралаштык,
Кош балалары кебек.

**Мужик бәете**
(1915 елгы)

Кайта мужик, чыланган,
Лап-лып басып урманнан.
Өсте ертык, туңган мескен,
Кызганырлык моңланган.

Балтасы да билендә,
Бер азыгы җиңендә,
Тәне күренә бичараның,
Кырык ямау киемендә.

Әнкәм карчык карт инде,
Көтә торгандыр мине.
Ашарга да бер нәрсә юк,
Нишләтим дөньясын.

Тәрәзәдә карындык,
Идән чүпле абынырлык,
Өй үтәле җилләр исә,
Ходай бирсен сабырлык.

Китте мужик муллага,
Әнкәм карчык үлде, – дип,
Әнкәм яхшы кеше иде,
Файдалары күп иде.
Йөзе нурлы, кабере рушан,
Бичараның булса иде.

– Фидиягә ни бирәсең,
Муллага ни диясең,
Ахирәтнең газабын
Нәрсә белән жуясың.

– Кайда кәҗәң бар иде.
Мал тапмаслык син мени.
Малым юк, дип лыгырдыйсың,
Син кешедән ким мени.

* * *

Авырлыктан түзәлмичә,
Килсә теләнче капкаңа,
Авыр сүзләр белән әйтеп,
Күңелләрен таптама.

Булса – бир, булмаса исә,
Иплэп сөйлә булмаслыгын.
Белми калма, аксакаллы карт –
Хозер Ильяслыгын.

Әйләнә көпчәк кебек,
Вафалы бит дөнья.
Син бүген бай,
Шайтаннан да ярлы син иртәгә.

**Җир асты юллары**

Томский астында, җир асты юллары бар. Репрессия елларында кешеләрне алып киткәннәр дә, аларны шунда алып төшкәннәр. Алар берсе дә кире кайтмаган. НКВД аларны аткан.

Анда Кәрим бай атларын яшергән, дип сөйлиләр.

**Зур кешеләр**

Урманда 3 метрлы кешеләр йөргән. Аяклары бик зур булган. Бу революциягә кадәр булган. Алар Кызылкаш астындагы Бичән күленә төшеп югала торган булганнар. Бу кешеләр бер кешегә дә игътибар итмәгәннәр. Үз юллары белән йөрегәннәр.

**Легенда**

Уршай дигән егет Тома исемле кызга гашыйк булган. Томаның атасы аны Уршайга бирергә теләмәгән. Кыз суга баткан. Аннары Уршай да батып үлгән.

**Зәйнәбем**

*(халык җыры)*

Бакчадагы гөлләремнең
Тамырлары бер генә шул, Зәйнәбем.

Ал Зәйнәбем, гөл Зәйнәбем,
Рәхәт үтсен җәйләрең.

Ал Зәйнәбем, гөл Зәйнәбем,
Рәхәт үтсен җәйләрең.

Кайчан да бер күрешербез,
Белмим көннәрен генә шул, Зәйнәбем.

Ал Зәйнәбем, гөл Зәйнәбем,
Рәхәт үтсен җәйләрең.

Ал Зәйнәбем, гөл Зәйнәбем,
Рәхәт үтсен җәйләрең.

Һавадагы йолдызларны
Нигәдер санамадым шул, Зәйнәбем.

Ал Зәйнәбем, гөл Зәйнәбем,
Рәхәт үтсен җәйләрең.

Ал Зәйнәбем, гөл Зәйнәбем,
Рәхәт үтсен җәйләрең.

**Уракчы кыз**

*(Н. Исәнбәт сүзләре, татар халык көе)*

Ай урагын салып иң башыңа,
Кояш нурларыннан нур алдың;
Кояш нурларыннан нур алдың да
Салкын чишмәләрдән су алдың.

Басма өстендә басып су алганда
Кулъяулыгың кемгә болгадың?
Талир тәңкәләрең чыңлаганда
Кем исеменә җырлар җырладың?

## Рәҗәп бабай турында

Безнең авылда Рәҗәп бабай бар иде. Вәт әкиятләрне күп сөйли иде ул. Кич белән килә, чәй эчәсең бергә, шуннан әкият сөйли башлый. Сөйли-сөйли дә, до конца сөйләми, туктап кала. Озын әкиятләре. Туктап кала да: Балалар, караңгы икән, кайткалы[1] кирәк, ди. Икенче көнне ашамыйча аның килгәнен көтеп утырасың.

## Талы, талы

*(уен җыры)*

Тал әйләнә, тал әйләнә,
Талга ефәк бәйләнә.
Күргәнче сүзем күп була,
Күргәч телләр бәйләнә.

Талы, талы,
Талы бөгелеп тора;
Тагын бер күрәсе килеп
Үзәк өзелеп тора.

Тал-тирәкләр утыртканнар
Агыйдел читләренә.
Алсу алма суы тамган,
Бәгырем, битләренә.

Талы, талы,
Талы бөгелеп тора;
Синең өчен ярларыңның
Үзәге өзелеп тора.

Былбыл булсам бакчаларда
Бер тирәк сайлар идем.
Шул тирәктә сине мактап
Иртә-кич сайрар идем.

Талы, талы,
Талы бөгелеп тора;
Бер генә минут исеңнән
Чыгамы диеп сора.

---

[1] *Кайткалы* – кайтырга.

**Чәй җыры**

Әбиләр дә, бабайлар да
Гомер буе чәй эчкән,
Шуңа күрә борынгылар
Туксан яшенә җиткән.
Әбиләр дә, бабайлар да
Гомер буе чәй эчкән,
Шуңа күрә борынгылар
Туксан яшенә җиткән.

Иртә торып чәйләр куеп
Зәңгәр газ өсләренә
Тәмле итеп чәйләр эчә
Һәм төшә исләренә.
Әбиләр дә, бабайлар да,
Гомер буе чәй эчә.
Шуңа күрә борынгылар
Туксан яшенә җиткән.
Әбиләр дә, бабайлар да
Гомер буе чәй эчә,
Шуңа күрә борынгылар
Туксан яшенә җиткән.

Мәтрүшкәләрне өзәмен
Ислесен сайлап кына.
Әбиләр дә, бабайлар да
Гомер буе чәй эчә,
Шуңа күрә борынгылар
Туксан яшенә җиткән.
Әбиләр дә, бабайлар да
Гомер буе чәй эчә,
Шуңа күрә борынгылар
Туксан яшенә җиткән.

Тәмле итеп чәй эчик
Әбиләрнең, бабайларның

Йоласын дәвам итик.
Әбиләр дә, бабайлар да
Гомер буе чәй эчә,
Шуна күрә борынгылар
Туксан яшенә җиткән.
Шуңа күрә борынгылар
Туксан яшенә җиткән.

* * *

Әй, яшьлегем, яшьлегем,
Әй, яшь чагым бар иде,
Дим урамнар тар иде.
Киң урамны парлы итеп
Йөргән чаклар бар иде

Әй, яшь чагым, яшь чагым,
Яшь чагым матур чагым.
Очып киткән кошлар түгел,
Әйләнеп кайтмас тагын,
Очып киткән кошлар түгел,
Әйләнеп кайтмас тагын.

* * *

Әй, дусларым, дусларым,
Дусларым бәгырьләрем.
Уза икән яшь вакытлар
Белмибез кадерләрен.
Узып китте яшь чакларым,
Белмәдем кадерләрен.

* * *

Кулъяулыгым күлгә төште,
Күлгә төште күмелде.
Әй, дусларым, бергә яшик,
Бергә яшәү күңелле.
Әй, дусларым, бергә яшик,
Бергә яшәү күңелле.

* * *

Йөгереп чыктым урамга,
Әйтер сүзем булганга.
Әйтер сүзем әйтә алмадым,
Күңелләрем тулганга.
Әйтер сүзем әйтә алмадым,
Күңелләрем тулганга.

* * *

Сандугачым син кечкенә,
Син кечкенә бит әле.
Сагыну түгел, саргаерсың,
Чит жирләргә кит әле.

* * *

Эх ма, Михайла,
Михайлама, хоть майла,
Майласаң да, юк файда.

* * *

Сез дусларны кемгә охшатыйм,
Кемгә охшаган, кем белсен.
Виног(ы)рад бакчасында
Чәчкә аткан гөл төсле.
Виног(ы)рад бакчасында
Чәчкә аткан гөл төсле.

Җил булмаса да, селкенә
Олы юлның әреме,
Сезне күрмичә басылмый
Йөрәкләрнең әрнүе.

## «Городок» җырлары

Бу городок җырларын туйларда җырлыйлар. Егет яки кыз ягындагы халык, кунаклар авыл буенча җырлап килә бу көйләрне. Егет яклап каршы җырлыйлар. Кодаларны мактап җырлыйлар. Кияүне, киленне мактап җырлыйлар.

Городокның тавы биек
Утырып чана шуарга.
Городокта бер матур бар
Ничек алып чыгарга.
Городокта бер матур бар,
Ничек алып чыгарга.

* * *

Берәү, икәү, өчәү, дүртәү,
Сигез, тугыз, унике
Шул унике арасында
Барысы да сөйкемле. (2 тапкыр)

* * *

Уйна, дустым, гармуныңны,
Син матур уйнатасың.
Гармуныңны матур уйнап
Күңлемне юатасың.

* * *

Өстәлләрдә тальян-гармун,
Уйный белмибез икән.
Бергә чакта бик күңелле,
Кадерен белмибез икән.

* * *

Әй, дусларым, сезнең белән
Шат минем күңелләрем.
Шатлык белән үтсен иде
Алдагы гомерләрем.

* * *

Ерлашыйк, дуслар, ерлашыйк,
Сызылып таңнар атса да.
Үткән гомер кире кайтмый,
Сулар кире акса да.

* * *

Яшь гомерне үтә диләр,
Үткәнен күрсәң иде.
Үткән чакта тотып алып,
Кирәген бирсәң иде.

* * *

Том суының аккан суы
Аракы булса иде.
Агып барган бүрәнәсе
Колбаса булса иде.

* * *

Аракыны, пивоны
Бик яратам мин аны.
Бер эчкәндә бер бид(е)рә
Бер таз эчәм мин аны.

* * *

Аракыны, водканы
Эчә егет үткене.
Эчә егетнең үткене
Аракыны мескенне.

**Сак-Сок бәете**

Мәдрәсәләрдә китап киштәсе,
Сак белән Сокның бәетен ишетәсе.
Мәдрәсәләрдә пыяла ишек,
Сак белән Сокның бәетен ишет.

Әнкәй орышты тимер ук өчен,
Әнкәй каргады бигрәк юк өчен.
Әткәй калдырды, өйдә торсын, дип,
Әнкәй каргады, Сак-Сок булсын, дип.

Бардык урманга, җыйдык карлыган,
Без ятимнәрне әнкәй каргаган.
Төшкәндер безгә әнкәй каргышы,
Үзебез туганчы тәкъдир язмышы.

Әнкәй каргагач, Сак-Сок булдык без,
Бу дөньялардан гыйбрәт алдык без.
Чыктык басуга, урак урырга,
Ходай язгандыр шулай булырга.

Урыныбыз урман, икебез туган,
Кавышу юк безгә, әнкәй каргаган.
Өйгән кибәнне җилләр тарата,
Кавышабыз дигәч, хәзер таң ата.

Кояш чыкканда кан тула күзгә,
Кыямәт көнсез кавышу юк безгә.
Әнкәй елыйдыр, ник каргадым, дип,
Сак-Сок йөридер, харап булдык, дип.

Болай булдык без: каргыш тәдбире.
Елама, әнкәй, – Ходай тәкъдире.
Мамык эшләпәм җилгә очырдым,
Ике баламны каргап очырдым.

Мендем ботакка, карадым як-якка,
Ике баламны каргадым юкка.
Җәйгән җәймәмнең калды яртысы,
Ике баламның калмады берсе.

## Мәрьямкәй бәете

*(Минем әнкәй сөйли иде)*

Агуланган Мәрьямкәйне
Алдылар больницага,
Салдылар кроватька.
Ике доктор, бер сестра
Йөриләр коткарырга.
Коткармагыз, коткармагыз,
Мин барыбер үләмен.
Ике рәхәт, бер михнәтне
Каберемдә күрәмен.
Шул Мәрьямкәйнең янында
Сөйгәне дә суела,
Мәрьямкәй белән икесе
Бер кабергә куела.

## Такмак

Әтәч менгән киртәгә,
«Кукареку» итәргә.
Әтәчкә повестка килгән
Армиягә китәргә.

Әтәч әйтә, бармыйм, ди,
Тавык әйтә, калмыйм, дип,
Әтәчемне алсагыз,
Бүтән күкәй салмыйм, дип.

* * *

Хәзерге вакытта Томск шәһәрендә яшәүче информант Фәхретдинов Сәйфулла абый Яңавылда туып үскән. Аның сөйләве буенча, әби-бабалары Яңавылга Татарстаннан күчеп килгәннәр. Бу авылга Татарстанның Казаклар, Тәкәнеш, Олы Шыңар, Мәтәскә дигән авылларыннан революциягә кадәр, 1914 елларда килүчеләр нигез салган.

## Киржаклар

Урысларны «киржак»лар дип атаганнар – старообрядцы.

Ул киржакларның яшәү рәвеше башкача булган. Алар тәмәке тартмый, эчмиләр, сүгенмиләр. Бездә аларның чиркәүләре дә бар. Хәзер дә киржаклар бар. Алар элеке колхозларга кермичә шулай качканнар.

Безгә бер киржак кереп йөри иде: калагы да, кружкасы да үзе белән иде. Кешене ашатмыйлар. Үзләре генә шуннан ашыйлар иде. Аларга кеше керсә, кунакларга посуда аерым иде.

Әгәр кеше тискәре була икән, аңа «киржак» дигән кушамат кушканнар.

Алар авылдан аерым торганнар.

## Ат караклары

Элек Яңавылда ярты авыл ат каракларı булган. Бу революциягә кадәр була. Алар атлар җигеп бөтен семьяларын утыртып я Новосибирский, я Барнаул якларына киткәннәр, күчеп барган кебек. Берәр табуннан атларны урлыйлар да, ирләре атланып качкан, ә хатыннары кире кайтканнар. Аннары Воронин авылы ат каракларı белән урланган атларны алмашканнар, сатканнар ул атларны. Березкинода бер татар малае була председатель сельсовета. Ул атларга ялган паспортлар ясый. Аны тотканнар аннары.

Күбесе кием теккәннәр кышын.

*Томск шәһәрендә Фәхретдинов*
*Сәйфулла Сабит улыннан (1950 елгы)*
*язып алынды*

## Авыл турында

Казан авылында элек төп булган Башкортстаннан килгән татарлар. Безнең әтиемнең әтисе монда килгән кешеләр. Казаннан килгән кешеләр дә бар. Яши-яши телләре Себер теленә әйләнгән. Ә менә минем әбиемнең теле бер дә үзгәрмәгән. Төп халык *калмаклар*. Чәчләре кап-кара. Йөзләре белән аерылмыйлар. Телләре

инде бик каты: *барадыкъ, киләдек.* Авылның төп кешеләре Зәйнәп мамай, Корбан бабай.

Якында гына Том елгасы бар. Менә шушы елга буена авыл салынган. Кайчандыр сөйләгәннәр, авылны бетереп, күчендерәләр (Новосибирское море ясаганнар, шулай ясыйбыз дигәннәр).

## Иyaләр турында

Урман эчендә бер күл бар. Урманны Еш дигәннәр, берсен Бөк дигәннәр. Урман (еш) эчендә агачлар пихты, карагайлар, имән – караңгы агачлар үсә. Ул урман эчендә бер күл бар. Ул күл янына кеше керсә, адашып йөри. Адаштыра торган күл. Кешеләр анда барып адашып йөргәннәр. Ул күлне берсе дә күрми, ялгыш кына кергән кешеләр адаша. Суы чип-чиста.

Кешеләр анда адашкач, бәлки су анасы бардыр. Элек анда избушка да булган. Озеросы бик зур дигәннәр. Сәлам-сәлам (исәнләшеп) дип урман эченә кергәннәр.

Ипат тавы бар. Анда уголь казыганнар (но өлгермәгән). Казыганнар, шул килеш калдырган.

Ике тау бар, берсе Туры тау, икенчесе Ипат тавы. Туры тауның иясе булган. Йә бүре булып, йә сакаллы бабай булып күренгән булган. Тау аша шәһәргә йөргәннәр. Һәрвакыт йөргән чакта үтүче кешеләрнең күзенә күренгәннәр. Аларны җен дип атаганнар. Тауга барганда яки урманга кергәндә кешеләр үзләре белән икмәк алганнар һәм керер алдыннан бу икмәкне агачка куеп калдырганнар.

## Ахырзаман

Әбием сөйли торган иде. Менә шундый вакыт килеп җитәр, бөтен дөньяны тимер урап алыр. Менә шундый вакыт килеп җитәр – ахырзаман алдыннан дөньяны су батырыр, җир яна башлар. Тимер кошлар очарлар. Ахырзаман алдыннан чыгар начар авыру, ирләрне кырып салыр, дөньяда хатын-кыз калыр. Уйлаганнар: каян су чыга башлар? – ледовитый океан эри башлар.

Менә дөрестән дә, безнең авылда ирләр алтмышка җиткәч бер-бер артлы китеп бардылар.

Әбием бик укымышлы иде, һәм бөтен китапларны җыеп зыяратка кереп нәрсәгәдер урап-урап күмеп куйган. Бер китабы да калмаган.

Боз киткәндә Мәгъдия әбинең песәе үлгәч, малайларга хәер биреп, песәйне чүпрәкләргә төреп, урап Том елгасына алып барып, боз алып китер дигән.

**Мәгъдия әби әйткәннәрдән**

Әгәр урам уртасында торып сөйләшсәң, зур язык була икән.

Суны алып чыгып урамга түгү – зур язык.

Тышкы як тәрәзәдән өй эченә карарга ярамый – авыру кертәсең.

Бусагада утырырга ярамый.

Бусага аша исәнләшергә ярамый.

Кояш батканнан соң бакчага чыгып җирне казырга ярамаган. Бөтен җир йокларга яткан.

Кояш батканнан соң «Әгузе» әйтеп капка, ишекләрне бикләргә кирәк булган.

*Казан авылында Сотникова (Азангулова)*
*Рауза Сөнгат кызыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

## ШӘРФҮК ӘБИ ҖЫРЛАРЫ

*Гөлнара Яхшисарова*

Татарлар Россиянең төрле төбәкләрендә сибелеп яши. Томск өлкәсе халкыбызның тарихи мәркәзеннән еракта булуына карамастан, андагы милләттәшләребез гасырлар буе рухи кыйблабызны югалтмыйча яшәп киләләр. Бабаларыбыздан калган халык иҗатын онытмыйча, буыннан буынга тапшырып, үзләре дә актив рәвештә иҗат итәләр әле.

Томск өлкәсе татарларының халык иҗатын туплау һәм өйрәнү, язып алынган материалларны халкыбызның әлегә кадәр билгеле булган фольклор әсәрләре белән чагыштырып карау безгә бу төбәккә хас җирле үзенчәлекләрне билгеләргә, халык иҗатының традицияләрен ачыкларга мөмкинлек бирде. Халык иҗаты үрнәкләре Әүштә, Абытай, Кызылкаш, Умавыл, Казан, Калтай авылларында язып алынды. Тикшерүгә, информантлардан алынган мәгълүматлар белән беррәттән, мәктәп музейларында сакланган материаллар да җәлеп ителде.

Томск шәһәрендәге Татар бистәсе безне үзенең матурлыгы белән җәлеп итте. Монда вакыт туктап калган кебек тоелды. Чөнки карагай агачыннан салынган йортларга, ким дигәндә, 100–150 яшь. Узган гасырда Томск татарларының күбесе шундый агач йортларда яшәгән. Татар бистәсенең матур йортларының берсе – шәһәрнең бай сәүдәгәре Кәрим бай Хәмитовныкы булгандыр. Бүгенге көндә анда «Татар җәмгыяте» үзәге эшли. Монда ата-бабаларының рухи мәдәниятен, гореф-

гадәтләрен буыннан буынга тапшырып килүче «Халык моңнары» һәм «Нур» коллективлары белән очрашу оештырылды. Коллектив, Себер татарларының халык иҗаты белән кызыксынудан тыш, аларны җыю, саклап калу белән дә шөгыльләнә. Аларның җырларында Себернең табигате, туган якка мәхәббәт чагыла.

Шәрфүк әби Әгъләмова белән дә шушы очрашу вакытында таныштык. Аны коллективның йөзек кашы дип атарга була. Ул – шагыйрә дә, үзе бәетләр, көйләр дә яза, халык җырларын бик матур җырлый, такмаклар әйтә. Шул ук вакытта Шәрфүк әби милли киемнәр тегә һәм калфаклар чигү белән дә шөгыльләнә.

Әгъләмова (Понамарева) Шәрфүк Рәҗәп кызы 1932 елның 24 августында Томск өлкәсенең Умавыл авылында дөньяга килә. Әтисе Рәҗәп Габделхәсән улы Понамарев 1894 елда, әнисе Гайшә Нәби кызы Понамарева 1905 елда туган. Гаиләдә 8 бала туа, тик икесе генә исән кала. Берсе – Шәрфүк, икенчесе – Рауза. Шәрфүк Әгъләмованың ата-бабалары Себергә Явыз Иван идарә иткән вакытта христианлаштырудан качып килгәннәр. Һәм, акрынлап, җирле халыклар белән туганлашып беткәннәр. Әнисенең атасы, Нәби бабай бәетче булган. Авыл балалары аның җыр-риваятьләрен тыңлап үскәннәр. Нәби бабай исә, башта үз бабаларыннан тыңлап үскән бәетләрне сөйләсә, соңрак үзе дә чыгара башлый. Ул гарәп графикасын яхшы белгән, Корьән укыган. Шәрфүк әби дә бу бәетләрне мәңгелеккә исендә калдыра. «Әнием дә, бабасы кебек, бәетләр чыгарырга оста иде», – дип сөйли Шәрфүк Рәҗәп кызы. Шәрфүк апа бабаларының традициясен дәвам итә. Ул тормыштагы төрле вакыйгалар турында бәетләр яза. Аның бәетләре дә халыкның тарихын, аның тормышында булган зур һәм катлаулы вакыйгаларны реаль җирлектә, халык идеаллары нигезендә яктырта. Һәм, һичшиксез, алар биредәге халыкның рухи байлыгын чагылдыра.

Бүгенге көндә Шәрфүк Әгъләмова бу төр жанрны саклап килә һәм бәетче ата-бабаларының дәвамчысы булып тора. Бәетләрне ул мелодик һәм тематик структураларын саклап яза. Мәсәлән «Афган» (1985 ел) бәетеннән өзек:

Күпме безнең батыр улларыбыз
Афган илендә башын иделәр.
Кемнең ялгыш эшләре өчен
Безнең балалар әрәм булдылар.

Нәрсә өчен сугышканын белми,
Миңа балам хатлар язасың.
Әнкәй, бәгърем, дошман көчле диеп,
Төшләремә көн дә керәсең...

Шәрфүк апаның əти-əнисе дә бик укымышлы булганнар, мәдрәсәдә укыганнар. Октябрь инкыйлабы башлангач Рәҗәп абый большевиклар партиясенә керә, коллективлаштыруда һәм кулакларны атуда катнаша. Соңрак аны колхоз председателе итеп куялар. «Халык дошманы» дип Рәҗәп абый белән Гайшә апаны Нарымга сөргенгә җибәрәләр. Көч-хәл белән сөргеннән качып котылып, гаилә Красноярск шәһәренә урнаша. Бу коточкыч вакыйгалар хәзер дә Шәрфүк Рәҗәп кызының хәтерендә әле. Авыр булса да гаилә тиз арада яңа урынга күнегә. Монда алар җир алып бәләкәй генә булса да йорт салып чыгалар. Әти-әнисе аны еш кына циркка йөрткәннәр, хәтта цирк түгәрәгенә дә биргән булганнар.

Ләкин 1938 елны гаилә башлыгын тагын алып китәләр. Гайшә тиз арада йортны сатып, туган авылына – Умавылга кайта. Бер елдан Рәҗәп абый да туганнары янына кайта. Шәрфүк балачактан ук «халык дошманы» кызы дигәннән куркып яши. Яшь чактагы хәсрәт, кимсенү һәм куркулар Шәрфүк әбине гомер буе озата килгән күрәсең. Әлеге чорның йөрәк әрнүләре аның башлангыч иҗатында да чагылыш таба.

Том суларын эчтем мин.
Умавылда тудым мин.
Күп тормадым авылыбызда
«Враг народа» булдык без.

Тигез туры юлга куябыз дип
Тигез җирне бүлделәр.
Җиң сызганып эшли башлагач,
Кунак дип озаттылар.

Су өстендә яфрак
Агып килә ялтырап.
Совет илендә яшәдем
Куркып, качып, калтырап, –

дип яза соңрак ул үзенең балачагын искә төшереп.

Беренче сыйныфка Шәрфүк 9 яшьтә генә бара. Бу – фашистлар Германиясе илебезгә каршы сугыш ачып, Бөек Ватан сугышы башлаган чор. Гаилә Томск шәһәренә күченгәч, кызны 20 нче санлы татар мәктәбенә бирәләр. Шәрфүк өчен татар һәм рус теле бик җиңел бирелә.

7 нче сыйныфны тәмамлагач Шәрфүк келәм тукырга өйрәнү өчен укырга керә, 6 айдан эшли башлый. Кул белән келәмнәр тукый. Шәрфүк Рәҗәп кызының йортында бу келәмнәрне хәзер дә күрергә була. Бу бик күп көч таләп итә торган эш. Җитмәсә, эш хакы яшь кыз өчен бик аз була. Нәкъ шул елларда Шәрфүк рус хорына йөри башлый, җырлап коллектив төрле призлы урыннар да яулап өлгерә.

Бервакыт кызга Мияссар исемле егеттән хат килә. Кемдер Мияссарга Шәрфүкнең адресын биргән була. Яшь егетнең татар кызы белән танышасы килгән. Хат аша аралашу башлана. Беренче очрашу офицерлар йортында бию кичәсендә була. Яшьләр беренче күрешүдән бер-берсенә гашыйк була. Һәм 1953 елны Мияссар Мөбәрәк улы Әгъләмов һәм Шәрфүк Рәҗәп кызы Понамарева язылышалар. Яшь гаиләгә тиз арада квартира бирәләр. Мияссар төрле музыка коралларында – мандолинада, гармунда, фортепианода уйный. Гаиләдә 2 бала – малай һәм кыз туа.

1958 елны Шәрфүк яңа гына ачылган «Эмальпровод» заводына эшкә урнаша. Бу елларны татар халык коллективлары булмауга карамастан, татарлар барыбер бер-берсендә җыелып җыр җырлап, туган телдә сөйләшеп, кичәләр уздырганнар икән.

1960 елларның урталарында Томск шәһәренең татар бистәсендә Ситек Понамарева йортында татар коллективы оеша. Алар татар авылларында концерт куеп йөри башлыйлар. Коллектив җырлап, биеп, спектакльләр куеп йөри. Ситек апа концертларның алып баручысы була. Ул Муса Җәлил һәм башка татар

шагыйрьләренең шигырьләрен сәхнәдә укый. Бу коллектив, ни сәбәпледер, бер елдан таркала.

Бүгенге көндә Шәрфүк Рәҗәп кызы «Халык моңнары» ансамбленә йөри. Ансамбль Томск өлкәсе халкын татар халык җырларына, матур шигырьләргә бай чыгышлары белән куандырып тора.

Шәрфүк Рәҗәп кызының репертуарында халык җырлары бик күп. Бөтен татар халкы яратып җырлый торган «Ашказар», «Ай урагым», «Зөләйлүк», «Сарман буе» һ.б.

Элек әби-бабайларыбыз «истәлек (көндәлек) дәфтәрләре» ачып, үзләре ишеткән җырларны һәм сөйгәннәре язган мәхәббәт шигырьләрен теркәп барганнар. Шәрфүк әбинең да шундый дәфтәре бар. Анда җырлар, бәетләр, шигырьләр, хат җырлары тупланган.

Шул дәфтәрдән язып алган җыр үрнәкләрен сезгә дә тәкъдим итәбез.

## ҖЫРЛАР

## Хат һәм истәлек дәфтәрләре җырлары

* * *

Аклы ситсалар ак була,
Үзгәрми ул һәрвакыт.
Җир йөзендә сау-сәламәт
Яшә, дустым, һәрвакыт.

* * *

Исеңдәме, дустым, моңсу кичләр,
Сагнуларны уйлап килгәннәр.
Исеңдәме, дустым, икәү бергә
Мәктәпләрдә уйнап йөргәннәр.

* * *

Бөтен гөлем арасыннан
Мин яратам кынаны,
Яратмас идем кынаны,
Сиңа ошатам мин аны.

* * *

Ефәк яулык җиңел була,
Җилгә чыксаң җил ала.
Син дустыма ядкәр булып
Шушы кулъязмам кала.

* * *

Иртә торып чыксам,
Яшел үләннәр тездән,
Мәңге-мәңге, мәңгелеккә
Айрылмас идем сездән.

* * *

Күк күгәрчен күчеләдем
Җиргә төшә җил өчен,
Әй, дускаем, өз(е)лә эчем
Бер сөйләшер сүз өчен.

* * *

Аллар итәрбез әле,
Гөлләр итәрбез әле.
Киләчәктә альбомыңны
Чәчәк итәрбез әле.

* * *

Сандугач бала чыгаргач,
Баласын кагындыра,
Бергә чакта берни түгел,
Айрылгач сагындыра.

* * *

Җәй көнендә куаклыктан
Тотып алдым пар куян,
Гомерлеккә онытмаска
Истәлек язып куям.

* * *

Җырлар язам өстәлдә
Ай яктысы төшкәндә,
Сагынган чакта укырсың,
Мин исеңә төшкәндә.

* * *

Бу җырларны язган чакта
Каләмем камыш иде,
Шәрфүк дустым, ачуланма,
Эшем ашыгыч иде.

* * *

И, искән бул, искән бул,
Дәрья суын эчкән бул.
Шуның белән тәмам итәм,
Хуш, дускаем, исән бул.

* * *

Хатлар яздым өстәлдә,
Исләремә төшкәндә,
Син дә миңа хат язарсың
Исләреңә төшкәндә.

* * *

Иртә торып хатлар язам,
Тибрәтәм каләмемне,
Иртәнге җил, кичке салкын –
Җибәрәм сәламемне.

* * *

Очып бара күгәрчен,
Түше яшел, күрәсең,
Хуш бул, туган, язган хатым
Үзем кебек сөйләсен.

* * *

И, дускаем, хат язгансың,
Энҗе кебек тезгәнсең.
Мин укыдым да еладым
Ничек үзең түзгәнсең.

* * *

Биек тауның башларында
Бәйләнмәгән ат йөри,
Мин саргаеп үләр идем,
Арабызда хат йөри.

* * *

Урамыгыз бормалы,
Урап чыгып булмады.
Әй, дускаем, гаепләмә,
Матур язып булмады.

* * *

Йомшак таң җилләре искән чакта
Ал сачаклар башын иярләр.
Йомшак кына искән таң җилләре
Миннән сәлам сиңа диярләр.

* * *

Өстәлләрдә сары лимон,
Сары май дисең мәллә.
Туганкаең чит илләрдә
Сагынмый дисең мәллә.

* * *

Биек тауның башларында
Тотып алдым пар куян.
Син дустыма истәлеккә
Җырлар да язып куям.

* * *

Алдым каләм, яздым сәлам,
Калсын әле бер сүзе.
Сагынганда бер укырсың,
Бәлкем булмам мин үзем.

**Уфа хәтирәләре**

Уфа диләр, Уфа диләр,
Уфа күренәме соң?
Ничә еллар мин ялгызым,
Күңел сүреләме соң.

Уфа юллары пыяла,
Таш булса таймас иде.
Минем йөрәккәем яна,
Сез булса янмас иде.

* * *

Уфа диләр, Уфа диләр,
Уфа күренәме соң?
Сагнам илкәемне,
Сезгә беленәме соң?

* * *

Уфадан килгән атлардан
Су тама ялларыннан.
Бер дә җибәрәсем килми
Сезне күз алларымнан.

**Кыска җырлар**

Өстәл өсте бигрәк матур –
Закускага кыярың,
Эчәр өчен мин килмәдем,
Булсын якты чыраең.

* * *

Стенада ике көзге,
Матур күрсәтә йөзне.
Кич утырган чакларымда
Гел уйлыймын мин сезне.

* * *

Агып килә, йөзеп килә,
Әллә дуслар күбекме?
Күп эзләдем, табалмадым,
Дуслар, сезнең кебекне.

* * *

Ишек алдыңа кергәндә
Бакчаңа да кергәлә.
Минем туганым бар диеп,
Исеңә төшергәлә.

* * *

Менә сиңа матур сачәк,
Күкрәгеңә кадарсың.
Мине сагынган чагыңда
Шул сачәккә карарсың.

* * *

Биек тауга менгән чакта
Утырдым яшел ташка.
Күңелләрем сезнең белән,
Яшимен сездән башка.

* * *

Биек тауның башларында
Йөри куй көтүләре.
Кинәт кенә авыр була
Аерылып китүләре.

* * *

Су буенда күп йөредем
Сусаган филләр кебек,
Икебез ике якларда –
Айрылган гөлләр кебек.

* * *

Чәчләремне үрер идем,
Тарак юк бит тararга.
Ай да биек, баскычы юк,
Сагынганда карарга.

* * *

Агыйделдә ак кораб,
Утырам алга карап.
Бер генә сүз әйтер идем
Сезнең якларга карап.

* * *

Айкаладыр чайкаладыр,
Кер юганда beләгем.
Тормышыңда рәхәт яшә,
Шул беренче теләгем.

* * *

Ак пароход эчләрендә
Танцевать итсәң иде.
Сезнең нурлы йөзегезне
Рисовать итсәң иде.

* * *

Йөзегезгә, йөзегезгә
Йөз карадым, туймадым.
Мин сезне нурдан яратылган
Мәллә диеп уйладым.

* * *

Әнкәем, ник таптың
Ник таптың да, ник саттың?
Мине сатыпниләр алдың,
Газиз баласыз калдың.

* * *

Ак эшләпә, күк эшләпә,
Московский эшләпә.
Ике генә пәтер[1] биреп
Көне буе эшләтә.

* * *

Зәңгәр һава, зәңгәр диңгез,
Зәңгәрләтә диңгезне,
Зәңгәр һаваларда йөзгән
Айлардан эзлим сезне.

---

[1] *Пәтер (бәтер)* – лепешка.

* * *

Уй бит ул уйландыра,
Җыр бит ул җырландыра.
Тормыш бит ул матур чәчкә –
Вакытсыз коелдыра.

* * *

Ак тапочка, ефәк носки,
Дачада кия торган.
Син бит минем роза гөлем,
Мәңгегә сөя торган.

* * *

Ике каен янәшә –
Яфраклары шаулаша.
Ике туган бергә килсә,
Кошлар кебек сайраша.

* * *

Авылларның ишекләре
Звоноксыз ачыла,
Авылыма кайтым җитсәм
Күңелләрем ачыла.

* * *

Урамдагы капкагызны
Яшелләргә буягыз.
Пожалуйста үзегезне
Әллә кемгә куймагыз.

* * *

Түгәрәк күл өсләрендә
Тезлеп йөри ак кошлар.
Ниләр генә күрсәтмәде
Башка төшкән язмышлар.

* * *

Утырам да башым чайкыйм,
Күргән күрмешләремә.
Тагын да ниләр күрәсем бар
Калган тормышларымда.

* * *

Атларны күркәм күрсәтә
Томский дугалары.
Кайда барсак, шунда кирәк
Ата-ана догалары.

* * *

Эх, дускаем, беләсеңме,
Кайсы гөлдә сачка күп.
Кына гөлемдә чәчәк куе,
Уйлама гомер буе.

* * *

Пыяла ишек буш була –
Ачыладыр җил сукса,
Сез барда мин сезгә карыйм,
Мин нишләрмен сез юкта.

* * *

Яшел тәрәзә төпләрендә
Бөглә, сыгла гөлләрем.
Үлсәм дә сине эзләрмен,
Тар булса да гүрләрем.

* * *

Алсу алма, алсу алма,
Алсу алма сулата.
Без түгел, кошлар айрыла,
Дустым ямансулама.

* * *

Сөйләсеннәр, сөйләсеннәр,
Сөйләсеннәр, түзәрбез.
Араларны су басса да,
Аккош булып йөзәрбез.

* * *

И, дускаем кәрзин үрә,
Яңа камышлар белән.
Танышкансыз, кавыгышыз
Яңа танышлар белән.

* * *

Күгәрчен күкрәге төсле
Күлмәгең булмас иде.
Икең ике илдә булгач
Күңелле булмас иде.

* * *

Тормыш түтәлемә чәчәк өстә,
Дәшми генә өстә, дускаем.
Бер кешегә бер яхшылык эшлә,
Бер изгелек эшлә көн саен.

* * *

Урманнарга кереп җил тынса,
Урман түбәсенә ай кунса,
Тал буендагы әрәмәләр,
Мине сагына кебек кич булса.

* * *

Болыннарга чыгам, тау буена,
Том суларын күрергә.
Мин чәчәкләр җыям сабан туена,
Мин матурлык эзлим гомергә.

**Күк күгәрчен**

Күк күгәрчен, бик чибәрсең,
Хат тагам канатыңа,
Күк күгәрчен, оч еракка,
Биек таулар артына.

Күк күгәрчен, бар еракка,
Җилләр искән якка бар.
Партизаннар каннар түгеп,
Сугыш үткән җиргә бар.

Бар, күгәрчен, бар еракка,
Кояш чыккан җиргә бар.
Батыр егет, данлы егет
Постта торган җиргә бар.

Кич утырып хатлар язам
Батыр егет өчен мин.
Күк күгәрчен, алып барып
Минем якты сәламемне сөйләрсең.

## Чистай көенә

Һаваларда очкан ак кошларның
Карап калдым очып китүен,
Авыр булды сине озатуы
Тагын да авыр сагынып көтүе.

Том сулары буе яшел чирәм,
Мин аларны бик күп таптадым.
Чын күңелемнән өзлеп сөйдем сине,
Аңлашырга сүзләр тапмадым.

Һаваларда очкан ак кошларның
Каурыйлары җиргә коела.
Сугыш кырларында үлеп калгач,
Үле гәүдәләрең кем алган.

Күптән инде синең хатларыңны
Почтальоннар миңа китерми.
Күпме генә сагынып еласам да,
Ул елаулар сиңа ишетелми.

Җәйге көннең алсу иртәсендә
Тал кошлары сайрый өзлексез.
Үлгән хәбәреңне ишетсәм дә,
Кайту көнең көтәм түземсез.

Һаваларда очкан ак кошларның
Каурыйлары коела күлләргә.
Хаты да юк, җылы сүзе дә юк
Сагнып кына калды сөйләргә.

## Ике егет – ике кыз

1 нче егет:

Алай итәбез, давай,
Болай итәбез, давай.
Әнә килә ике гүзәл,
Кайсын сөябез, малай.

2 нче егет:

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр патрон.
Үзем ямьсез булмаганга,
Сөям кызның матурын.

1 нче кыз:

Алай итәбез, давай,
Болай итәбез, давай.
Берсе агай, берсе малай,
Кайсын сөябез, малай.

2 нче кыз:

Дустым, синең күңлең кемдә?
Минем күңлем гел синдә.
(егеткә)
Әгәр күңлең миндә булса
Салма күзең һичкемгә.

2 нче егет:

Өсләрендә аклы күлмәк,
Башларында ефәк шәл.
Берүземә ике гүзәл –
Берсен сөйсәм, берсе жәл.

1 нче егет:

Карале, малай, карале,
Таң чулпаны күренә инде.
Берсе сиңа җитәр инде,
Берсен миңа бир әле.

2 нче егет:

Китче моннан, монда йөрмә,
Онга төшкән таракан.
2 нче кызга:
Зинһар, дустым, үпкәләмә,
Сине генә яратам.

2 нче егет:
Биек тауның башларында
Бата торган талым бар.
1 нче егеткә:
Синең яр таба алмаганыңа
Минем ни кайгым бар?

1 нче егет:
Нигә болай акырасың,
Сиңа тагын ни җитми?
Берүзеңә ике ярны
Закон позволять итми.

1 нче кыз:
Җаныкаем, җәйгә чыксаң,
Җәй келәткә урныңны.
2 нче егеткә:
Миндин артык яр тапмадың,
Бик күтәрмә борыныңны.

2 нче егет:
Дустым, синең йөзкәйләрең
Күзләрне чагылдыра.
2 нче кызга:
Әйдә китик исполкомга,
Исполком кавыштыра.

1 кыз:
Сикереп-сикереп пешә
Бәләкәй генә чүлмәктә.
1 нче егеткә:
Бәләкәй булсын, матур булсын,
Үсәр әле яшь чакта.

2 нче егет:
Ике ат җиктем, арбасын
Алты ат тарта алмаганга.

Ярымны подарить итәм,
Яр таба алмаганга.

1 нче егет:
Дустым, синең йөзкәйләрең
Күзләрне чагылдыра.
1 нче кызга:
Әйдә китик исполкомга,
Исполком кавыштыра.

**Сәрмән буе**

Сәрмән буйкайлары бигрәк матур,
Урманында сайрый сандугач.
Сәрмән көйләренә җырлар җырлыйм,
Сез дусларны өзлеп сагынгач.

Сәрмән яланнары бик зур ялан,
Печәннәре җитәр бер заман.
Бергә яшәүләре бик күңелле,
Аерым яшәүләре бик яман.

Сәрмән буйкайларына барырсыңмы,
Тыңларсыңмы җырлар җырласам?
Күзләреңне тутырып карарсыңмы,
Зәңгәр таудан яулык болгасам?

Сәрмән буйларында бик күп йөрдем,
Ләкин суын эчеп туймадым.
Әйтер сүзләремне әйтә алмадым,
Тагын да күрешербез дип уйладым.

Сәрмән буйлары тугай-тугай,
Тугаенда сайрый бер тургай.
Иртәсен дә сайрый, кич тә сайрый,
Саргаеп үлсен ди бугай.

Сәрмән буйкайлары киртләч-киртләч,
Киртләчләре бетәр яз җиткәч.
Ир балалар кайта хезмәт иткәч,
Кыз балалар кайтмый бер киткәч.

Сандугачлар гына боегып сайрый
Сәрмән буйларында тирәктә.
Сиңа булган яшьлек мәхәббәте
Үрелеп сачәк атадыр йөрәктә.

Сәрмән буйкайларын буйлаганда
Каралыдан күлмәк кимәдем.
Яшьлегемне сиңа бүләк итәм,
Синнән башкаларны күрмәдем.

Сәрмән буйкайлары бик зур ялан,
Печәннәре җитми атларга.
Эчкәйләрем тулы кайгы хәсрәт,
Белдерәсем килми ятларга.

Сәрмән буйларына бергә барыйк,
Бергә төшеп бергә йөзәрбез.
Бергә тумасак та, бергә үстек,
Аерылышкач ничек түзәрбез.

Иртә торып бер сызгырдым,
Печән покосларым кипсен дип.
Бер әйтмәсә әнкәй, бер әйткәндер,
Гомерләрең читтә үтсен, дип.

Сәрмән буйларында бик күп йөрдем,
Кулларымны юдым суында.
Синең өчен тудым, синең өчен үстем,
Синең өчен яшимен дөньяда.

**Дусларга**

*(«Городок» көенә)*

Городокның тавы биек
Алма тәгәрәтергә,
Дусларымның хәт(е)ре калган,
Ничек бәхилләтергә.

* * *

Әй, дусларым, дусларым,
Дусларым, дус ишләрем.
Сез дуслардан аерылсам да,
Ялгыз башым нишләрем.

* * *

Дустым алма, дустым хөрмә,
Дустым кура җиләге.
Аша да эч, уйна да көл,
Бетмәс дөнья кирәге.

* * *

Дуслар җырлый әле
Сыз(ы)лып таңнар атса да.
Үткән гомер кире кайтмый,
Сулар кирегә акса да.

* * *

Бөрлегәннәр, төрле үләннәр
Юл буйларында гына.
Якты йөзләр, матур сүзләр
Сез дусларымда гына.

* * *

Кульяулыгым күлгә төште,
Күлгә төште, күмелде.
Әй, дусларым, бергә яшик,
Бергә яшәү күңелле.

* * *

Чыксын болыт, яусын яңгыр,
Китсен урман буена.
Сезнең белән безнең дуслык
Житсен гомер буена.

* * *

Ак каенның ботагына
Тайлар бәйләсәң иде.
Җыйнаулашып, бергәләшеп
Җәйләр җәйләсәң иде.

* * *

Каен яфрагы кебек
Түгәрәк булсаң иде.
Бер сөйләшеп кайтыр өчен
Күбәләк булсаң иде.

* * *

Кайдан килдегез сез безгә
Батмаенча диңгезгә.
Кадерле кунак сез безгә,
Ни хөрмәт итим сезгә.

* * *

Биек икән тавыгыз,
Каршы ява карыгыз.
Без килдек тә кунак булдык,
Инде үзегез барыгыз.

* * *

Гармуныңны тартып уйна,
Без җырлаган көйләргә.
Без җырлаган, син уйнаган,
Калсын саг(ы)нып сөйләргә.

* * *

Яшь гомерне уза диләр,
Узганын күрсәң иде.
Узган чакта тотып алып
Кирәген бирсәң иде.

* * *

Әнә килә автомобиль –
Төягәннәр таш күмер.
Әкрен генә, сиздермичә
Узып бара яшь гомер.

* * *

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырлап ачыла күңел.
Җырлап ачылмаса күңел,
Мәңге ач(ы)лачак түгел.

* * *

Томскидан килдеңме?
Омскидан килдеңме?
Мин сагынганны белдеңме?
Үзең саг(ы)нып килдеңме?

* * *

Умавыл урамнары
Уйный җил-бураннары.
Сагынганда сөйләшергә
Юк бит телефоннары.

* * *

Яшел тәрәзә төпләрендә
Бөг(е)лә-сыг(ы)ла гөлләрем.
Үлсәм дә сезне эзләрмен
Тар булмаса гүрләрем.

* * *

Каләм саплары сөяктер,
Язучылар сирәктер.
Читкә китеп ялгыз калсаң,
Дусларың бик кирәктер.

* * *

Сөйләсеннәр, сөйләсеннәр,
Сөйләсеннәр, түзәрбез.
Араларны су басса да,
Ак кош булып йөзәрбез.

* * *

Поездга утырмагыз,
Поезд алып китә.
Алып китеп чит илләргә
Бер күрергә зар итә.

* * *

Утыр, дустым, урындыкка,
Аякларың талмасын.
Уйнап-көлеп әйткән сүзгә
Хәтерләрең калмасын.

* * *

Ак самовар борыннары
Борылып агулары.
Сиңа ничек, миңа читен
Айрылып калулары.

* * *

Сине озатып барганда
Карадың син кайрылып.
Мәк чәчәге өзгән кебек,
Калдым бит мин айрылып.

* * *

Мәк чәчәге коела
Былбыл кайрылган саен.
Мәк чәчәгенә мин карыйм
Сине сагынган саен.

* * *

Иртә торып тышка чыксам,
Халык бара базарга.
Вакытларым тыгыз булды,
Матур гына җырларга.

* * *

Аклы ситса күлмәгемне
Кимәгән булыр идем.
Читкә китәсеңне белсәм,
Сөймәгән булыр идем.

* * *

Ак кофтыга кара юбка
Сатып алырбыз әле.
Бер-ике ел берни түгел,
Көтеп алырбыз әле.

* * *

Иртә торып тышка чыксам,
Яшел үләннәр тездән.
Мәңге-мәңге мәңгелеккә
Айрылмас идем сездән.

* * *

Сандугач бала чыгарса,
Баласын кагындыра.
Бергә чакта берни түгел,
Айрылгач сагындыра.

* * *

Өстемдәге күлмәгемнең
Җиң ягы уелмаган.
Йөзегездә кояш нуры,
Ай гына куелмаган.

* * *

Мәңге нур эчендә булсын
Дуслар, сезнең йөзегез.
Матур итеп чәчкә атсын
Киләчәк гомерегез.

* * *

Тәрәзә төбем исле гөл,
Иснә, дустым, исле ул.
Уртасында бер чәчәк бар,
Өзмим, сезнең төсле ул.

* * *

Иртә торсам, исерәм
Исле гөл исләренә.
Исле гөлдәй бөг(е)леп төшәм
Исләремә төшкәндә.

* * *

Айга карыйм, айга карыйм,
Ай да түгәрәк микән?
Бер күреп сөйләшер өчен
Булсаң иде күбәләк.

* * *

Уйсу җиргә су җыела,
Кыр казлары коена.
Сезнең алдагы тормышлар
Бик күңелле тоела.

* * *

Самовар куйдым кайнатып,
Кыйблаларга каратып.
Айлар түгел, көннәр түгел,
Еллар йөрдем яратып.

* * *

Чәйләр эчәсем килгәндә
Самовар да кайнамый.
Бик сагынган көннәремдә
Кош та килеп сайрамый.

* * *

Соболинный шапкаларны
Кисәң ни, кимәсәң ни.
Кешедән калгән ярларны
Сөйсәң ни, сөймәсәң ни.

* * *

Нәрсәдер бар яшерен
Нәрсәдер тарта сиңа.
Нәрсәгәдер, күргән саен,
Мәхәббәт арта сиңа.

* * *

Кар бит ак бит, кар бит ак бит,
Карны ашап булмый бит.
Җыр бит җәл бит, җыр бит җәл бит,
Җырны ташлап булмый бит.

* * *

Утырсам уйларга батам,
Кулымда кош уйнатам.
Моңаеп сайраган кошны
Сез дусларга ошатам.

* * *

Күк күгәрчен күктә уйный,
Күләгәсе җирдә уйный.
Минем күңлем сине уйлый,
Синең күңлең кемне уйлый?

* * *

Каз канаты кат-кат була,
Ир канаты ат була.
Читкә китеп малсыз кайткан
Туганнарың ят була.

* * *

Җәйгә чыксам, кәсебем шул
Кырларда кош уйнатам.
Моңаеп сайраган кошны
Сез дусларга ошатам.

* * *

Дуслар, сез икәнсез,
Танымыйча торамын.
Иртәнге ал чәчәккә
Ошатып утырамын.

* * *

Сезне былбыл дияр идем,
Очып гөлгә кунсагыз.
Күкрәгемдә йөртер идем,
Төрле чәчкә булсагыз.

* * *

Сөям сине, сөям сине,
Сөям сине, чәчәгем.
Сөямен сине, чәчәгем,
Мәңгегә сөячәгем.

* * *

Уйныйк әле, җырлыйк әле,
Сыз(ы)лып таңнар атса да.
Узган гомер кире кайтмый,
Сулар кирегә акса да.

* * *

Без үскәндә үскән идек
Гөл тамырлары кебек.
Үсеп җитсәк таралыштык
Кош балалары кебек.

* * *

Гөлкәбирә көлтә бирә
Арбадан кибәнләргә.
Мине дисәң, мине сөйсәң,
Сер бирмә бүтәннәргә.

* * *

Җиде лампа якты яна,
Эчендә мае булса.
Безгә дуслар җырлар әле,
Эчендә җаны булса.

* * *

Болар кайдан килгәннәр,
Җиңсез камзол кигәннәр.
Болар безгә ятлар түгел –
Үзебезнең туганнар.

* * *

Сандугачым-былбылым,
Кичә кайларда булдың.
Бөтен дөнья малын биреп
Сатып алырдай булдым.

* * *

Әй, яшь чагым, яшь чагым,
Яшь чагым – чәчкә чагым,
Никадәрле уйласам да,
Әйләнеп кайтмас тагын.

* * *

Атымның дагасы алтын,
Сынса да алыштырмам.
Үзем үлми, гүргә керми
Ятларга алыштырмам.

* * *

Гөлләреңне куе утыртма,
Яфрагы сирәк булыр.
Кайгың булса да, җылама,
Күзләрең кирәк булыр.

* * *

Әй, дусларым, җырлыйм әле,
Күтәреп җибәрегез.
Авыр сүзләр ишетсәгез,
Үткәреп җибәрегез.

* * *

Җырлыйм әле, җырлыйм әле,
Җырчы хатын мин түгел.
Кычкырып җырлап җибәрсәм,
Җырчылардан ким түгел.

* * *

Җыр бит ул җырландыра,
Моң бит ул моңландыра,
Яшьлек бит чәчкә кебек
Вакытсыз шикләндерә.

* * *

Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Гармун кулларыбызда.
Исле гөлләр чәчкә атсын
Йөргән юлларыбызда.

* * *

Сезнең урам – урам мени?
Вот безнең урам урам.
Утырган урыныгыз белән
Сатып алырдай булам.

* * *

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Фатыйма.
Нинди җырлар җырлыйм икән
Сез дусларым хакында.

* * *

Агыйделдә ак кораб,
Утырам алга карап.
Бер генә сүз әйтер идем
Сезнең якларга карап.

* * *

Агыйделнең буйларында
Таянам талларына.
Сез дусларны ошатамын
Сандугач баласына.

* * *

Иркәм, иркәм, дип әйтәсең,
Үзең иркәләмисең.
Үзең иркәләмәгәч тә
Мин дә иркәләнмимен.

* * *

Электрлар якты яна
Тайга вокзалларында.
Бер җибәрми тотар идем
Сезне күз алларымнан.

* * *

Җырлар җырлап, уйлар уйлап,
Йөрим Том буйларында.
Көннәр түгел, еллар буе
Сез генә уйларымда.

* * *

Учактагы утыннарым
Әйләнде ут күмергә.
Сезнең белән үткән яшьлек
Истән чыкмас гомергә.

* * *

Сез кайдан дип сорасагыз,
Без бит Арча яклары.
Башларымның нәрсә уйларга
Белми торган чаклары.

* * *

Чәч үргечем, чәч үргечем,
Чәч үргечем чыланган.
Ничә ел күрми торсам да,
Исләремнән чыгармам.

* * *

Усак яфрагы кебек
Түгәрәк булсам иде.
Бер күреп сөйләшер өчен
Күбәләк булсам иде.

* * *

Идел бит ул, Идел бит ул
Идел утравында.
Кычкырып җырлап җибәрәм
Уйлап утырамын да.

* * *

Шәл бәйләдем, шәл бәйләдем,
Шәлем түгәрәк түгел.
Яныгызга барыр идем,
Җаным күбәләк түгел.

* * *

Ырымбур шәлләре матур,
Ябынсаң иде аны.
Көн дә күрәм төшләремдә,
Күрешсәң иде тагын.

**Төртмә җырлар**

Сезнең очлар түбән булса,
Безнең очлар югары,
Кешедән көлгән буласың,
Авторитетың юк әле.

* * *

Алла бирсә, пенсияга чыксам,
Сатып алам кәҗәкәй,
Суйса ите, сауса сөте,
Налогы да бәләкәй.

* * *

Татарча кая барасың,
Урысча куда пойдешь.
Бу аракыны эчә-эчә
Пожалуй, с ума сойдешь.

* * *

Урманнарга баргансың,
Нигә чалбар кимәдең,
Аркылыга җәелгәнсең,
Нигә буйга үсмәдең.

* * *

Әнә килә автомобиль –
Төягәннәр кыярлар.
Борыныңны бик күтәрмә,
Чиләк элеп куярлар.

* * *

Урманнарга баргансың,
Усаклар кистең мәллә?
Телеграмм баганасы
Булам, диеп үстең мәллә.

* * *

Биек тауның башларында
Ап ак кошлар өшегән,
Өч тиенлек акылың юк,
Ник көләсең кешедән.

* * *

Биек тауга чыккан чакта
Өздем кар кузгалагын.
Бу җырымны яратмасаң
Бүсерең кузгаламы.

* * *

Аракыны шунсын сөям,
Мелдердәп утырганын.
Туганнарны мин яратам
Гел җырлап утырганын.

* * *

Без киябез иске күлмәк,
Яңаларга көч җитми.
Төртмә җырлар җырласаң да,
Төртмә җырдан ис китми.

* * *

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Юраман.
Күтәрелгән борыннарың
Төшәр әле бер заман.

* * *

Алтын да була кашык,
Көмеш тә була кашык.
Капка төпләренә чыгып
Тора корсагын кашып.

* * *

Ал биргәнгә ал бирмичә,
Гөл бирүче без түгел.
Тәкәббергә баш июче,
Сер бирүче без түгел.

* * *

Арбаларың майлагансың,
Буялма син дегеткә.
Кәкерәеп каткансың да
Үреләсең егеткә.

* * *

Атыңны, егет, мактама,
Син аны җәлләмисең.
Сез безгә каршы җыр җырлап,
Барыбер җиңәлмисез.

* * *

Китче моннан, монда йөрмә,
Онга төшкән таракан.
Зинһар инде үпкәләмә,
Сине генә яратам.

* * *

Без килмәдек китәргә,
Килдек гулять итәргә.
Хуҗаларның муйны калын,
Можно терпеть итәргә.

* * *

Зимагур баеп кайткан,
Пар калошларын саткан.
Ике аягын кулга тотып
Капка төбендә яткан.

## Такмаклар

Биик әле парлашып,
Әйдә, кода, алга чык.
Бие-бие, кодача,
Кодачасы кызмача.

* * *

Бие әле, баш кода,
Идәннәре таш кына.
Уйлама син, баш кода,
Кодачаң бит яшь кенә.

* * *

Тыпыр-тыпыр бас әле,
Алай гына аз әле.
Итек, читек кунычы,
Күңелем куанычы.

* * *

Әйлән-бәйлән бәйләнеп,
Чәчләр чәкчә бәйләнеп.
Әниемнең җиңгәсе,
Балдызыңның җиңгәсе.

* * *

Ал итмәсә, гөл булмас,
Гел итмәсәң, көл булмас.
Уйнап кал да, җырлап кал,
Мондый туйлар гел булмас.

**Хәдичә**

Әй, Хәдичә, Хәдичә,
Бигрәк матур карыйсың,
Матур итеп елмаясың,
Йөрәгемне өзәсең.

Әй, Хәдичә, Хәдичә,
Төшләремә керәсең.
Төшләремә син кереп,
Йөрәгемне өзәсең.

Күпме була сынарга,
Күпме була көләргә.
Әйдә киттек ЗАГСларга,
Бергә тормыш корырга.

# МАТЕРИАЛЬНАЯ КУЛЬТУРА, РЕМЕСЛА И ДЕКОРАТИВНО-ПРИКЛАДНОЕ ИСКУССТВО СИБИРСКИХ ТАТАР ТОМСКОЙ ОБЛАСТИ

*Алсу Бурганова*

История, язык, этнические особенности и быт сибирских или, как еще их называют, западносибирских татар, долгое время интересовали и продолжают интересовать многих ученых. Их изучением в XVIII веке занимались Г.Ф. Миллер[1], И.Г. Георги[2] и др. Из ученых XX – начала XXI века в изучение духовной культуры сибирских татар весомый вклад внесли этнографы: Н.А. Томилов[3], Ф.Т. Валеев[4], языковеды: С.М. Исхакова[5], Д.Г. Тумашева[6],

---

[1] *Миллер Г.Ф.* История Сибири. М., 1999. Т. 1. 630 с.; *Миллер Г.Ф.* История Сибири. Москва, 2000. Т. 2. 796 с.

[2] *Георги И.Г.* Описание всех в Российском государстве обитающих народов, также их житейских обрядов, вер, обыкновений, жилищ, одежд и прочих достопримечательностей. СПб. 1799. Ч. II: О народах татарского племени. 178 с.

[3] *Томилов Н.А.* Этнография тюркоязычного населения Томского Приобья (хозяйство и материальная культура). Томск: издательство Томского университета, 1980. 200 с.

[4] *Валеев Ф.Т.* Сибирские татары: культура и быт. Казань: Татар кн. изд-во, 1993. 208 с.

[5] *Исхакова С.М.* К вопросу о взаимоотношении языка татар-аборигенов Сибири и Казанских татар // Из истории Сибири. Томск, 1976. С. 250–254.

[6] *Тумашева Д.Г.* Язык сибирских татар. Казань, 1968. Ч. 2. 182 с.; *Тумашева Д.Г., Гилязиева А.Р.* Влияние русского языка на диалекты сибирских татар // Социально-культурные процессы в советской Сибири. Омск. 1985. С. 19–21.

А.Р. Рахимова[1], историки: З.Д. Титова[2], Г.Л. Файзрахманов[3] и многие другие. Однако выявлением особенностей развития материальной культуры и раскрытием характера ремесел и декоративно-прикладного искусства сибирских татар специально не занимались, поэтому проблема их изучения остается актуальной.

Целью статьи является попытка раскрытия данной проблематики на примере Томских татар, опираясь на имеющиеся исследования, и используя данные комплексной экспедиции, предпринятой Институтом языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова в Томскую область.

Сибирские татары состоят из трех разрозненных этнических групп – томских, барабинских и тоболо-иртышских татар[4].

Мы изучили материальную культуру и декоративно-прикладное искусство 7 татарских деревень и сел Томской области (д. Эушта, д. Кисловка, д. Черная Речка (Абытай авыл), с. Тахтамышево, д. Барабинка (Умаул), д. Казанка, с. Калтай) и Татарской слободы г. Томска, где сохранились и охраняются государством дома прошлых столетий.

Татары томской группы проживали и живут в Томском и частично соседних районах по рекам Томь и Обь. Обилие рек и озер, богатые рыбой, издавна способствовали развитию **рыболовства** у сибирских татар и у др. народов. Основными орудиями ловли служили сети, неводы, удочки (*кармак*), также широко были распространены орудия корзиночного типа, которые

---

[1] *Рахимова А.Р.* Лексика диалектов сибирских татар (сравнительно-исторический анализ промысловой и хозяйственной лексики). Казань: Мастер Лайн, 2001. 128 с.

[2] *Титова З.Д.* Барабинские татары//Из истории Сибири. Томск, 1976. Вып. 19. С. 108–147.

[3] *Файзрахманов Г.Л.* История Сибирских татар: с древнейших времен до начала XX века. Казань: Фэн, 2002. 486 с.; *Файзрахманов Г.* История татар Западной Сибири: с древнейших времен до начала XX в. Казань: Татар. кн. изд-во, 2007. 431 с.

[4] Тюркские народы Сибири / отв. ред. Д.А. Функ, Н.А. Томилов; Ин-т этнологии и антропологии им. Н.Н. Миклухо-Маклая РАН; Омский филиал Института археологии и этнографии СО РАН. М.: Наука, 2006. С. 27.

татары плели и изготовляли сами. Распространенным средством передвижения служила лодка – *обласок (кама)*, которую выдалбливали из цельного бревна. Все перечисленные орудия и сохранившиеся в оригинале лодку-обласок (1925 г. изготовил мастер Баширов Гиззат Кадырович) хранятся в краеведческом музее д. Черная Речка. Рыбаки ловили щук, хариусов, карасей, окуней, линей, чебаков, налимов, муксонов, нельму, стерлядь и др. Это было прибыльным занятием, ведь рыбу не только употребляли в пищу, ее также продавали летом и зимой в замороженном виде. Рыболовство и в настоящее время не теряет своей актуальности, только значение ее упростилось: для большинства теперь это вид отдыха, а не способ добычи.

Предки тегильдеевских татар молились кукле. Об этом тегильдеевцы говорят сами. Нам удалось у них записать сказку о кукле. Она следующего содержания: «Наши старики молились кукле, которая помещалась на вышке. Кукле приносились разного рода кушания. В нашу деревню попал татарин, сосланный из России. Он жил среди сибиряков. Однажды он залез на вышку и съел принесенное. Ему понравилось, и он стал каждый день съедать приносимое кукле. Старики радовались, что кукла съедает приношения. Он съедал сначала все. Потом стал есть то, что вкуснее. Иногда, желая переменить пищу, совсем не ел. И старики меняли пищу кукле. Один раз старики заметили, что он полез на вышку, и следом полезли за ним. Желая избежать опасности, он начал мешать землю на вышке. Поднялась пыль. Старики, увидев на вышке пыль, подумали, что куклы пляшут и ушли, довольные, обратно. Опять продолжалось для ссыльного веселое время. Он каждый день ел приносимое кукле. Но в конце концов его поймали и присудили к казни. Его привязали к хвосту лошади. Лошадь водили но улице, а он тащился по земле». С разными вариациями эту сказку рассказывают и в других татарских деревнях, прилегающих к Томску, например, в Барабинке, Тохтамыше и др.

За последнее столетие в Тегильдеевой стали селиться приезжие татары из Уфимской, Казанской и других губерний. Приезжих татар насчитывается до 75% и более. Приезжие имели сильное влияние на старожилов, и последние заметно стали ассимилироваться с переселенцами – татарами.

Тегильдеевские татары считают ясачных д. Горбуновой, Кульман и других деревень также родственными себе. Старики нам рассказывали, что в молодые годы им приходилось слышать, как их деды говорили, что у них есть «Семен-сват, Иван-сват, Мокей-сват». Совершенно обрусевшие и крещеные жители указанных деревень считались родственными тегильдеевским татарам.

С первых же дней заселения Тегильдеева приезжими татарами между ними и старожилами была рознь. Этому способствовало различие наречий татар приезжих и старожилов. Эта рознь нашла себе отражение в народном творчестве татар. Нам рассказывали, что некоторые из стариков, когда выпивали, пели непонятные приезжим татарам песни. Вот одна из них:

И Полатбе, Полатбей.
Кайда киттен, Полатбей.
Ун эшн бар, ашказар улым бар,
Алтын чачле кызм бар.
Эй, Полатбей, Полатбей.
Куда пошел, Полатбей?
Тебе какое дело.
У меня есть сын-кормилец,
И дочь – золотые волосы.

Различие языка давало поводы насмехаться над сибиряками. Нам удалось записать несколько рассказов, в которых сказалось непонимание языка друг друга. По словам тегильдеевцев, эти рассказы взяты из жизни.

По старому тегильдеевскому (сибирскому) наречию. «Ю» означает греби, по казанскому (современному) «Ю» означает «мой» (мыть).

Однажды хозяин говорит своему работнику (ссыльный из России) «бар, пчан ю» (по казански «бар, пчан жи»), иди, греби сено. Работник думал, что его послали мыть сено, т.к. «Ю» по-казански означает «мой». Он удивился, что в Сибири моют сено. Пошел на луга и стал в озере мочить сено, пока не пришел хозяин.

Вот еще подобный рассказ про другого ссыльного из России, поселившегося в Эуште.

По старому эуштинскому наречию – *тап* – «щепка» по казанскому наречию *тап* – «найди».

Ссыльный нанялся в работники к старшине (старшина назывался князем). Дочери князя дают работнику корзину и говорят: «бар, тап жиеп кер». Работник взял корзину, вышел на улицу и не знает, что найти в корзину, так как слово «тап» по-казански означает – найди. Шел по улице сибиряк, знавший наречие казанских татар. Он спросил, почему работник стоит с корзиной на улице. Работник рассказал ему о своем недоумении, что найти. Прохожий засмеялся и указал ему на щепку – тап.

В другой раз старшина послал его к соседу просить разрешения топить баню. По старому казанскому обычаю он должен был сначала·спросить разрешение войти в избу. Он открыл дверь и сказал *ассаляму галяйкум – здравствуйте* и снова закрыл дверь. В Эуште этого не знали и стали над ним смеяться. Хозяин избы сказал: «Кер касанньк» – заходи, казанец. Работник вошел и сказал: «Мурза огай, мунчанне ягарга срап кильдем – мурза, я пришел к Вам просить разрешения топить баню». По-казански мурза – князь. Поэтому работник и назвал соседа мурзой. В Эуште же мурзой дразнили соседа, так как он был ленивый. Сосед обругал хозяина работника по-татарски и сказал: «Не дал бы разрешения, но для тебя даю баню, топи». Работник же думал, что он у большого князя живет, а этот, видно, еще больший князь, что так ругает старшину.

Когда число приезжих татар стало увеличиваться, рознь доходила до вражды. Вот несколько примеров народного творчества по этому поводу.

«К а с а н к н ы н утырган уряын к ы р т а ш т а» (по казански – «К а з а н а к н ы н утырган урнын к ы р ы п т а ш л а»). Если где посидит казанец, то нужно скоблить то место.

«К а с а н н ы к кука чекса, кутена с и н е к и н я н с а й кал» – (по казански: «к а з а н н ы к кука чекса кутена с я н я к б л я н с а е п кал»). – «Если казанец вознесется на небо, то и в это время ему воткнуть надо в зад вилы».

За последнее время в Тегильдееве говорят чистым современным татарским языком. Старое наречие вытеснено. Старики-старожилы перемерли. Их потомки смешались с приезжими татарами.

В деревне Эушта мы собрали немного старинных слов: *шабала* – ложка, (кашик), *абзый* – дядя, *туш* (кукряк) – грудь, *кунек* (кульмяк) – рубашка, *итмяк* (икмяк) – хлеб и другие.

На старом наречии эуштинцев за последнее время сказывается сильное влияние языка приезжих татар. В Эуште наряду со словами старого наречия употребляются и слова современного татарского наречия.

Несомненно, все обследованное нами население – есть смешавшиеся остатки томских татар (эуштинцев, телеутов, татар, чатских и чулымских), о которых мы говорили выше. Наречия этих смешанных племен подверглись сильным влияниям других языков. Наречие татар кульманских, каргатских, канаевых, Базанаковых юрт, Оськиной – подверглось влиянию русского языка. Их потомки говорят теперь по-русски. Наречие татар д. Тегильдеевой подверглось влиянию наречия татар казанских. Тегильдеевцы все говорят современным казанским наречием, как и жители деревень Барабинка, Тахтамыш и др.

Наречие эуштинцев сохранилось. Но и оно за последнее время носит на себе следы современного татарского наречия.

## ЕРАК ЕЛЛАР КАЙТАВАЗЫ

Томск өлкәсендә яшәүче татарларның милли-мәдәни мирасы элеккеге елларда да туплана килә. 1993 елда халык иҗаты бүлегенең фәнни хезмәткәрләре Ким Миңнуллин белән Салават Мөхәммәтнуров төрле авылларда йөреп бик күп җыр текстлары, шигырьләр язып алып кайталар. Аларның кайберләрен сезнең игътибарга тәкъдим итәбез. Алар Умавыл, Кызылкаш, Яңа Исламбул, Абытай һ.б. авылларда Нурлыхәят Гайнетдинова, Миңнекамал Гыйззәтуллина, Мәгъсүмә Фәйзуллина, Шәрфүк Әгъләмовалардан язып алынган.

*Эльвира Сафина*

**Шигырь**

Яшьлек җиле исеп, йөрәкләрнең
Тибрәнәләр нечкә кыллары.
Җүләр уйлар белән чуарланып
Ишетелгәли дуслык сүзләре.

Хыялларның матур шатлык тавы
Мәңге җимерелмәскә нигезле.
Шул таудагы серләр калкуланган
Яшьлек мәхәббәтен нигезли.

Мин күбәләк булсам, җитез итеп,
Кунар идем сезнең гөлләргә.
Аңласагыз, сезгә сөйләр идем
Мәхәббәтне серле телләрдә.

Аңлыйм сезнең матур яшьлек уен,
Ләкин белмим, ни дип язарга.
Тасвирларга сезнең яшь күңелне
Мөмкин түгел сүзләр табарга.

Күбәләктәй сезнең матур яшьлек,
Хуҗа бит ул чәчәк сайларга.
Юл, бер чәчәк төркемнәре буйлап
Китү өчен әллә кайларга.

Әгәр теләгегез сайлау булса,
Чәчәкләрнең матур тезмәсен.
Яратыгыз берсен һәм нурлысын
Матураеп күзгә бәрелсен.

Беләм сезнең яшьлек фикерегезнең
Читтәлеген минем уйлардан.
Серләр сезгә сөйләсәм дә шикле,
Бармау мөмкин бердәм юллардан.

Читлектәге ялгыз кошчык кебек,
Ялгыз хис итмәгез яшь җанны.
Иң беренче сезнең тимер бурыч
Саклау җиңелмәслек вөҗданны.

Әйтер идем сезгә мактанычлы
Яшьлек дәрте җирдә калмаса.
Кояш нуры кебек алтын уйны
Сезнең караш утка салмаса.

Язам, ләкин сезгә сер түгел бу,
Тик очкыны яшьлек уемның.
Көләм, анса юк итәргә телим
Күңелләрнең яшьлек тутыгын.

Бурыч түгел миңа яшь күңелне
Чәчәк сайлар өчен димләргә.
Сез хокуклы минем язган сүздән
Тикшеренеп серләр эзләргә.

Куе томан аша күрәм сезнең
Уегызның төбе чуарын.
Килешә алмас сезнең теләк белән
Киләчәктә минем уйларым.

Мин хаклымын сезнең уегызның
Матур якларына карарга.
Рөхсәт итәсезме уйларымны
Тезеп-тезеп сезгә язарга?

Яшьлек хыяллары күзне буа,
Яшьлек өчен дөнья тарая.
Сезгә язар өчен матур сүзләр
Яшеренделәр әллә кайларга.

Матур яшьлек әллә сусыз гөлдәй,
Ялгызлык көннәре кызганыч.
Юк. Дөньядан ваз кичмим әле мин,
Алда терәк – ныклы ышаныч.

Шик юк миндә сезнең яшьлек белән
Тикшерергә төпле уйларны.
Ышаныгыз, юл киң ачык безгә,
Бергә кую өчен кулларны.

## Истәлек өчен

Сине якын итеп, шуның өчен генә,
Язамын мин шушы шигырьне.
Бөгелеп-сыгылып үскән ал чәчәкләр
Бизәсеннәр синең юлыңны.

Үтәр яшьлек, үтәр ямьле көннәр,
Калыр сагынып-сагынып сөйләргә:
Кайда минем белән бергә булган,
Бергә булган дуслар дияргә.

Бергә булган көннәр онытылырмы,
Юк... онытылмас алар мәңгегә.
Алар мәңге миндә сакланырлар,
Тик онытырсың бары син генә.

Үтәр еллар, яшьли сагынырсың,
Яшьлек истәлегең язарсың.
Шул вакытта иске дусларыңнан
Берсе итеп мине санарсың.

Былбыл балалары җиргә төшә,
Тагын алар китә кагынып.
Бергә йөргән көннәр бар иде дип
Сөйләрсеңме, дустым, сагынып.

Дустым, сиңа шигырь язар өчен,
Алдым кулга зәңгәр каләмем.
Укыганда тыңлаучылар булса,
Аларга да яшьлек сәламем.

Сахраларга чыгып аяк бассаң,
Төрле гөлләр эзләп өзәрсең.
Әкрен генә салмак җилләр иссә,
Безнең яктан сәлам көтәрсең.

Укысаң да шунда истәлекне
Искә алырсың бергә йөрегәнне.
Һәрвакытта булганбыз шат күңелле,
Бергә уйнап, көлеп йөргәнне.

Эх!... Җәй ямьле, чәчкә аланнары,
Исерәмен чәчкә исенә.
Менә, дустым, шуны язам,
Алыр өчен мине исеңә.

Иртә торсам, таң җилләре белән
Китә еракларга уйларым.
Киләчәккә соңгы сәлам итеп,
Шигырь язды минем кулларым.

## Шигырь

Сиңа бу шигырем язар өчен
Матур сүзләр эзләп карадым.
Чөнки сине матур чәчәкләрдән дә мин
Матурырак итеп санадым.

Дуслык хисе яна йөрәгемдә,
Ни өчендер, белә алмыймын.
Якын дустым, сиңа шигырь язам,
Шигырь язам, оныта алмыймын.

Тормыш мине синнән аерса да,
Еракларга алып китсә дә,
Сөйләшербез, дустым, хатлар аша,
Очрашырбыз, тормыш очратса.

Һәрбер нәрсә зәңгәр сирень кебек
Чәчәк ата исмер языңда.
Аңлыйсыңмы минем серләремне
Язып булмый монда барсын да.

Менә, дустым, сиңа истәлегем –
Кулыңа алып укып карарсың.
Әгәр аерылгач та онытмасаң,
Канат алып хатлар язарсың.

## Дустыма

Син бит минем, дустым, иртә таңнан
Йөрәгемнән утлар кабыздың.
Иртә таңнан утлар кабыздың да
Күзләремнән яшьләр тамыздың.

Мәхәббәт башы син булганга,
Өзелеп сөйдем сине, яраттым.
Яшьлек җуләрлеге белән янган чакта,
Яшь күңелне үзеңә караттың.

Башта һичкем кирәк түгел иде,
Бары сине генә күзләдем.
Синең күңелеңә ошый торган
Матур-матур сүзләр эзләдем.

Яшьлек тармагымда беркемне дә
Сине сөйгән кебек сөймәдем.
Сиңа әйткән кебек беркемгә дә
«Мәңгелеккә булам» димәдем.

Сиңа теләгем, дустым, кайгы күрмә
Көндезен дә, төнен дә.
Чәчәк кебек яшьлек гомереңне
Үткәр, дустым, шатлык эчендә.

**Сәлам дустыма**

Таңнар атып кояш чыккан чакта,
Елы яктан җилләр исәрләр.
Исәрләр дә, сине иркәләрләр,
Миннән сәлам сиңа диярләр.

Аерылулар бигрәк кыек була,
Яшь йөрәктә гөрләп ут яна.
Гәүдәләрең китми күз алдымнан,
Күзләремнән кайнар яшь ага.

Күкрәгемдә булган серле уйлар
Хәзер алар бар да сүнгәннәр.
Мин яраткан алсу йөзләреңне
Белмим, дустым, кемнәр сөярләр.

Серле матур алсу йөзләреңне
Икенче кат бәлки очратмам.
Сиңа карап сөйләшә алмамын,
Бер аерылгач, бәлки күрмәмен.

Айлар, еллар үтәр, бәлки сагынырсың,
Язган хатларымны укырсың.
Укыган чакта шушы шигырь чыкса
Укырсың да, исеңә алырсың.

Дус бул, дустым, күпләр белән
Карама син матур сүзләргә.
Вәгъдә бир син, дустым, мин үлгәндә,
Каберемә гөлләр чәчәргә.

## Ялгызлыкта

Мин ялгызым барам урманнарга,
Уйлап йөрим синең турында.
Мин бәхетле булыр идем, дустым,
Син дә булсаң минем янымда.

Тукталам да, карыйм чәчәкләргә,
Алар шундый-шундый сөйкемле,
Яшь йөрәкне мәңге сагынырлык иткән
Синең зәңгәр күзләр шикелле.

Син якында булсаң, күкрәгеңә,
Ал чәчәкләр кадар идем мин.
Күзләреңә, төпсез күзләреңә
Бер сокланып карар идем мин.

Мин һәр таңда йөрим куе урманнарда,
Зәңгәр чәчәкләргә талпынып.
Моңлы тавыш ишетәм, кемдер җырлый,
Яшьли сөйгән ярын сагынып.

Мин һәр таңда шулай тын урманда
Сине уйлап йөрим һәрвакыт.
Кайда соң син, дустыкаем,
Мәхәббәт һәм якты йолдызым.

## Шигырь

Салкын таң җилләре искән чакта
Сәлам язам сиңа, дускаем.
Сәлам синең нурлы йөзләреңә,
Сәлам сиңа, нурлы дускаем.

Таңнар атып, кояш чыккан чакта,
Безнең яктан җилләр исәрләр.
Исәрләр дә, сине иркәләрләр,
Миннән саләм сиңа диярләр.

Таң җилләре ашыгып искән чакта
Сандугачлар башын иярләр.
Сөйгән дустың ерак чит илләрдә,
Күрү өчен сапна диярләр

Сахраларга чыгып аяк бассаң
Чәчәк булып үсәрмен юлыңа.
Болай йөрү күпкә бармас,
Истәлегем бирим кулыңа.

Күкрәгеңә када зәңгәр чәчәк,
Үз кулымнан сиңа чын бүләк.
Рәхәт яшә, дустым, тормышыңда
Миннән булыр сиңа чын бүләк.

## Җавап хаты

Аерылырбыз, дустым, вакыт җитәр,
Син китәрсең ерак илләргә.
Син китәрсең, дустым, мине ташлап,
Кошлар очып җитмәс җирләргә.

Китәрсең дә, мине онытырсың,
Исләреңдә синең мин булмам.
Ни кадәрле өзелеп сагынсаң да,
Синең күз алдыңда мин булмам.

Шул кадәрле миндә кайгы булгач,
Ул чагында кайда булырсың,
Я булмаса, башым өзеп ташлап,
Үз җанымны үзем алырмын.

## Җырлар

Сагыну чишмәсеннән кайнап чыккан
Бер җыр язам сиңа, тыңларсың.
Алсу таңнар аткан чакта
Минем җырым итеп җырларсың.

Сахраларга чыгып хәл җыйсам да,
Исерәмен чәчәк исенә.
Сандугачлар чут-чут итеп сайрый,
Төшерәмен сезне исемә.

Дустым, синең күкрәгеңә
Чәчәк кадар идем, шиңәрләр.
Минем монда язган сүзләр
Йөрәк серләремне сөйләрләр.

Онытмамын сине мәңге-мәңге,
Миңа әйткән синең сүзләрең.
Киләчәктә син миңа яз
Йөрәгеңнең барлык серләрен.

Сине уйлыйм, дустым, мәңге уйлыйм,
Яшь йөрәгем әрнеп шиңгәнче.
Оныта алмам инде, дустым, сине,
Тормышыңның гөле сүнгәнче.

## Шигырь

Агыйделкәй ага, алга бара,
Айлы кичтә матур юл ала.
Яшь гомер дә шулай, аккан судай,
Дулкыннарга кереп югала.

Сагынам сине көннәр-төннәр,
Мин кайтырмын микән тиз генә.
Мин оныта алмам сине еллар буе,
Онытырсың бәлки син генә.

Әгәр күрсәм нурлы йөзләреңне,
Карар идем нурлы йөзеңә.
Сөйләр идем барлык серләремне,
Карап янып торган күзеңә.

Сау бул инде, минем яшьлек дустым,
Сау бул инде, минем сөйгәнем.
Сагынып, өзелеп сезгә хатлар яза
Яшьлек уты – синең сөйгәнең.

Сиңа язам, дустым, бу җырларны,
Сиңа булсын, миңа калмасын.
Чөнки син бит минем йөрәгемдә
Мәңге сүнмәс урын алгансың.

**Дустыма**

Их, дускаем, син бит минем
Исләремдә мәңге калырсың.
Шушы җырларны укырсың да,
Бәлки мине дә исеңә алырсың.

Чәчәкләргә кунсаң, син сайлап кун,
Күп кызыкма матур гөлләргә.
Ямьсез булсын, төссез булсын,
Якты булсын алгы көннәрдә.

Сагынам, дустым, сагынам сине,
Минем кебек беркем сагынмас.
Кайтып синең белән күрешмичә
Шат минутлар миңа табылмас.

Исемә төшерәм сине, дустым,
Сызылып алсу таңнар атканда.
Исләремнән сез чыкмассыз инде,
Язгы гөлләр чәчәк атканда.

### Вәгъдәм

Биргән вәгъдәм кире кайтмас,
Кире кайту өчен бирмәдем.
Ташламамын сине мәңгелеккә,
Ташлар өчен сине сөймәдем.

Биргән вәгъдәм минем аткан уктай,
Мәңгелеккә, кире кайтмый ул.
Син дип китек минем күңелләрем,
Үзенә тиңне һич тә тапмый ул.

Сөям сине, дустым, ташламаска,
Гомерлеккә бирәм кулымны.
Син дә бирче миңа вәгъдәңне,
Мәңгелеккә, сөям дигән сүзеңне.

### Якын дустыма

Сәлам сиңа миннән күзләреңә,
Сәлам сиңа миннән, дускаем.
Таң җилләре әкрен искән чакта
Хатлар язам сиңа, дускаем.

Сиңа, дустым хатлар язам,
Кулларымда минем каләмем.
Исеңә төшсә, бәгърем, бер укырсың,
Шушы булыр минем саламем.

Бакчаларда бер гөл ал чәчәкле,
Былбыл кунып сайрый шул гөлгә.
Соңгы сүзем, дускай, син онытма,
Мин онытмам сине гомергә.

## Шигырь

Хатлар өчен, дустым, сиңа шигырь язам,
Сагынганда, бәлки, укырсың.
Әгәр, дускай, күңелең саф булмаса,
Якын дуслар тапсаң, онтырсың.

Матур сәхрәләрдән киткән чакта
Алларыңа чәчәк кадармын.
Сине сагыну билгесе иттереп
Матур итеп хатлар язармын.

Дустыкаем, бергә булмасак та,
Мин сөярмен гомергә сине.
Онытмамын сине мәңгелеккә,
Ул ташламас иде, – дип мине.

Сиңа, дустым, кайнар сәлам язам,
Озын гомер теләп каламын.
Ялгыз башым моңлы уйлар уйлап,
Өзелеп сагынып хатлар язармын.

Сине онытмам, дустым, хәтерләрмен,
Җәйге матур таңнар атканда.
Таңнар атып, айлар батканда,
Кошлар сайрап канат какканда.

Исәр җилләр, агар салкын сулар,
Үтәр көннәр, сизми калырсыз.
Үткән көннәр исеңә төшкән чакта
Шунда мине дә искә алырсыз.

Иртән кояш чыккач, кошлар сайрар
Йомшак җилләр исәр шул чакта.
Искән җилләр сиңа сәлам әйтер,
Исеңә алырсың мине шул чакта.

Былбыл балаларын карап тордым,
Очып киткәннәрен кагынып.
Бергә йөргән чаклар бар иде, дип
Мин сөйләрмен сине сагынып.

Язгы матур кошлар сайраганда
Сәхрәләргә чыгып җырларсың.
Шунда сандугачның моңлы тавышларын
Минем тавышым итеп тыңларсың.

**Шигырь**

Иртән кояш чыккач кошлар сайрар,
Йомшак җилләр исәр шул чакта.
Искән җилләр сезгә барып сәлам әйтер,
Искә алыгыз мине шул чакта.

Сөйгән дустым, кулга каләм алып,
Саләм язам сиңа күңелемнән.
Серләр язам сиңа чын күңелдән,
Урын булса күңел түреннән.

Хатлар язам кагәз битләренә,
Тал чыбыктай бөгелә каләмем.
Сиңа бүләк итәм күкрәгемне
Кайнап чыккан дуслык сәламем.

Саләм язам, дустым, сиңа,
Ал, кадерлем, минем сәламем.
Сиңа өзелеп, дустым, хатлар язам
Аңларсыңмы икән сәбәбен?

Сәбәбе шул, дускай, якын күрү,
Онытмаслык итеп ярату.
Күккә караганда, якты йолдыз,
Сезне күрү өчен җан ату.

Көтмәгәндә тормыш дулкыннары
Алып китә кая булса да.
Шул вакытта минем бу шигырьләр
Уйлатырлар нәрсә булса да.

Язлар җитәр, дускай, карлар эрер,
Чәчәк атар алсу гөлләрем.
Шул чәчәкләр арасында йөреп
Сезне уйлап үтәр көннәрем.

Җәй көненең шунсы матур аның,
Алсуланып матур таң ата.
Хатлар язу белән генә түгел,
Шигырь күбрәк серне аңлата.

«Дустым» дигән сүзгә ачуланма,
«Дустым» сүзе сезгә карата.
«Дустым» сүзе һичбер вакытта да
Истән чыгармауны аңлата.

Минем теләк шушы булсын сиңа:
Башларыгыз моңнар күрмәсен
Тормышыңда шат һәм рәхәт яшә
Йөзләреңдә нурлар сүнмәсен.

Телим сиңа шуны, дускай
Чәчәк атсын сөйгән гөлләрең
Тиңдәш гөлләреңне шуннан табып
Шат күңелле үтсен көннәрең

Ярар, дустым, хуш, исән бул
Йомшак кулың кысып каламын
Шигыремнең иң соңгысы итеп
Җавап хаты көтеп каламын

* * *

Ак алъяпкычлар тектердем
Ике метр сатиннан.
Бәхетсез кеше аерыла
Яшьтән сөйгән ярыннан.

* * *

Җем-җем кара чәчләреңне
Уникедән үрәсең.
Синең ярларыңны сөймим
Нигә дошман күрәсең.

* * *

Өйгә керсәм, тышка чыксам,
Өшим, пиджак кимәсәм.
Дәфтәреңә язмас идем,
Син дустымны сөймәсәм.

* * *

И, дускаем, айга кара,
Мин дә айга карармын.
Синең нурың айга төшсә,
Шуннан эзләп табармын.

* * *

Иртә торып сулар сибәм,
Алмалы гөлләремә.
Рәхәт яшәвеңне телим
Алдагы көннәреңдә.

* * *

Бакчаларда үсәр әле
Парал дигән гөлләрем.
Бер айрылгач, булмас инде,
Сине күрер көннәрем.

* * *

Стенада ике сәгать,
Берсе суга унберне
Дустыкаем, сезнең белән
Яшәр идем гомергә.

* * *

Биек тауның башларына
Күгәрчен төшә уйнап.
Күз алларыма китерәм
Күңелем белән уйлап.

* * *

Ерак микән, ерак микән,
Ерак микән Исламбул?
Җырларымны тәмам итәм,
Хуш, дускаем, исән бул.

* * *

Сандугачлар күккә оча
Сайраган чакларында.
Суларга төшәрдәй булдым,
Сагынган чакларымда.

* * *

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мәймүнә.
Сезнең белән дуслыкларны
Онытмамын мәңгегә.

* * *

Сандугачлар сайрар инде,
Талларга басып кына.
Безнең сүзләр бетмәс инде
Хатларга язып кына.

* * *

Уйладым уй, уйладым уй,
Булмады бер уйларым.
Күзем йомсам, күз алдымда
Синең зифа буйларың.

* * *

Ятсам төшләремдә күрәм,
Сандугач тотканыңны.
Яшерсәң дә, беләм инде,
Нинди уй тотканыңны.

* * *

Биек тауның башларына
Минем менәсем килә.
Чын күңлеңнән сөясеңме?
Шуны беләсем килә.

* * *

Сездә, дустым, җигәләрме,
Мәскәвский атларны.
Кабул итеп аласыңмы,
Мин җибәргән хатларны?

* * *

Сүтмә, дустым, гөлләреңне,
Сүтәрсең, үрәлмәссең.
Дусларым, хурлап йөрмәгез,
Китәрмен, күрәлмәссез.

* * *

Бакчадагы гөлләр кебек
Дус күрәмен үзеңне.
Кайнар сәламнәрем белән
Бетерәмен сүземне.

* * *

Сандугачның аягына
Яшел ефәк бәйләнгән.
Кая барсам да син генә,
Күңелем сиңа бәйләнгән.

* * *

Аннан җиләкнең чәчәген
Таптап китәрсең әле.
Шул җиләк чәчәге кебек
Ташлап китәрсең әле.

* * *

Биек тауның башларында
Алмалар пешкән кебек.
Бөтен дөнья кайгылары
Өстемә төшкән кебек.

* * *

Бу дөньяда иң кадерле
Ике нәрсә бар диләр:
Аның берсе – яшьлек гомер
Берсе – сөйгән яр, диләр.

* * *

Өстәлләрдә пар тарелка,
Эчләрендә май микән.
Безгә көннәр бик ямансу,
Сезгә дә шулай микән.

* * *

Сандугачлар матур сайрый
Су буенда җәй көне.
Кая барсам да онытмам,
Алсу чәчәгем, сине.

* * *

Калды инде, калды инде
Томский калалары.
Хатларымны илтер микән
Сандугач балалары?

* * *

Кулъяулыгымны алдырдым
Җилләрдә, бураннарда.
Йолдыз булып калкыр идем
Син булган урыннарда.

* * *

Борылып киткән, сузылып киткән,
Өй артында юлыгыз.
Җырларымны тәмам итәм,
Хуш, исән-сау булыгыз!

* * *

Дәфтәреңне алгансыңдыр
Иптәшләрем язсын дип.
Мин дә сиңа җырлар язам,
Гомерлеккә калсын дип.

* * *

Биек тауның башларында –
Куш карама, куш каен.
Истәлегем начар булды,
Үпкәләмә, дускаем.

* * *

Ак пирчаткаңны ки, дустым,
Кулларың тирләмәсә.
Сөймә, дустым, сөй, дип әйтмим,
Җаннарың теләмәсә.

* * *

Биек тауның башларында
Ай түгәрәк шикелле.
Кара урманда Сак белән Сок,
Без дә шулар шикелле.

* * *

Сандугачым сайрар әле,
Америка күлләрендә.
Юк канатым, очар идем,
Сагынган көннәремдә.

* * *

Матур яз җитәр инде,
Кар эреп бетәр инде.
И, дускаем, яшь гомерем
Сине уйлап үтәр инде.

* * *

Аклы ситса күлмәгемнең
Җиңенә ал кыстырам.
Кешедән калган ярларны
Сөюләре страм.

* * *

Аклы ситса күлмәгемне
Кисәң ни, кимәсәң ни.
Кешедән калган ярларны
Сөйсәң ни, сөймәсәң ни.

* * *

Кара пальто, кара яка
Минем киясем килә.
Дустым синең йөзләреңне
Минем күрәсем килә.

* * *

Яшь вакытта шунсы рәхәт –
Бергә гомер итәргә.
Тормыш мине мәҗбүр итте
Сезне ташлап китәргә.

* * *

Җиде ятам, җиде торам,
Җиде төн уртасында.
Дустыкаем, ташлаштык бит,
Дошманнар аркасында.

* * *

Тәрәзәңнең фәрдәләре
Нинди фәрдәләр икән?
Йөриләр дә, кавышалар
Нинди бәндәләр икән?

* * *

Алъяпкычым киң генә,
Ике бавы тиң генә.
Кара кашым карлугачым,
Дөньяда бит син генә.

* * *

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Әнүәр.
Йөрәгемнең януына
Син салдың бит әрнүләр.

* * *

Безнең лампа якты яна,
Пыяласы кызганга.
Сагынганда хат яз, дустым,
Кулларыңны кызганма.

* * *

Кара бөдрә чәчләреңне
Кипкә беләп сыйпап ки,
Чәчкәләрдән чәчкәләргә
Үрелмәслек булсаң, сөй.

* * *

Фуражкаңны күтәреп куй,
Кара чәчең күренсен.
Сөймәс булсаң, әйт тизрәк,
Күңелләрем сүрелсен.

* * *

Ефәк яулык башта тормый,
Булавка кадамасаң.
Син минеке, мин синеке,
Ятларга карамасаң.

* * *

Ишек алдым сары салам,
Илтеп сарайга салам.
Җитәр инде, тәмам итәм,
Чын бәхет теләп калам.

## Кемгә сөйлим

Кемгә сөйлим серләремне,
Йөрәгем ялкын кебек.
Ялкынланган йөрәгемә
Берәү бик якын кебек.

Иделкәем, суың бигрәк җылы,
Эссе көндә чумып йөзәргә.
Синең белән үткән айлы кичләр,
Калды ахры сагынып сөйләргә.

Кулларыма чәчәк җыйдым,
Аллы-гөллесен генә.
Исләремдә гел син генә,
Бәгърем, белмисең генә.

Безнең янда болота бар,
Гарәбә эри торган
Бер сандугач булсын иде,
Арада йөри торган.

Ал, дими күңелләрем,
Гөл, дими күңелләрем.
Синнән башка бүтәннәрне
Теләми күңелләрем.

## Онытa алмыйм

Күзләремне тутырып карап калам
Син ерактан үтеп киткәндә,
Оныта алмыйм, бәгърем, оныта алмыйм,
Күзем төшми синнән бүтәнгә.

Синең яктан искән җилләр белән
Килер сыман миңа бер хәбәр.
Бергә булган чакның минутларын
Ник сагынам икән бу кадәр?!.

Таң алдыннан моңлы кошлар сайрый
Бакчадагы яшел тирәктә.
Син дә минем сөйгән кошым булып
Саклanасың мәңге йөрәктә.

### Бик сагындым

Иртә торып тышка чыксам,
Ай күренә күземә.
Яктылыгын сиңа охшатам
Ялгызлыгын – үземә.

Агыйделдә ал кораб,
Утырдым алга карап.
Бер генә сүз әйтер идем,
Нурлы йөзеңә карап.

Сандугач, кая барасың,
Канат очын талдырып?
Очкан кошлар сайрап үтә,
Йөрәгемне яндырып.

Тал бөгелә, тал бөгелә.
Таллар тамырсыз икән.
Сандугачлар булып барсам,
Дустым, танырсың микән?

Ак иделдән үтә-үтә,
Аягым талып бетә.
Синнән хатлар көтә-көтә,
Йөзем саргаеп бетә.

Урам аша чыккан чакта
Абындым чылбырларга.
Күгәрчен дисәң, күк түгел,
Ошатам былбылларга.

Тәрәзәмнең төпләрендә
Бадиян дигән гөлләр бар.
Сиңа охшатып сөяр идем,
Сиңа охшаган кемнәр бар.

Җилләр исеп чәчәк исен
Тарата болыннарга.
Кошлар булсам, барыр идем,
Син булган урыннарга.

Сандугачым талга басып
Сайраганы юк иде.
Бер кеше өчен бу кадәре
Саргайганым юк иде.

Алты метр ал тасма,
Җиде метр гөл тасма.
Сөям дисәң, бир вәгъдәңне,
Сөймәс булсаң, алдашма.

Биек тауга менгән чакта
Таптым ал кашлы йөзек.
Агыйделләргә төшсәң дә,
Алып чыгармын йөзеп.

Энҗеләр тезим әле,
Сайлап эресен генә.
Янам синең утларыңда,
Бәгърем, белмисең генә.

Капка төпләренә чыгып
Кулъяулыгым киптерәм.
Серле күз карауларыңны
Күз алдыма китерәм.

Аклы ситса күлмәгеңне
Әллә сабыннадыңмы?
Киләсең дә, китәм, дисең,
Әллә сагынмадыңмы?

Алма өзсәң, җепкә тезсәң
Балавызлы җепкә тез.
Син юк җирдә, мин дә түзәм,
Мин юк җирдә, син дә түз.

Кара сатин ситсалардан
Күлмәк кистердем әле.
Сиңа охшатып, балконнарда
Гөлләр үстердем әле.

Түгәрәк күл эчләрендә
Эчертәм атларымны.
Җаннарымнан артык күрәм,
Җибәргән хатларыңны.

Көмеш йөзек сына диләр,
Сынмый да, бөгелми дә.
Гыйшык уты сүнә диләр,
Сүнми дә, сүрелми дә.

Яшел чирәм өсләреннән
Эзләдем эзләреңне.
Таба алмадым эзләреңне,
Онытмам сүзләреңне.

Сандугачлар су эчәләр,
Ак иделгә тезелеп.
Син дә шулай сагынасыңмы,
Минем кебек өзелеп?

Кызыл батис яулыгым,
Җилферди җилдә генә.
Күңелләрем күтәрелә,
Син булган җирдә генә.

Ак альяпкычлар тектердем,
Каралар кыйммәт булгач.
Сагынсам да, түзәм инде,
Аралар ерак булгач.

Шәлем көрән, шәлем көрән,
Кулъяулыкларга төрәм.
Хатлар белән сөйләшмәсәк,
Мин сине кайчан күрәм.

Сандугачлар сайрамаса,
Ничек уяныр идем?
Сагынганда хатың булса,
Укып юаныр идем.

Өстәлләрдә буй-буй такта,
Гөлләрем урам якта.
Якты йолдызларга карыйм
Сине сагынган чакта.

Урындыкка мендәр куйдым,
Кил, дускаем, син утыр.
Җаным, бәгърем, дигәннәргә
Серләреңне бирми тор.

Ал тасмалар алдым әле,
Чәчләремне үрергә.
Бу хат миннән бәхетлерәк,
Бара сине күрергә.

Кына гөлләре күп чәчтем,
Чәчә алмадым ислесен.
Җаныкаем, бик сагынам,
Ник җил булып исмисең.

Иртә торып тышка чыксам,
Күзем төшә гөлләргә.
Минем кебек саргаймасын,
Су сибегез гөлләргә.

Аллы-гөлле чәчәк ата
Бакчадагы әфлисун.
Сагынмыйм түгел, сагындым,
Сагынсам да, нишлим соң.

Уйлыйм чәчәк атканда,
Җырлыйм кояш батканда.
Син дустымны бик сагынам,
Сызылып таңнар атканда.

Су сип, дустым, гөлләреңә,
Су сипмичә корытма.
Бергә булган минутларны
Аерылгач та, онытма.

Алма бакчасына кереп,
Хат язарга исәбем.
Хатка язып сүзләр бетми,
Сау бул, алма кисәгем.

Ак иделнең талларына
Таяна торган идем.
Нурлы йөзләреңә карап,
Юана торган идем.

Тәрәзә ачып җимнәр сиптем
Ак канатлы таулыкка.
Сөймәдем түгел, бик сөйдем,
Белдермәдем халыкка.

Ак иделгә төшәрсең,
Колач салып йөзәрсең.
Кычкырган чакта кәккүкләр
Ничек инде түзәрсең?

Аклы ситса күлмәгемне
Кисәм каралыр микән?
Искән җилгә сәлам бирсәм,
Алып баралыр микән?

Аллы-гөлле чиләгеңнән
Суларың түгелмәсен.
Дошман сүзләренә карап,
Күңелең сүрелмәсен.

Тукта поезд, тукта поезд,
Тукта, кеше утырсын.
Яшьләй сөйгән ярым бит ул,
Ничек итеп онтырсың.

Алма бакчасына кереп,
Чәчәк өздем мин илдән.
Гөлдән өзгән чәчәк кебек,
Аерылдым бит мин сездән.

Ал матурмы, гөл матурмы,
Кайсысын яратасың?
Эч серемне аласың да,
Ятларга таратасың.

Аклы ситса күлмәгемнең
Җиңе тар беләгемә.
Сандугачларның сайравы,
Ял була йөрәгемә.

Җир җиләге җыя-җыя,
Кульяулыгым тулды инде.
Син дустымны күрмәгәнгә
Бик күп көннәр булды инде.

Алсу, алсу диләр иде,
Алсуга кызыл тамган.
Былбыллар аерылмый икән,
Былбыл буласым калган.

Камадай кара кашларың,
Карлыгандай күзләрең.
Йөрәгемне яндырадыр,
Өзелеп әйткән сүзләрең.

Җем-җем кара чәчләремне
Сүтсәм, үрәлмәм инде.
Җаным, нурлы йөзләреңне,
Китсәң, күрәлмәм инде.

Без барабыз Кырымнан,
Кырым иле кырыннан.
Минем иркәм булса таныр,
Җырлап килгән җырымнан.

Ишек алдым сары чәчәк,
Сарысын сабын итәм.
Сагынмый дип йөрмә, дустым,
Сагынып сабыр итәм.

Аерылганда кулың бирдең,
Син миңа салкын гына.
Салкын кулың йөрәгемә
Тутырды ялкын гына.

Ак иделгә туры бар,
Ике ягы кызыл яр.
Онытыла, дип әйтә күрмә,
Онытылмый сөйгән яр.

Алма бакчасына элдем,
Башымдагы шәлемне.
Бармы җаның, юкмы җаның,
Ник белмисең хәлемне?

Иртә торып тышка чыксам,
Бар матурлык айда икән,
Әй, бәгърем, бергә булган,
Көннәребез кайда икән?

Иртә торып тышка чыксам,
Гөрли күгәрченнәрем.
Бик сагынам, бәгырькәем,
Килә күрәселәрем.

Усак яна, усак яна,
Яна да, күмерләнә.
Онытырлык ярым түгел,
Оныта алмыйм гомергә дә.

## Бәлки син дә сөярсең

Эчтә тулып-тулып хисләр ята,
Телим сиңа әйтеп бирергә.
Хәзер әйтәм-әйтәм дигән чакта
Тотлыгам да китәм кирегә.

Күктә якты-якты йолдыз яна,
Иң яктысы син күк тиясең.
Сине уйлый-уйлый мин юанам,
Бәлки әле син дә сөярсең.

## Урам җырлары

Бөгелмәле, сыгылмалы
Көянтәң бардыр әле.
Кара кашлы, зәңгәр күзле,
Сөяркәң бардыр әле.

Ак иделнең ар ягында
Күлләр түгәрәк кенә.
Бер чәчәк тиң икенчегә,
Җырлый күбәләк кенә.

Биек тауның башларында
Гөлҗимеш матур агач.
Уйлый күңелем, сезне эзли,
Елыймын аптырагач.

Уйнап җибәр гармуныңны
Без җырлаган көйләргә.
Без җырлаган, сез уйнаган
Калсын сагынып сөйләргә.

Биек тауның башларында
Гөлҗимеш матур агач.
Елыймын да, яман сулыйм,
Җырлыймын аптырагач.

И, дускаем, озата алмадым,
Авыллар күмелгәнче.
Бигрәк читен була икән,
Күңелләр сүрелгәнче.

Егетләрнең перчаткасы,
Ак мамыктан аркавы.
Кояш баегач ятып йоклый,
Егетләрнең ялкавы.

Аргы якның кыр казларын
Бирге яктан карыйбыз.
Егетләрнең ничеклеген,
Бер карауда таныйбыз.

Тальян гармун, тальян гармун
Уйнап узып китәргә.
Уңган, зирәк егет белән
Озак гомер итәргә.

Урам аша елгалардан,
Су ала торган идем.
Авыр сүзләр әйтергә дә
Кызгана торган идем.

Урам аша елгалардан
Су ала торган идем.
Синнән башка бер минутта
Торалмам, дигән идем.

Телеграм баганасын
Кемнәр утырта икән.
Яннарың бизәрлек итеп,
Кемнәр котырта икән.

## Җырлар

Ак иделдән агып килә
Фонарь яндырып көймә.
Сау бул, дигән минутларың
Күз алларыма килә.

Биек тауның башларында
Йөгереп йөри бер бәрән.
Әйдә, дустым, безнең якка,
Син ул якларга әрәм.

Казан кооперативында
Алтын ләгәннәр бар.
Әйдә, дустым, безнең якка,
Яның теләгәннәр бар.

Җәйгә чыксам, тузан куба,
Атымның тоягына.
Син дустымны охшатамын,
Зәйтүн гөл кыягына.

Без китәрбез, сез калырсыз,
Талдан күпер салырсыз.
Талдан күперләр тар булыр,
Бер күрешүләр зар булыр.

Дустым, сиңа бүләгем юк,
Виноградлар пешмичә.
Айлар, еллар үтеп китте
Бер күреп сөйләшмичә.

Тальянский гармуннарны
Уйныйлар тартып-тартып.
Сандугачым – беренче көй,
Син алардан да артык.

Тальянский гармуннарны
Уйный белсәң уйнама,
Үзең ничек мин дә шулай,
Ялыныр дип уйлама.

Алма бакчасын чабыгыз,
Үткен булса чалгыгыз.
Су өстендә дулкын ничек,
Безнең шундый чагыбыз.

## Кыска җырлар

Стаканым тулы түгел,
Тулы диеп түкмәгез.
Җырлый белеп җырламыймын,
Дуслар, гаеп итмәгез.

Стенада сәгать суга,
Минутын белеп кенә.
Төшләремә син керәсең,
Елмаеп, көлеп кенә.

Китәм дисең, китәм дисең,
Син бер китәрсең әле.
Син бер китеп башларымны
Кайгылы итәрсеңме.

Сандугачлар сайрый, сайрый,
Ничек түзә кагынмый.
Күз карауларың ягымлы,
Ничек түзим сагынмый.

Аклы яулык юар идем,
Ишек төбем күл булса.
Яныгызга барыр идем,
Җир астында юл булса.

Башка гөлләр арасында
Яратам мин кынаны.
Яратмас идем кынаны,
Сезгә охшатам мин аны.

Җәйге көндә, матур көндә,
Атлар көтәм ялгызым.
Сез дусларга ошатамын,
Күктә чулпан йолдызым.

Биек тауга менгән чакта,
Ябышам үләннәргә,
Үләннәр дә зикер әйтә,
Сез матур гүзәлләргә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Разия.
Сезгә ошаган гөлләр үсә
Средний Азияда.

* * *

Кеше гомерен аерып алып
Сөймәм, Аллам сакласын.
Кеше яры диеп тормам
Яры булса, сакласын.

Сандугачны ничек тотыйм,
Ничек көйләрен отыйм.
Син бит минем якын дустым,
Сине ничек онытыйм.

Йөгердем, җитә алмадым,
Сикердем читәннәрен.
Ни булды икән телләремә,
Сау бул, дип әйтә алмадым.

Кызыл-сары күлмәгеңнең
Кара тамган түшенә.
Сагынсам да, саргайсам да,
Сөйләп булмый кешегә.

*Истәлек өчен.*
*Туганыма.*
*И.Ф.К.дан*

**Истәлеккә җырлар**

Аклы ситса күлмәгеңне
Яшел белән сырларсың.
Әгәр мине исеңә алсаң,
Җырларымны җырларсың.

Ай яктысы бигрәк якты,
Көн яктысы яртысы.
Сезнең белән бергә йөри
Күңелемнең яртысы.

Кара атка шул килешә:
Кара каеш, дилбегә.
Бу җырларны сиңа язам,
Онытмаска, билгегә.

Алларым да син идең,
Гөлләрем дә син идең.
Утларын да син кабыздың,
Суларын да сип үзең.

Безнең капка каен такта,
Гөлләре урам якта.
Аккош балалары кебек
Төрлебез төрле якта.

Бу яфраклар ник саргайган?
Көзге кыраулар алган.
Безнең йөзләр ник саргайган?
Кайгы-хәсрәтләр алган.

Сандугачым, ник сайрыйсың,
Ни зарың бар Ходайда.
Мин дә синең кебек,
Сабыр итәм шулай да.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Миңзифа.
Идел камышлары кебек
Синең буйларың зифа.

Өй артында миләшем,
Берәү дә әйтми балан дип.
Чит җирләрдә ялгыз башым,
Берәү дә әйтми «балам» дип.

Өй артында баланым,
Көн дә чыгып аламын.
Әникәем, сине уйлап,
Көн дә елап аламын.

Биек тауда йөрим мин,
Карлар яуса, көрим мин.
Сез булмагач бер ямь дә юк,
Ямансулап йөрим мин.

Яшел саплы урак белән,
Урак урасым килә.
И, туганым, сезнең белән
Бергә буласым килә.

Телефонда йөз чыбык,
Иң кечесе кыл кебек.
Сезне уйлап үткән гомер
Бер минутлы җыр кебек.

Акбүз атны эчерергә
Юлымда кое булды.
Бергә чакта рәхәт иде
Аерылгач кыен булды.

Минем сөеп җиккән атым
Кара белән тимер күк.
Бик сагынсам, айга карыйм,
Ай да ялгыз минем күк.

Ике метр сатин алдым,
Мендәр тышларга гына.
Сагынганда күрешә торган
Канат кошларда гына.

Иртән торып чия ашыйм,
Йөрәгем уйнаганга.
Йөрәккәем шуңа уйный,
Гел сезне уйлаганга.

Ак машина, көмеш энә,
Яшел юрган сырырга.
Безгә Ходай язган икән
Аерылышып торырга.

Бәйлим, сүтәм, бәйлим сүтәм,
Килешерлек булмагач.
Мин сагынып хатлар язам,
Күрешерлек булмагач.

Без барасы, юл арасы
Сайрый былбыл баласы.
Безнең кебек аерым тора
Кырларда кош баласы.

Яңа өйнең шкафларында
Лимон калды кап белән.
Безгә Ходай язган икән
Сөйләшергә хат белән.

Нинди машина баса икән
Ак сатинга бизәкне.
Сез дуслардан аерым торгач,
Өзә икән үзәкне.

Кызарып кояшлар чыга
Кавказ тавы артыннан.
Очарга дип өч талпындым,
Язган хатым артыннан.

Сандугач төшкән такырга
Канат кагып ятарга.
Сандугачтан канат алып,
Их, сөйләшеп кайтырга.

Ай да ялгыз, мин дә ялгыз,
Ләкин ай яшен түкми.
Айга карап ялварсам да
Сагынуларым бетми.

Сандугачның балалары,
Йөри камышны сайлап.
Өзә үзәкне сандугач,
Мин сагынганда сайрап.

Иртән торып тышка чыксам,
Ишек алларым томан.
Шул томаннар арасында
Син басып торган сыман.

Сәгать суга, сәгать суга
Стена буйларында.
Ятсам, торсам, ни уйласам,
Син генә уйларымда.

Дустым, өзелеп җырлар язам,
Сандугач кагынганда.
Утка якма, суга салма,
Укырсың сагынганда.

Биек тауның башларында
Арыш үсә бөгелеп.
Син сагынмый торгансыңдыр,
Мин сагынам өзелеп.

Кульяулыгым икәү иде,
Берсе суларга акты.
Төрлебезне төрле якка
Дөнья дулкыны какты.

Җәй көннәре иртә белән,
Күгәрчен кагынганда.
Синең карточкаңа карыйм,
Өзелеп сагынганда.

Агыйделгә басма салдым,
Берсе сиңа чыгарга.
Бергә булган вакытларны
Исләреңнән чыгарма.

**«Шахта көе»**

Аклы ситса күлмәгемә
Ал саласым калмаган.
Үз башыма хәсрәт итеп
Яр сөясем калмаган.

Аклы күлмәк ник тектердем
Көн саен кимәгәч.
Яшь күңлемне ник аздырдың
Ихлас белән сөймәгәч.

Урамнардан узаем да
Ал тасмалар сузаем.
Ал тасмалар җитмәс җиргә
Бер җыр җырлап узаем.

## Җырлар

Ал да чибәр, гөл дә чибәр
Көзгедән карап җибәр.
Матур кызлар арасында
Иң матуры син, диләр.

Кашың кара, кашың кара,
Минеке дә карамы?
Минем йөрәккәем яна,
Синеке дә янамы?

Кашың кара, кашың кара,
Кашыңнан күзең кара.
Керфегеңнән нурлар тама,
Күрсәм, йөрәгем яна.

Кара елганың буенда,
Карлыган пешәр әле.
Без ятларны сөйгән чакта,
Исеңә төшәр әле.

Карлыганнар пешкән, дидең,
Кайда карлыганнарың?
Болай булгач, билгеле инде,
Ятка калдырганнарың.

Кара каешлар килешә,
Нечкә билкәйләреңә.
Кайтасың килә торгандыр,
Туган илкәйләреңә.

Утырган урыннарымнан
Бүтән тора алмам инде.
Сабыр канатларым сынды,
Сабыр итә алмам инде.

Утыр, диеп урын бирде,
Ник утырмадым икән?
Сау бул, диеп кулын бирде,
Ник кул бирмәдем икән?

Кулымдагы йөзегемнең,
Исемнәре Асия.
Гөлләр – маяк, сандугачлар
Юлдаш булсыннар сиңа.

Җәй көнендә су коендым
Матур үрдәк күлендә.
Гомеремдә дә онытмамын,
Торырсың күңелемдә.

Яз җиткәнне беләләр бит
Казлары да коена.
Көнләшкәннең көне бетсен,
Көнләштерик тагын да.

*24.02.1954.*

**Шөгер**

Безнең егет әйткәләде,
Сөйгән ярын чакырып:
Синнән башка берәүгә дә
Күзем төшми, матурым.

Тальян гармун уйнаталар,
Безнең Шөгер буенда.
Ятсам, торсам, керсәм, чыксам,
Гел син генә уемда.

Шөгерләрдә ташкын кунды,
Шөгер суы тәмлегә.
Бир кулыңны, мин дә бирим,
Аерылмаска мәңгегә.

Без дә бүген теләктә лә,
Күңлем изге теләктә.
Мәхәббәтем гөлләр булып
Чәчәк аткан йөрәктә.

*20.11.1954*

**Әтнә көе**

Җырлыйк Әтнә көйләренә,
Җырчыларга таралсын.
Мул уңышлар үстерүдә,
Безнең Әтнә дан алсын.

Матур итеп кошлар сайрый,
Әтнә су буйларында.
Ятсам – төштә, торсам – истә,
Син генә уйларымда.

Кызарып кояш чыкмыйча,
Уйсу җирдә су кипми.
Көлемсерәп карауларың,
Күз алларымнан китми.

Шушы көйне матур итеп,
Җырлыйлар Әтнәләрдә.
Үзәкләремне өзәләр,
Исемең әйтәләр дә.

**Зөя**

Зөя ямьле, Зөя ямьле,
Зөянең суы тәмле.
Зөя ямьле, суы тәмле,
Безнең дуслар бик ямьле.

Зөянең матур суында
Вак балыклар дуенда.
Алма кебек матур кызлар,
Үсә Зөя буенда.

Зөя буйлап агып килә
Ап-ак каз канатлары.
Мәңге ядкәр булып калыр
Серле күз карашлары.

Аргы яктан бирге якка
Басма салдым киң итеп.
Гомерлеккә яр булсын, дип,
Сине сөйдем тиң итеп.

## Зәңгәр күлмәк

Казан сөлгеләре бигрәк матур,
Сабан туйларына эләргә.
Безнең теләкләр дә шундый матур иде:
Бергә яшәп, бергә үләргә.

Салкын чишмәләрдән су алганда
Зәңгәр чиләкләрем тулмады.
Ни кадәрле яратып йөрсәк тә,
Кавышырга насыйп булмады.

Һаваларда очкан кошлар кебек,
Ярсый-ярсый канат кагынып шул.
Туган илемә кайттым мин талпынып,
Күз нурларым, сезне сагынып.

Һаваларда очкан аккошларның
Канатлары җилдә кайрылмый.
Яшәр идем туган илем синдә
Якын дусларымнан аерылмый.

Һаваларда очкан аккошлардан
Коела җиргә мамык тузаны.
Туган илдә йөргән дуслар белән,
Сизелми лә гомер узганы.

Һаваларда очкан аккошлардан
Каурыйлары коела җилләргә.
Туфрагына алтын чәчсәләр дә,
Җитми икән туган илләргә.

### Ялгыз агач[1]

Яшел яфрак яргач,
Шаулый җилдә агач.
Ял итәргә чакыра ул мине.
Хуш исле ягыма,
Туган туфрагыма
Тарта мине яшел якташым.

Гомер җиле исә
Агач ялгыз үсә.
Айлар, кышлар, кичә ялкыным.
Күңел һаман тарта
Туып үскән якка,
Агачыма кайтам ашкынып.

* * *

Матур яза, шома яза
Комсомоллар каләме.
Тиздән Кытайда да балкыр
Ленинизм әләме.

Томскиның урамнары –
Эреле-ваклы тап кына.
Безне якты көнгә чыгарды
Ленин – пеләш баш кына.

Атларны матур күрсәтә
Томски дугалары.
Кайда барсам, шунда кирәк
Ата-ана догалары.

---

[1] Халык сүзләре, халык көе.

Кызылкашның урамнары
Уйный җил-бураннары.
Бик сагынсам, сөйләр идем,
Юк телеграммнары.

Кызылкаштан Абытайга
Үрмә үрсәләр иде.
Күкрәгемдә бер каты бар,
Ярып күрсәләр иде.

* * *

Сандугачның сайравына
Күңелләрем боега.
Әйтегез шул сандугачка,
Сайрамасын быелга.

Яшьлегем чәчәк атканда
Мин аны сөйгән идем.
Бәлки мине бу көннәргә
Калдырмас, дигән идем.

Сандугачлар сайраганда
Килә елыйсылары.
Төшләремә дә кермәде
Болай буласылары.

Чәчләремне тарап куйдым
Урал кызлары кебек.
Күкрәгемдә бер төер бар,
Урал бозлары кебек.

Әйдә, дустым, су буена,
Кулъяулыгың юарсың.
Син юарсың, мин җырлармын,
Күңелең тулса, еларсың.

## Сайлау җыры

Бөек эштә, зур көрәштә
Кем җиңеп алга бара?
Шул кеше бездә мактаулы,
Данлы булып санала.

Кем бөек, даһи Ленинның
Чүп төшерми юлына.
Шул кеше данлы санала,
Күркәм кеше шул гына.

Кем халык дошманнарына
Каршы көрәш алып бара.
Шул кеше илдә мактаулы,
Данлы булып санала.

Кем ил өчен, халкы өчен,
Сталинча эшли ала.
Шул кеше бездә мактаулы,
Данлы булып санала.

* * *

Урманнарга баргансың,
Нигә нарат кисмәдең?
Аркылыга җәелгәнсең,
Нигә буйга үсмәдең?

* * *

Аягыма сулар үтә,
Сары сандал кисәм дә.
Кошлар сайрап сагындыра,
Сагынмыймын дисәм дә.

* * *

Мин ал идем, гөл идем,
Мин болай түгел идем.
Сайрамаган сандугачны
Сайраттырган мин идем.

* * *

И, алым бул, гөлем бул,
Көн дә күз алдымда бул.
Җәен шомырт чәчәге бул,
Кышын кышлау гөле бул.

* * *

Ике аккош, бер тутый кош
Йөзә тирән елгада.
Бер аерылгач күрешеп булмый.
Айга түгел, елга да.

* * *

Сандугачым, былбылым,
Кичә кайларда булдың?
Бөтен дөнья малын биреп,
Сатып алырдай булдым.

* * *

Синең кашың кара булса,
Минем күзем сөрмәле.
Синең бәхетләрең булса,
Мин дә хур булмам әле.

* * *

Сандугачымны җибәрдем
Тыңларга сүзегезне.
Ул да барып, кире кайтты,
Күрмәгән үзегезне.

* * *

Аккош, былбыл атсам да,
Сазга кереп батсам да,
Онытмам сез туганнарны,
Мич башында ятсам да.

* * *

Җәйләрнең житүенә,
Кышларның үтүенә.
Исәпләсәм исем китә,
Яшь гомер үтүенә.

**Авторлар турында кыскача белешмә**

*Миңнуллин Ким Мөгаллим улы* – филология фәннәре докторы, профессор, ТР Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры.

*Баязитова Флера Сәет кызы* – филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге баш фәнни хезмәткәре.

*Борһанова Алсу Фәһим кызы* – Казан (Идел буе) федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Л.Н. Толстой исемендәге милли сәнгать һәм дизайн кафедрасы магистры.

*Булатова Миңнира Рәхим кызы* – филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге фәнни хезмәткәре.

*Волков Владимир Геннадьевич* – Томск дәүләт педагогика университеты хезмәткәре.

*Закирова Илсөяр Гамил кызы* – филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре.

*Иванов Павел Григорьевич (1890)* – тарихчы, тюрколог, педагог. Томск университетында, Себер татар педагогика техникумында, Себер фармацевтика техникумында укыткан, Том карагасларын өйрәнгән. Үлгән елы билгесез.

*Рамазанова Дария Бәйрәм кызы* – филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге баш фәнни хезмәткәре.

*Хажҗиева-Демирбаш Гүзәлия Сәйфулла кызы* – филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Хисамов Олег Ришат улы* – филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директорының фән буенча урынбасары.

*Яхшисарова Гөлнара Рәшит кызы* – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге фәнни хезмәткәре.

**ЭЧТӘЛЕК**

СҮЗ БАШЫ = ПРЕДИСЛОВИЕ
5

ТЮРКО-ТАТАРСКАЯ ТОПОНИМИЯ ТОМСКОЙ ОБЛАСТИ
*Олег Хисамов*
11

ТЮРКИ ТОМСКОГО ПРИОБЬЯ В XVII – НАЧАЛЕ XVIII В.
*В.Г. Волков*
52

СЕБЕР ТАТАРЛАРЫНЫҢ ТОМ ДИАЛЕКТЫ
*Дария Рамазанова*
81

ТОМ ДИАЛЕКТЫНДА ХАЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕ
ҺӘМ ФОЛЬКЛОР
*Флера Баязитова*
155

ТОМСК ТАТАРЛАРЫНЫҢ
ТЕЛ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ ҺӘМ РУХИ МӘДӘНИЯТЕ
*Миңнира Булатова*
209

ИМЯ ЧЕРЕЗ ВЕКА
*Гузелия Хазиева-Демирбаш*
277

ТОМСК ТАТАРЛАРЫ ХАЛЫК ИҖАТЫ
*Илсөяр Закирова*
291

ШӘРФҮК ӘБИ ҖЫРЛАРЫ
*Гөлнара Яхшисарова*
334

МАТЕРИАЛЬНАЯ КУЛЬТУРА, РЕМЕСЛА
И ДЕКОРАТИВНО-ПРИКЛАДНОЕ ИСКУССТВО
СИБИРСКИХ ТАТАР ТОМСКОЙ ОБЛАСТИ
*Алсу Бурганова*
358

ТОМСКИЕ ТАТАРЫ
(Материалы по обследованию Томских карагассов летом 1927 г.)
*П.Г. Иванов*
370

ЕРАК ЕЛЛАР КАЙТАВАЗЫ
391

Научно-популярное издание

*Серия «Из сокровищницы научных экспедиций»*

Четырнадцатая книга

**Национально-культурное наследие**
**ТАТАРЫ ТОМСКОЙ ОБЛАСТИ**

Фәнни-популяр басма

*«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе*

Ундүртенче китап

**Милли-мәдәни мирасыбыз**
**ТОМСК ӨЛКӘСЕ ТАТАРЛАРЫ**

Редакторлар: *Я.М. Абдулкадыйрова, А.А. Мартьянова*
Компьютерда биткә салучы *Н.Т. Абдуллина*

Китапта *О.Р. Хисамов, И.Г. Гомәров, И.Г. Закирова, А.Ф. Борһанова, М.Р. Булатова, Г.Р. Яхшисарова* фоторәсемнәре файдаланылды

Басарга кул куелды 12.12.2016
Форматы 60×84 $^{1}/_{16}$. Офсет кәгазе. Times New Roman гарнитурасы.
Офсет басма. Нәшер-хисап табагы 17,2. Шартлы басма табагы 25,1.
Тиражы 500 д. Заказ

Оригинал-макет
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләнде
420111, Казан, К. Маркс ур., 12